ТӘҮБӘ

ТӘҮБӘ

КАЗАН
ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ
1991

ББК 87.7
Т86

Төзүчеләр:
Я. М. АБДУЛКАДЫЙРОВА, Р. Б. ЗАРИПОВА

Тәүбә. Очерклар җыентыгы.— Казан: Татар. кит.
Т86 нәшр., 1991.— 136 б.
ISBN 5—298—00662—0

Бу китапка кешелек хисләрен югалтып баласын тәрбияләүдән ваз кичкән ата-аналар, җәмгыятебезнең әхлак нормаларын тупас бозып тирә-юньдәгеләрнең шәхесен кимсеткән кешеләр һәм аларның һаман арта баруына китергән сәбәпләр турында борчылып язылган очерклар, публицистик язмалар тупланды. Китапны укып чыгу һәркем өчен файдалы һәм гыйбрәтле булыр дип уйлыйбыз..

Т $\frac{0301070000—283}{М132(03)—91}$ 15—91 ББК 87.7

ISBN 5—298—00662—0

© Абдулкадыйрова Я. М., Зарипова Р. Б., төзү, 1991.

«ОНЫТМАГАН БУЛСАГЫЗ...»

Эштән арыбрак кайткан иде Гөлчирә. Әмма почта ящигында хат күргәч, аның адресына күз ташлагач, аруларын онытты ул. Хатны кат-кат укыды. Күзләренә яшь тыгылды, дулкынланудан маңгаен салкын тир каплады. Инде онытылып беткән вакыйгаларны кабат күзаллады, кабат кичерде. Бу хатны Вася-Василек язган булуына ышанасы да килми иде. Әйтерсең лә газаплану, борчылу кичергән, билгесезлек белән яшәүче олы кешенең өмет тулы юллары иде бу. Аптыраган, шаккаткан, сөенгән Гөлчирә тагын хат юлларына текәлде:

«Белмим, Гөлчирә апа, бәлки, хатымны да укымассыз. Шулай да тагын бер кат борчырга булдым. Хәер, борчуларым, дөресрәге, борчуларыбыз, болай да җитәрлек булды бит. Юк, бездәге тавыш-гауга турында әйтмим мин. Боларында без — сабыйларның гаебе юклыгын үзегез дә белә идегез бит. Хәтерегездә микән, күршебез Галя апага нидер сөйли-сөйли, ике көмеш кашык агарттыгыз. Әбиегездән әниегезгә, әниегездән Сезгә күчкән бик кадерле кашыклар булуын мин дә ишетеп калдым. Иртән торып Сез эшкә киткәнсез, ә көмеш кашыклар кухня өстәлегездә ялтырап ята. Алдым да кесәмә тыктым. Юрканың хаты янына. (Ә сез минем энемә «Юрик» дип кенә, иркәләп эндәшә идегез!) Онытмаган булсагыз, медсестра китергән ул хатны елыйелый иң башта Сез укыдыгыз. Хәер, исегездәдер, андый әйберләр онытыламыни! Исемә төшкән саен, хәзер дә әле йөрәгем өшеп китә. «Вася, абыем, зинһар, син мине ташлама. Син дә ташласаң, мин сукыраеп үләчәкмен. Әгәр палатага кертмәсәләр, син тәрәзәгә кар ыргыт, мин тәрәзә янына килермен. Кып-кызыл зур алма ашыйсы килә. Күзем әз генә күрә башлады. Мине ташлама, Васенька», — дип кемнәндер хат яздырган иде җиде яшьлек энем Юра. Бу хат бүген дә минем түш кесәмдә... «Кып-кызыл алмалар». Шул кып-кызыл алмаларны алырга миңа акча кирәк иде. Һәм мин Сезнең көмеш кашыкларны кесәмә тыктым. Энемнең хаты янына. Бүген дә хәтерлим: кулларым кайнарланды,

аркам тиргә батты, чәчләрем юеш маңгаема ябышты... Кашыкларны мин, әни сатарга кушты дип, алдаша-алдаша базарда саттым. 2 тәңкәгә.

Больницада мине палатага ук керттеләр. Энем Юра минем ак халат эченә башын яшереп елап җибәрде. Дымлы керфекләремне көчкә күтәреп, нәрсәдер әйтергә тырыштым. Энем алдында җебеп утырырга ярамаганын аңлый идем. Мин аңа дүртенче класс укучысы түгел, абый идем бит! Бердәнбер таяныч, ышаныч! Тик тамак төбендәге каһәр суккан төерне генә куып булмый...

— Мин сиңа кызыл алмалар алып килдем,— дидем, ниһаять.

— Чынмы? Кып-кызылмы?!

— Кып-кызыл! Өчәү.

Юра, караватыннан сикереп төшеп, тәрәзә янына йөгерде. Алмаларны әйләндерә-әйләндерә бик озак карады. Аннан аларны күкрәгенә кысып, сикерә-сикерә әйләнергә-бөтерелергә тотынды.

Бүлмәгә врач белән медсестра керделәр.

— Кып-кызыл алмалар. Абыем Вася алып килгән! — диде Юра, елмаеп. «Абыем» сүзенә басып ясап әйтте. Горурлык белән.

Ул көнне врач, бүлмәсенә алып кереп, минем белән бик озак сөйләште. Сорашты.

— Энеңнең сәламәтләнү мәсьәләсе, Василий,— дип башлады сүзен врач апа (миңа беренче тапкыр «Василий» дип эндәшүче кеше), — синнән дә тора. Кечкенә булса да нервлары бик киеренке хәлдә. Аңа ял, тынычлык һәм ышаныч-таяныч кирәк. Ул таяныч, минемчә, син бугай. Син Юра янына гел килеп йөр! Юра хәзер бераз күрә башлады — күрү сәләте акрынлык белән генә кайта. Син дә безгә — врачларга — бу эштә ярдәм итәргә тиеш. Безнең янга кереп чыгуын үтенеп, әниеңә берничә тапкыр хат салдык. Килмәгәч, эшенә шалтыраттык. Вәгъдә дә биргән иде, һаман килми, күренми... Юраның кайчан һәм нинди шартларда авырый башлавын белми торып, күрү сәләтенең бөтенләй кайтуына ышанып булмый. Бөтенесен дә сөйлә, Василий. Яшермичә. Юраның күзләре генә түгел, хәтта киләчәге дә шушы сөйләшүгә бәйле.

Врач апага бөтенесен дә сөйлисем килде. Акылым белән сөйләп тә чыктым. «Әйе-әйе, дидем эчемнән генә, энемнен сукыраюының сәбәбен беләм мин. Юра белән без ике ата баласы — энемнең фамилиясе — Голиков, ә минеке — Захаров, болардан тыш әнинең Мартиненко, Афанасьев дигән ирләре дә булды. Әнинең һәр көн эштән эчеп кайтуы-

на, аннан талашуына түзмәделәр... Хәзер әни көн саен берәр ир ияртеп кайта. «Менә сезгә эти алып кайттым, ишетсен колагыгыз, аңа эти дип кенә эндәшәсе булыгыз»,— ди безгә. Төнге өчләргә кадәр эчәләр, җырлыйлар, кычкырышалар, сугышалар. Юра белән мин, котыбыз алынып, төнге өчләрдә-дүртләрдә генә йокыга китәбез. Ә иртән сәгать сигезгә мәктәпкә барырга кирәк...»

Юк, боларны кычкырып әйтергә телем әйләнмәде.

— Безнең әни бик чибәр шул, — дидем һич тә кирәкмәгәнгә.

— Шулайдыр. Тик андый хатыннарның матурлыкларының кадерен белмәүләре генә кызганыч.

Врач апаның тавышы хөкем булып яңгырады. Андый хатыннар... Кызганыч... Әни өчен рәнҗеп киттем. «Минем әнием кызганыч?! Кухняга да 70 тәңкәлек япон халаты гына киеп чыга безнең әниебез, беләсегез килсә! Әниемнеке кебек тунны, мех бүрекне бүтән бер апада да күргәнем юк әле», — диясем килде. Ләкин эндәшмәдем. Врач апаның хаклы икәнен йөрәгем белән тоя алырлык дәрәҗәдә идем инде мин. Тоттым да, врачны аптыраштa калдырып, әнием турында түгел, күршеләребез — сезнең турыда сөйли башладым.

— Безнең күршеләребез бик кызык кешеләр бит. Галя апаның да ике баласы бар — Таня һәм Женя. Аларның этисе Сергей абый, син, Вася, безнең йортның олы егете, урамда, я мәктәптә чакта безнекеләргә дә күз-колак бул инде, ди миңа. Галя апа һәм Сергей абый көн саен балаларын мәктәпкә озаталар, көн саен каршы алалар. Аларның дәресләренә дә кереп утыргалыйлар әле кайчакта. Вакытында ашыйлар, вакытында йоклыйлар. Кызык инде... Ә икенче күршебез, Гөлчирә апа, беләсезме, кем булып эшли?! Авиация заводында токарь. Орденнары да бар. Икәү. Үткән якшәмбедә генә туган көне булды. Җыйнаулашып заводтан килгәннәр. Бүләккә китаплар күтәреп. Кызык инде, бер тамчы да аракы эчмичә генә җырлашып утырдылар. Әни әйтә... — дидем дә туктап калдым. Әниемнең алар турында әйбәт фикер әйтмәвен һәм аның хаклы түгеллеген нәкъ шушы минутта аңлап алдым.

Врач апа:

— Ярый, Василий, өегезгә барып, әниең белән сөйләшмичә булмас. Юра янына гел килеп йөр, — дип озатып калды.

Ул көнне мин ике җинаять эшләдем. Сезнең, Гөлчирә апа, көмеш кашыкларыгызны урладым һәм мәктәптә дәресләремне калдырдым.

Менә җинаятем өчен җәза көтәм. Котны алып, кич якынлаша. Мәктәптә булмады дип, класс җитәкчебез Мария Гавриловна керер кебек. Бүген әле ул минем кашыкларымны да урлаган, дип, Сез дә гауга куптарырсыз сыман.

Кич җитте. Мария Гавриловна кермәде. Сез эштән кайттыгыз. Бөтен барлыгымны, бөтен зиһенемне, игътибарымны туплап, кухняны тыңлыйм. Менә Сез аш әзерлисез. Галя апа балалары өчен сөтле ботка пешерә.

— Кызык,— дидегез Сез.— Кашыкларны өстәлдә калдырган идем. Любаның кичәге сөрхәнтәе чәлдергәндер инде. (Люба — минем әни.)

Сөенеп киттем. (Шул чактагы халәтем өчен бүген оялам.) «Ә-һә, дидем эчемнән генә, Гөлчирә апа миннән шикләнми. Юрага кызыл алмалар алып дөрес эшләдем бит».

Шул көнне Сез миңа кып-кызыл алмалар бирдегез дә: «Боларны Юрикка күчтәнәчкә алып барырсың!» — дидегез. Гади генә итеп әйттегез, әмма минем бәгыремне көйдереп алгандай иттегез. Мин, җинаятем өстендә тотылгандай, кып-кызыл алмалар төсле кызарганымны тойдым. Ярый әле, Сез миңа туры карамадыгыз.

Бу вакыйга минем өчен бөтен гомеремә җитәрлек сабак булды.

Аннан соң да Сез миңа «Юрик өчен» дип күчтәнәчләр бирә идегез, энем янына үзегез дә, Галя апа да еш бара идегез бит.

Сезнең алда олы бурычлымын, Гөлчирә апа. Мин аны кайтарачакмын. Ышаныгыз! Көмеш кашыкларны да Сез биреп торган бурыч итеп кабул итәм һәм түләячәкмен!

Тагын үткәннәргә кайтам... Хәтерлисез микән, безнең гаиләдә вакыйгалар бик тиз алышына башлады. Әни белән сөйләшергә дип, больницадан да, мәктәптән дә, үзенең эш урыныннан да килеп карадылар. Тик һәр килүләрендә исерек әнигә һәм аның чираттагы йолкышына тап булдылар. Әни эшенә дә бөтенләй йөрми башлады. Сез аны заводка үзегезнең янга урнаштырып карадыгыз. Әмма икенче көнне үк анда эшкә чыкмады... Озак та үтми, бүлмәдәге әйберләр дә сатылып бетте. Башта ул алтын йөзек, алтын алкаларын ярты литр аракыга алыштырды, аннан, шкафтагы әйберләр юкка чыкты. Өстәл-урындыклар...

Юра больницадан бөтенләй сәламәтләнеп, тазарып, матураеп кайтты. Ул көннәрдә әни өйдә кунмый иде инде. Аның язмышы, безнең язмышыбыз белән сез — күршеләр, врачлар, укытучылар гына түгел, бөтен җәмәгатьчелек шөгыльләнә башлаган чак иде бу...

Суд көнен хәтерлим. Хәер, Сез дә хәтерлисездер. Шаһитлар идегез ич! Юра белән эскәмияләрнең берсендә утырабыз. Яныбызда — Мәскәү янындагы колхоздан килгән әнинең апасы. Юраның әтисе дә килгән. Хатыны белән. Кызыксынып аларны күзәтәбез. Колакларым кызыша башлады. Җилкәмдә кемнеңдер карашын тоям. Катя апа, алга гына карап утырыгыз дисә дә, тәкатем юк, артка борылам һәм... искереп беткән яшел кофта кигән ябык бер хатынны күрәм.Таныш күзләр... Ходаем, әни, безнең әниебез ич бу! Катя апаның көчле куллары җиңемнән тартты: «Утыр!»...

Суд башланды. Кемнәрнеңдер нәрсәләрендер сөйлиләр... Сөйлиләр... Сөйлиләр... Яшь пәрдәсе белән томаланган күзләрем беркемне дә күрми, кинәт шаулый башлаган колакларым берни дә ишетми. Катя апа җилкәмә кагылып куйды: «Тыңла, Василек!»

— Любовь Ивановнаны ана булу хокукыннан мәхрүм итәргә... Аның улы Василий Захаровны тәрбияләп үстерү өчен Екатерина Николаевнага тапшырырга... Юра Голиковны исә үз әтисе Федор Савельичка кайтарырга...

Кинәт арттан таныш исерек тавыш яңгырый:

— Дөрес эшлисез! Ул балаларның миңа бер тиенгә дә кирәкләре юк.

«Әни!.. Әллә саташаммы, ходаем!» Колакларымны томалыйм...

Урамда безнең янга Федор абый килде.

— Әйдә, улым, Юра, — диде ул.

Мин энемне кочаклап алдым: Юк, бирмим, бирмим мин аны!

— Шулай кирәк, Васек,— диде Катя апа, никтер пышылдап.

Шул мизгелдә мин әнине күрдем. Күрдем дә тораташ булып катып калдым. Әнинең өстендә бер ягы салынып төшкән кара итәк, аягында үкчәләре тапталып кыйшайган туфлиләр... Матур йомры гәүдә урынында озын агач сыман ябык сын. Алсу-ак йөз зәңгәрләнеп каткан.

Аракы... Нишләттең син минем әнине, нишләттең?!

Бу минем әнием түгел! Җен алыштырган аны, җен түгел, аракы алыштырган!..

Ул вакыттан бирле, Гөлчирә апа, алты ел вакыт узды. Менә быел мин, унынчы классны тәмамлап, югары уку йортына да кердем. Агроном булачакмын. Җилдә тирбәлеп җәйрәп яткан бодай, арыш диңгезләрен яратам. Иген үстерә-үстерә читтән торып кына укымакчы идем, Катя апа белән җизни якын да килмәделәр. «Синең җәй көннәрендә

колхозда эшләп алган акчаң ике институт бетерергә җитә»,— диләр. Арттыралар инде анысын! Җизни комбайнчы. Өч җәй рәттән аның ярдәмчесе булып йөрдем. Мактаныйм әле: былтыр урак батыры булдык. Клубта бөтен авыл халкы безгә кул чапты. Җизнине — төсле телевизор, мине мотоцикл белән бүләкләделәр. Катя апа да төшеп калганнардан түгел. Безне (алар миннән башка да өч бала үстерәләр) тәрбияләргә дә өлгерә, үзе колхозның алдынгы сыер савучысы да.

Күрәсез, Гөлчирә апа, матур яшибез. Әмма... Үз-үземнән дә яшерә торган серләремне бүген Сезгә язам. Казанны сагынам. Юраны, Сезне, Галя апаларны, ишегалды малайларын... Юра хатны бик сирәк яза. Гел бертөсле хатлар. «4—5 легә укыйм, әйбәт яшибез», ди. Әни... Инде менә буй житсәм дә, бәләкәй чагымдагы кебек өзелеп «әнием» дип дәшәр кеше житми миңа. Мин әниемне такта кебек кипкән гәүдәле, нурсыз чырайлы, иске-москы кигән хатын итеп түгел, яшь, чибәр, ыспай, назлы итеп күзаллыйм. Нәни чагымда иркәләгән йомшак кулларын сагынам.

Тик минем сөекле әнием бик ерак үткәннәрдә калды шул инде. Ул тормышта ялгыш сукмак сайлады, бәхетен, Сезнең кебек, Катя апалар кебек, хезмәттән, гаилә иминлегеннән эзләмәде, ул үз бәхетен үзе өчен генә яшәүдән, тоташ кәеф-сафа корудан, эчүдән табарга тырышты. Бу сукмак аны кара упкынга илтеп ташлады.

Их, Гөлчирә апа, аның суд вакытында кычкырган сүзләре! «Ул балаларның миңа бер тиенгә дә кирәге юк!» — дигәне ятимлегем авазы булып әле дә колагымда чыңлап тора...

Гөлчирә апа! Үзегез ничек яшисез? Һаман шул эшегездәме?

Әгәр рөхсәт итсәгез, Сезнең янга, Казанга кышкы каникулга килер идем.

Хушыгыз, Гөлчирә апа!

Җавап көтеп, Вася».

...Гөлчирә хатны куйды да уйга калды. Әйе. Ул белгән малай түгел икән бүген Вася-Василек.

Язмышы ни катлаулы булса да, үз юлын тапкан, шуңа сөенде Гөлчирә, шуңа куанды.

Рәйсә Юсупова

БАЛАЛАР ХӨКЕМЕ

Артымнан авыр тимер ишекләр шапылдап ябылып кала. Хезмәт белән төзәтү колониясе диләр бу урынны. Чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынгач, тирә-ягындагы күзәтү каланчаларында мылтыклы солдатлар йөренеп торгач, төрмә була инде ул. Бер гаиләдә тәрбияләнгән бәхетсезләрнең бәхетсезе белән очрашып сөйләшәсе килү теләге китерде мине бирегә. Кемлегемне җиде кат тикшергәч, ниһаять, эчкә ияртеп алып керделәр. Такыр башлы, күкрәкләренә саннар сугылган сырган фуфайкалы тоткыннар каршыма зур тизлек белән килүче кара сөрем шикелле тоела. Бераздан ак халат кигән ханым мин күрергә теләгән яшь кенә егетне чакырып кертте. Ул авырып төрмә больницасына эләккән.

...Әнисенең карынында яткан бер кайгысыз вакытында ук борчыдылар Рамилне. Ике айлык яралгы гына иде әле ул, этисе әнисен хәсрәт уты эчендә калдырып, биш ай буена чит бер хатын тирәсендә чуалды, аннары әйберләрен төйнәде дә өйдән үк чыгып китте. «Бүтән эзем дә булмас бу йортта, мин синнән юньлерәк хатын таптым»,— дип антлар эчеп китте Рәүф. Һәм Биектау районына барып, шул хатынга йортка керде. Әмма, дөньяга килгән ике сабыен итәгенә утырткан Мөнирә ханым инде өченчесен, әле йөрәге янында күтәреп йөргәнен сәламәт табу өчен җаныннан кан булып тамган хәсрәтен җиңәргә тырышкан бер вакытта, ай ярым дигәндә, кайтмаска киткән Рәүфе яңадан бусаганы атлап керде. «Бетмәс монда гулять итәргә ярата торган хатыннар, балаларга алимент түләп, исән хатыным барда читтә яшәп булмас инде»,— дип кайтты. Озакламый кеченә Фәрит белән Фаягөлнең көтеп алган туганы — Рамил туды. Аннары Равил дөньяга килде. Инде шактый ишәеп барган гаиләдә тагын бер җан артты: анысы — авыру мамае тарафыннан кыйналып, урамга куылган ялгыз карчык — Бәян әби (алар аны Бәян тәтә диләр) иде.

Әнә шулай 31 ел бергә гомер иткәч, көннәрнең берендә Рәүф тагын китеп бара Тәмтедән. Бу юлы язмышы аны атаныннан, гаиләсеннән байтак еракка, Актаныш районының Байсар авылына илтә. «Инде үлсәм дә, картлык көнемдә урамда калсам да, әйләнеп кайтасым юк», — дип китә. Бер чемодан әйберен җыйнап, ул яшь хатын янына юнәлә, ә биш көннән соң өченче улы — Рамиленә суд булачак. Әле егерме яшькә генә җиткән егет инде дүртенче мәртәбә

ирегеннән мәхрүм ителә. Монысында хезмәт белән төзәт колониясенә өч елга эләгә...

— Әнкәй миңа: «Балаларыңны үстермичә гаиләңне таш лама, сабыр ит, аннары китәрсең», — дигән иде. Шуңа кайттым мин теге чакны. Инде менә, барысы да үсеп, ба лигъ булдылар, үз тормышларын кора башладылар. Аларга әти ярдәме кирәк түгел хәзер, — ди Рәүф Вафин. — Яратып өйләнмәдем,— дип дәвам итә аннары.— Җиде ай бергә яшәгәч тә, бозылды безнең татулык. Гомерем буена көткән кешемне эзләдем. Һәм менә таптым мин аны. Куып чыгара икән, ишегә төбендә ятармын...

Мөнирә ханым да ирен яхшы сүз белән искә ала алмый:

— Яраткан егетем армиядә иде. Урлап алып китте ул мине. Мин аннан өч яшькә өлкәнрәк. Шулай да ул: «Теләгемә ирештем, сине үземнеке иттем»,— дип кат-кат кабатлады. Өйләнешкәннән бирле хатын-кыз белән чуалды, баш күтәрмичә эчте, йорт эшенә кулын тыкмады, балаларга юньле тәрбия булмады. Шулкадәр интегеп, җәфа чигеп яшәлде. Кеше арасында хурлык, балаларга гарьлек...

Мөнирә ханым ирен югалту хәсрәтенә түзә алмагач, аның яңа гаиләсе яши торган районның «Игенче даны» газетасы редакциясенә хат яза, мәкалә бастыра, үзе барып кайта, «Иремне кайтарып бирегез», — дип, КПСС райкомына хәбәр җибәрә. Ә берникадәр вакыттан соң шул ук газета битләрендә ире Рәүф Вафинның җавабын урнаштыралар.

Нинди гаилә соң бу? Ник яшьлекләрен бер-берсеннән канәгать булмыйча үткәргәннәр дә, картайган көннәрендә Тәмте авылы халкын гына түгел, чит район кешеләрен дә көлдерәләр, нәфрәтләндерәләр? Ник, учлап борчак чәчкән шикелле, бер-берсенең яманатын чәчәләр? Балалары, оныклары белән гөрләшеп яшисе урында, нигә аларның — болай да бәхет күрми үскән Фәрит, Фаягөл, Рамил, Равилнең йөз аклыкларын урлыйлар?

Бу гаилә язмышы турында белгән кеше иң элек: «Гаеп кемдә икән: ирдәме, хатындамы?» — дияр. Берәүләре: «Юньле хатыннан ир китәмени?»— дисә, икенчеләре исә: «Юньле ир картайган көнендә гомер иткән гаиләсен, балаларын ташлап китми, нигә элегрәк, дүрт бала туганчы уйламаган соң?» — дияр. Ике төрле фикер. Ике төрле хаклык. Беренче карашка шулай тоела. Әмма сорау туа: бу ике кеше арасында гаилә бөтенлеген саклардай мәхәббәт булганмы соң? Август Бебельнең бу мәсьәләдә кызыклы фикере бар: «Бер-берсен яратмаган ир белән хатынны бергә торырга мәҗбүр итеп кенә бәхетле итеп булмый. Алар-

ның аерылышуын закон тарафыннан тыю — әхлаксызлык ул». Фридрих Энгельс та нәкъ шулай уйлаган: «Җәмгыять өчен дә, үзләре өчен дә аларның аерылышуы мәгъкуль», — дигән.

Гаеп кемдә генә булса да, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрдә казыну, аларның кимчелекләрен дөньяга фаш итү, бер караганда, дөрес тә түгел кебек. Аларга үгет-нәсихәт биреп тә, алар арасындагы сүнеп көлгә әверелгән мәхәббәтне (мәхәббәт хисе булмаган булса,— бигрәк тә!) яңартып та, таркалган гаилә учагын яңадан тергезеп тә булмый. Һәрхәлдә, моңа иң югары фикерле адәм баласының да, иң камил компьютерларның да көче-кодрәте җитә торган түгел. Әмма гаилә бөтенлеге, минемчә, ир белән хатынның шәхси эшенә генә дә кайтып калмаска тиеш. Әхлакый тазалыктан башка, аның икенче ягы: балалар язмышы — тормышны дәвам итәргә сәләтле, сәламәт акыллы, җәмгыять өчен файдалы балалар язмышы да бар бит әле. Менә монысы инде шәхси кысалардан чыгып, җәмгыять интересларына, дәүләткүләм әһәмиятле проблемаларга барып тоташа...

...Санаторийга киткән җиреннән мәхәббәт хисләренә исереп кайткан Рәүфнең тынычлыгы тәмам югала. Моннан унбиш ел элек ире авырып үлгән Илгинә исемле хатынга гыйшкы төшә бу юлы. Хатлар да язып карый, берничә мәртәбә ул яшәгән төбәкләргә дә барып кайта.

— Андый хатыннарың күп булды инде, тора-бара оныттың. Бусын да онытырсың әле, картлык көнең турында уйла бераз. Урамда калсаң, кем сыендырыр үзеңне. Яшь чагың түгел бит,— дип үгетли Мөнирә Рәүфне, сөяркәсе янына китәргә җыенуын сизеп.

Үз гомерендә читләр тирәсендә аз бөтерелмәгән иргә мондый сүзләр үтәме? Юк, әхлак нормаларында тота алмады ул ирен. Тырышты. Әмма тырышулары бушка иде. Элек тә ял йортларыннан күңеле иләсләнеп кайта иде Рәүфнең, йөргән җирендә очраткан хатын-кызлар да аның күңелен кытыклап торды. Иренең мондый нәфесен белгәч, Мөнирә башта үзе генә эзләргә чыкты. Балалары үсә төшкәч, алар белән «ауга» йөрде. Әйе, әтиләренең чуар йөрәкле булуын сабыйлар бәләкәйдән белеп, күреп үстеләр.

— Икенче класстан бирле аңымны югалтам, йөрәгем, ашказаным еш борчый,— ди Фаягөл.— Ә әтинең безгә күрсәтмәгәне калмады. Әйбәт кеше булса, әйбәт дияр идек. Ни дисәң дә, безнең әти ич. Фәрит абыем хәзер Үзбәкстанда яши. Анда рәхәт күрермен дип ашкынып китмәде. Әти аркасында... Куып диярлек җибәрде ул аны. Менә хаты...

«Әтигә хат язган идем, каршы язмады. Ул миңа хәзер әллә бар, әллә юк...» дигән юлларны укыгач, йөрәкләр чемердәп китә. Исән килеш, сау-сәламәт килеш бала атадан йөз чөерсен әле?!

Әтиләре киткәч, Фәрит җәй көне гаиләсе белән авылга кунакка кайткан булган. Бик күрәсе килеп, телеграмма суккан үзенә. «Мине борчымагыз», — дип җавап биргән ата кеше.

«Оясында ни күрә...», ди халык мәкале. Атаның «авыруы» балалар язмышында кайтаваз булып яңгырый. Фәрит тә үз гаиләсен кора алмыйча аптыраган. Бер бала белән беренче хатынын ташлап, икенчегә өйләнгән. Бүген әнә читт-ят якта, дәү әтисе белән дәү әнисеннән еракта, Башкортстанда Вафиннарның тагын бер ятиме ата назыннан мәхрүм үсә.

Фаягөлнең гаилә тормышы да чәлперәмә килгән. Җиде ел бергә яшәгәч, ике малаен алып, эчкече иреннән аерылган. Әтиләреннән башка нинди тәрбия бирелер ул балаларга? Нинди шатлык яки кайгы-хәсрәт китерер әтисез үскән бу балалар аңа? Җәмгыятькә файдалы кешеләр итеп тәрбияли алырмы аларны авыру хатын?

— Әтинең, никадәр юньсез, тәрбиясез, шакшы кеше булса да, өйдән китүен бик авыр кичердек,— ди Фаягөл.— Ул безнең өчен мәңгегә юк, үлде, таптый-таптый күмеп куйдык без аны. Тереләй күмдек... Без аның бидонлап ачыткы ясавы турында да, көн саен эчеп, өйдә кара тавыш чыгаруы турында да кешегә әйтергә, эш урынына җиткерергә оялдык. Коммунист бит ул, билетлы эчкече... Бигрәк тә төрмәдәге энемне кызганам.— Фаягөл тыела алмыйча елый. Көч-хәл белән тынычландырам.— Кечкенәдән үк тукмактан башы чыкмады шул баланың. Шуңа да холыксыз булды инде ул... «Миңа тәрбия юк, атналар буе рәтле ризык ашатмыйсыз, ихтирам-хөрмәт итмисез»,— дия иде әти безгә дә. Әнине ничек мыскыллаганнарын күрмәс өчен асылынып үләсе килгән чакларны үзем генә беләм...

Мөнирә ханымның үзен өйдә очратып булмады, больницада күрештек аның белән. Өйдә 81 яшьлек Бәян тәтә генә табык чистартып йөри иде. Ник килүемне белгәч, йорт хуҗалары турындагы авыр хәсрәтне сөйләп бирде. Рәүфне эттән алып эткә салып сүгәргә ашыкмады. Ни әйтсәң дә, алар аны 23 ел буена үз куышларына сыендырып, туганнарыннан артык күреп яшәткәннәр. Әмма карчыкның күз карашында гаилә башлыгына карата җылы хис, миһербанлык әсәре сизелми, туң салкынлык, тирән чоңгыл ча-

ыла иде. Рәнҗетеп киткән ул аны, тел ярасы белән яралап киткән.

— Мөнирәнең кин күңеленә сыя алган идем, үзе генә сәламәтлеккә туймый. Больниста ята,— диде Бәян тәтә.— Бакчада эшли бит ул, авыр кәрҗиннәргә тутырып миләш җыйганнар, көч килгән. Пенсиягә дә күп калмаган иде инде.

Ул арада кече уллары — Равил кайтты. Бер иптәше белән иделәр. Әзмәвердәй озын буйлы егет ял көне дип, өйдә эш таба алмыйча йөридер кебек тоелды. Күңелгә шунда ук: «Их, менә шушы йорт тирәсендә балта, чүкеч белән эш килсә яки менә бу ватык мотоциклны ремонтлап сарайга куйса», — дигән уй килде. Йорт таштан зур итеп салынса да, биредә ир кеше яшәмәгәндер сыман: ишегалдында агач-тактага, тимер-томырга абынып яки урап үтмәле, капка юк, коймалар ярым җимерек. Әтиләренең кадак-чүкеч тотарга өйрәтергә вакыты җитмәгәндер шул. Равил үзе кызыксынуыма каршы:

— Казанда химия-технология институтында укыган җирдән кайттым,— ди.— Өйдә кеше калмады бит. Әнигә мораль яктан булса да ярдәм итәрмен дидем, эшкә дә урнаштым. Барып әтине күреп кайтасым килә. Ничек яши икән, эчмичә түзә ала микән?

Гаилә башлыгы Вафинны нинди картлык көтә. Шул начар хатыны, кадерсез балалары бусагасына кайтып егылмасмы ул, — дип уйладым әлеге гаилә тарихын тыңлаганда.

Аның икенче хатыны (законлы булмаса да) бәлки бик яхшы күңелле, ирне ир итә белә торган, игътибарлы кешедер. Һәрхәлдә, авылда да, районда да аны белүчеләрдән начар сүз ишетмәдем. Өендә, ихатасында да Вафиннардагы шикелле хуҗасызлык, җыйнаксызлык юк. Өч баласына да ялгыз көе яхшы тәрбия биргән, югары белемле иткән, олыларга хөрмәт белән карарга өйрәткән.

Мин барган көнне Илгинә ханымның шәһәрдә яшәүче олы улы Айрат кайтып керде. Бусаганы атлауга ук үги әтигә дигән бүләген дә чыгарып бирде. Вафинга исә шул җитә калды, күрәсеңме, дигәндәй, горур утыра: «Минекеләрдән кулъяулык та тәтемәде»,— ди.

Кулъяулык та бирмәслек итеп аларны кем тәрбияләде соң? Әлеге сорауга җавап бирүче юк бу йортта. Илгинә ханым да, аның егерме сигез яшьлек улы Айрат та бу кешенең алар нигезенә үз гаиләсен җимереп килеп керү турында да уйламыйлар...

...Артымнан авыр тимер ишекләр шапылдап ябылып ка-
ла. Хезмәт белән төзәтү колониясеннән чыгып киләм. Ко-
лак төбемдә Рамилнең һәр сүзе тимер чыңлавыдай чың-
лап тора.

— Әни борчылмасын иде, мин ул кадәр нык авыру тү-
гел, — ди Рамил. — Үземне белә-белгәннән бирле әти эчте,
көн саен кычкырыш-талаш тынмады. Барысын да әти чы-
гарды. Үземә көч кергәч кенә, мине кыйнаудан туктады.
Әле Равил килгән иде: «Бик рәхәт әти булмагач, ты-
ныч»,— ди. Минем язмышыма әти гаепле, үзе кыстап эчер-
тә иде... Бакча эшеннән башка бүтән шөгыле юк иде, өйдә
нидер эшләгәнен күрмәдек, безгә дә өйрәтмәде. Әни кызга-
ныч. Бәхетсез үткән яшьлеге кызганыч...

«Ә синең яшьлегең?» дип, төрмә бикләрен ватардай итеп
кычкырасым килде шул чакта. Тавыш чыкмады. Шалтырап
төшкән келәләрнең тавышы, мылтыклы сакчы солдатлар-
ның үтергеч күз карашы күмеп китә төсле иде аны. Төрмә-
дә утырган газизләренә күчтәнәч, хат китерергә килгән
төенчекле хатыннар, аналар һәм балалар гына артымнан
«Бер бәхетлесе янына көрешергә кертсәннәр бит әнә»,—
дип көнләшеп калалар сыман. Ә минем башта ми күзәнәк-
ләрен ерып-тырмап мең төрле сорау, нәфрәт, борчылу хисе
айкала. Күз алларым караңгыланып китә дә каршымнан
бер-бер артлы шушы гаилә бәхетсезләре үтә кебек...

Әлфия Саматова

ӘТИ КЕШЕ ХАК ДАУЛЫЙ

Менә тагын көзнең салкын, яңгырлы көннәре килеп җит-
те. Урамга чыксаң, карлы җиле сөякләргә үтә. Аяк астын-
дагы балчык, тышау сыман сарылып, атларга ирек бирми.
Шуңа күрә һәркем, тыштагы эшен тиз-тиз тәмамлап, җы-
лы өенә ашыга. Кичке табын көнозын күшегә-туңа эшләп
йөргән гаиләне үз тирәсенә җыя. Урамдагы шыксызлыкны
оныттырып, һәр өйгә күңелле җанлылык, нур иңә. Тик ме-
нә бу йортны — кыйгач тыкрык буендагы Фәйзерахманов-
лар өен өченче көз инде күңел өшеткеч салкын яктылык
урый.

Әрхәметдин абзыйга беркая да ашыгасы юк. Капка ба-
ганасындагы буш сыерчык оясы сыман аның тын өенә дә
килүче һәм китүче юк. Язгы тамчылар уянуга, сыерчык оя-
сы тагы дәртле җырга күмелер, әмма Әрхәметдин абзый

йортына язлар да нур, ямь алып килергә вәгъдә итми. Ул япа-ялгыз. Өйгә кергәч, күзе түр стенага төбәлә. Анда яшь чакта хатыны белән парлап төшкән, зурайтылган фоторәсем эленгән. Аңа карап сагышлы уйга тала Әрхәметдин абзый. Элеккеге шау-гөр килеп торган табынны күз алдына китерә. Хатынын, балаларын сагына.

Әрхәметдин абзыйның редакциягә язган хатыннан:

«Тормыш иптәшем Зәйтүнә белән 32 ел гомер иттек, 6 бала үстердек. Малайларым да, кызларым да, Казанда уку йортларында укып, дипломлы белгеч булдылар. Тик аларның берсе дә авылда түгел, чит җирләрдә эшлиләр. Ә 1982 елның январенда хатыным да, миңа әйтмичә, качып китте. Шулай итеп, авылда ялгызым яшәп калдым.

Нихәл итим, барысын да сагынам. Быел җәй, күреп кайтыйм дип, улларым яши торган Чаллы шәһәренә барган идем. Телефоннан башта кече улым Рафаэльнең квартирасына шалтыраттым. «Килгән юлыңны беләсең, безгә кермә, кайтып кит», — диде. Аннары олы улым Рафиска бардым. «Ник килдең, нәрсә бар монда сиңа?» — дип җикерергә тотынды. Песигә биргәндәй ашарга көйләде. Тамагымнан үтмәде. «Әйдә, бар, тизрәк кайтып кит», — дип, куып чыгарды... Алар яхшы киемле булгач, мине күрәселәре килмәде. Миңа аларның бер юл хат язганнары да, ике тиен акча, күчтәнәч, бүләк җибәргәннәре дә, үзләре кайтканы да юк.

Минем әнием дә карады бит ул алты баланы. Үзем дә балалар укыган вакытта аларны ач тотмадым, булдыра алганча өсләрен карадым.

Кая боларда тәрбия нәтиҗәсе? Алар да картаймас микәнни?».

Әрхәметдин абзый үзенең язмасын «Шәфкатьсезләр» дип исемләгән. Бу хатны укып чыгуга, күз алдына рәнҗетелгән ата килеп баса, аңа тизрәк ярдәм итү теләге туа. Шуңа күрә башта аның үзе янында, Яңгул авылына ашыктык.

Әрхәметдин абзый 69 лар тирәсендәге кеше. 1950 елда ул озын сроклы хәрби хезмәттән кайта. Ул елларда армия сафларындагы егетләр илебездә сугыш калдырган җимерекләрне төзәтәләр. Алар җилкәсе потларны гына түгел, центнерларны күтәрә. Зарланырга вакыт юк. Әрхәметдин исә авыр күтәрүдән башланган чирен яшерә. Үтәр әле дип уйлый.

Авылга кайтуга, солдат гадәте буенча хат аша танышкан Зәйтүнә белән гаилә корып җибәрә. Әмма егет чакта башланган авыруы тынгылык бирми Әрхәметдингә. 1954 елда участок врачына күренергә мәҗбүр була. Аңа артык

авыр күтәрүдән, озак утырып эшләүдән сакланырга киңәш итәләр. Әрхәметдин югалып кала. Ихтыяр көчен туплап, тормыш дилбегәсен акыл белән, сабыр гына тартасы урынга эчүгә сабыша.

Гаиләдә бер-бер артлы балалар арта. Әрхәметдиннең әнисе Әсма карчык та, дөм-сукыраеп, килене тәрбиясендә кала. Ә Әрхәметдин эчүен ташламый. Аның каравы эшне берсен башлап, берсен ташлап йөри башлый. Балалар үстерергә хатынына ни материаль, ни мораль ярдәме тими. Эчүдән чире һаман көчәя барган саен, эти кеше ныграк холыксызлана. Аек чакта гарьлегеннән үзенә урын тапмый. Ә эчсә, үчен гаиләсеннән кайтарырга тырышып гайрәтләнә, явызлана, тавыш куптара. Хатынына, балаларына кул күтәрүдән, балта, пычак белән янаудан да тартынмый. Гаиләнең сер сандыгы бик тирән була. Һәм ул һәрчак йозакта тора. Өйдә нинди генә давыл купса да, аны урамга чыгармаска, кешегә сиздермәскә тырышалар. Тик авыл күзеннән кеше тикле кеше язмышын яшереп буламы соң? Урамда исереп аунап ятмаса да, Әрхәметдиннең эчкәнен дә, эшсез йөргәнен дә беләләр.

Әйе, артык сабыр була шул Зәйтүнә апа. Балалар йортында эшләгәндә, үксезләрнең моңсу карашлары күңелен телгәли аның. Аларга ана җылысы, ана назы бирергә тырыша, әмма малайларның эти кочагы, эти карашы, эти кулы, эти киңәшенә мохтаҗлыгын тоеп йөрәге сыкрый. Шуна күрә дә, үз гаилә газабы чигеннән ашкан чакларда да, балалар хакына Әрхәметдинне ташламады да, кумады да. «Эти» дигән сүзне бер әйтергә зар булып үсмәсеннәр диде.

«Каенанасы Әсма карчыкка да картаймыш көнендә улыннан-кызыннан күрмәгән тәрбияне күрсәтте Зәйтүнә»,— диләр авылда.

Гаиләнең ишле, тормышның мәшәкатьле елларында салынган йорт тирәли алмагачлар күкрәп үскән. Монда бүген Әрхәметдин абзый белән Зәйтүнә апа тыныч кына, матур гына гомер кичерергә тиешләр иде югыйсә. Олыгаеп барган ата белән ана өчен ял саен, бәйрәм саен ул-кызларын, оныкларын каршылап, кунак итеп озатудан да бәхетле тормыш булырга мөмкин идеме соң? Тик Әрхәметдин абзый бу бәхеттән мәхрүм. Ул япа-ялгыз.

Зәйтүнә апа балаларының берсендә яши.

Абыйлы-энеле Рафис һәм Рәсил белән Чаллы шәһәрендә очраштык. Алар белән сөйләшкәндә, икесенә дә нәкъ менә ата тәрбиясе, уртак гаилә тәрбиясе эләкмәве ачык чагыла. Әдәпсез рәвештә, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, әтиләрен яманлыйлар алар. Рафис (өлкәне) КамАЗ берләшмәсе

...роләренең берсендә житәкче, кешеләр язмышы өчен ...лы урында эшли. Әрхәметдин абзыйның хаты ту...нда сүз башлагач, кызып китте: «Тагын шул «сорыкорт» ...е белән йөрисез икән әле. Гомумән, андый хатларны ...шереп йөрергә, газетага язарга хакыгыз юк. Беләм мин, ...дый хатларны урынга җибәреп тикшертәләр. Үземә дә ...ыльләнергә туры килгәне бар... Элегрәк, без исерек бе...н җәфаланып үскән чакта, килеп тикшереп язарга ...рәк иде сезгә... Әнә, укытучым белән сөйләшегез, ул белә ...шем ничек үскәнне. Бервакыт муенымдагы эти буып кү...рткән биш бармак эзен күреп: «Әллә асылынган идеңме ...ш, Рафис?» — дип сорады... Кешеләр этиләренең хезмәте, ...е турында горурланып сочинениеләр язганда, безнең ни...к кимсенгәнне күз алдына китерә аласызмы соң сез? Әгәр ...л безне суд аша үзен тәрбияләргә мәҗбүр итә икән, өйнең ...ер почмагында урын табарбыз, тик якты чырай күтмәсен. ...атериаль яктан гына ярдәм сораса, хәл итәрбез. Без ал... бит әле. 60 яшь тулган көненнән ай саен билгеле бер ...үләмдә акча җыеп җибәреп торырбыз».

Әйе, егетләрнең икесе белән дә сөйләшергә авыр иде. ...дәплерәк сөйләшүләрен үтенеп, аларны еш бүлдерергә ...ры килде. Ә әниләре Зәйтүнә апа алар каршында сүз әй...ргә дә куркып утырды. Иренең язмышы өчен дә, балала... өчен дә борчылып ике ут арасында яшәвен аңладык без ...йтүнә апаның. Китәргә саубуллашкач, артыбыздан чыгып:

— Бөтенләй авырып китеп, аяктан егылса, үзем исән ...акта кайтып карармын, тәрбияләрмен мин аны. Әмма хәзер ...эчмим» дип ант итсә дә, кайтмыйм. Сүзендә тормый. Сы...ап карадым инде, — диде ул.

Рафис йортындагы бу сөйләшү күңелдә авыр тәэсир ...алдырды. Бу ир-егетләр әниләрен дә олылый, хөрмәтли ...елмиләр икән, дип уйлыйм мин. Нәрсә турында гына сүз ...ашласалар да, «мин үзем», «без үзебез» дип кабатларга ...раталар. Әниләренең өлеше, хезмәте, тырышлыгы турын...а ник бер җылы сүз әйтсеннәр. Әлбәттә, балалар (аеруча ...алайлар) әнигә яхшы мөнәсәбәтле булырга этидән өйрә...ергә тиешләр иде шул... Ир-ат тарафыннан анага карата ...ын мәгънәсендә ихтирам булган гаиләдә генә әдәпле ба...алар үсә.

Чаллыда булган сөйләшүдән соң күп үтмәде, редак...иягә Свердловск өлкәсеннән тагын бер хат килеп төште. Монысын Фәйзерахмановларның иң олы кызлары — Дами...э язган.

«Сез безнең гаилә турында газетага язарга уйлыйсыз ...кән. Мин бөтен дәреслекне язуыгызны үтенәм. Безнең

эти — Фәйзерахманов Әрхәметдин инде күптән эчкәне өчен эштән куылды. Колхоз дәваларга җибәрергә теләгән иде, әни каршы булды. Бу саулыгы белән аннан әйләнеп кайта алмый ул, шунда җибәреп үтертте диючеләр булыр диде. Без кечкенә вакыттан ук төннәр буе йокламыйча, әтидән качып йөри идек. Мин әнигә гел әйтеп елый идем: «Чыгыйк инде, әнием, тау куышында булса да яшәрбез», — дип. Гел тавыш (балта-пычак та әтинең кулында еш уйный иде) юкка булмады, күрәсең. Миннән кече энем — Рафис тиз кызып китүчән. Үзе бик яхшы күңелле, акыллы ул. Әти йөри алмас хәлгә килсә, үзе үк аның янына йөгереп кайтачак».

* * *

Мәгънәсез тормышы белән хатынының, балаларының жанын биздергән Әрхәметдин абзый бүген төрле юллар белән шушы кешеләрдән хак, хөрмәт даулый. Төн җиттеме, хәтер ярлары тулып ташый башлый аның. Шомлы тынлыкны селкетеп, морҗа торбасыннан улаган җил тавышын басарга теләп, күңеле белән кемнәрнедер тиргәргә, үпкә-рәнҗешләрен яудырырга тотына. Ялгызлыктан ярсыган күңелгә шуннан башка чара, дәва юктыр шул хәзер. Үткәннәрне кире кайтару да юк.

Язилә Абдулкадыйрова

ГОМЕР КӨЗЕҢ НИНДИ БУЛЫР?

Тагын көз җитте. Быел аны кинәт килде диләр. Табигатьнең котылгысыз законы: язларны җәйләр, җәйләрне көзләр алыштыра. Нәкъ кеше гомере кебек: балачак, яшьлек һәм... картлык. Гомер көзен кем генә сагынып көтеп ала икән? Көзләрнең дә үзенчә җәйне хәтерләткән җылы, кояшлылары һәм быелгыдай салкын, яңгырлылары булган кебек, картлык та төрлечә була: ихтирам-хөрмәт белән уратылганы, ялгызлыкта, йөрәк әрнеткеч кадерсезлектә үткәне. Бу очракта сүз соңгысы турында бара.

Моңарчы күргәнем булмаса да, мин аны шунда ук таныдым. Бөтен килеш-килбәте аның ялгыз, караучысыз яшәве турында сөйли: тузып-тетелеп беткән өс-баш, бәрелеп-сугылып зәңгәрләнгән бит-куллар, бөршәйгән гәүдә. Хәлсез кулларына чәйнек тоткан сиксән өч яшьлек Әсма әби, көзге пычракны көч-хәл белән ерып, суга бара иде.

Бөтенләй чит-ят кешенең исемен дөрес әйтеп, хәл-әхвәл сорашуы азрак гаҗәпләндерде бугай үзен. Чәйнегең күтәрешкәнем өчен ул нишләргә дә белмәде:

— Әй, бәбкәем, рәхмәт яусын сиңа, балаларыңның игелеген күр...

Минем үтеп баручы гына булмавымны, аның язмышы белән кызыксынып Казаннан килүемне белгәч, Әсма әби бөтенләй аптырады. Чит кешенең шундый кайгыртучанлыгын башына сыйдыра алмый иде карчык. Һәм кинәт кенә, нидер исенә төшкәндәй, сорап куйды:

— И, канәтем, безнекеләрне күрмәдеңме анда? Нишләп яталар икән? Кайчанрак кайтырлар икән?

Нәрсә дип җавап бирергә күземә туп-туры карап утырган әбигә? Балаларыңның сине бүтән карыйсылары килми, кайтырга уйларында да юк, дияргәме? Казандагы ике кызың белән бер улың арасында сине кем карарга тиешлеге турында ызгыш-талаш бара дияргәме?

Аның улы янында булган авыр сөйләшү әле һаман да күз алдымда тора. Ни өчен килүемне белгәч, Нурый Шәмсетдиновның беренче сүзе мондый булды:

— Ну и что!..

Мондый ук катгыйлык көтмәгән идем, бермәлгә сүзсез калдым.

— Нишләп әле сез аны миңа тагасыз, ә? Мин үзем дә, беләсегез килсә, икенче группа инвалид. Халидә дә алтмыш ике яшендә, ыңгыр-шыңгыр гына йөри. Анаңны алып килсәң, икегезне бер ишектән куып чыгарам, ди.

Ул сөйләде дә сөйләде, әйтерсең сүз базардагы бәяләр турында бара иде. Ышанасы килми: дөньядагы иң газиз кеше — ана турында менә шулай итеп сөйли алучылар да бар икән! Бер кисәк ипигә тилмергән чакларда тудырып үстергән әнисенең бүген кыш чыгарлык җылы өе, тамагын туйдырырлык ризыгы, өстенә кияргә киеме юклыгы инде үзе дә ике бала атасы булган, алтмышынчы яше белән баручы кешене ничек битараф калдыра ала икән?!

Күңелендә аз гына булса да шәфкать, мәрхәмәт хисе бардыр дип, әнисенең аяныч хәле турында җентекләбрәк сөйлим.

— Сез миңа мораль укымагыз, яме, мин үзем дә булдырам аны. Үстергән — рәхмәт, карамадым түгел, карадым, аңа җибәргән акча квитанцияләрен күрсәтә алам, мин аннан инде гарык, җитте.

— Үзегез теләп ярдәм итмәсәгез, әниегезнең сездән алимент түләтергә хакы бар.

— Бугазы тыгылсын, биш-ун сумнан да артык ала ал-

маячак ул убырлы. Егерме биш процент бирмәячәкмен — мин инвалид, икенче группа...

Бу инде сөйләшү түгел, ә җәнҗал иде. «Алимент» сүзе аны бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Әйе, минем алда утыручы чыннан да инвалид икән. Әхлакый инвалид һәм икенче группа гына да түгел.

Ишек төбенә җиткәч, кинәт туктап калдым. Әле генә пыр тузып кычкырынган хуҗа бөтенләй икенче кешегә әйләнгән иде.

— Аңлагыз мине,— диде ул ялварулы тавыш белән.— Кертер дә идек без аны, карагыз, ике гаилә торабыз, өч бүлмәле квартирада. Күршеләр үзләре генә дә дүртәү, бишенчегә кыш чыгарга әниләрен алып киләләр. Менә өчесе дә безнеке булса, берсүзсез кертер идек...

— Алар шул кечкенә генә бүлмәгә дә бишәү сыялар, ә сез ике бүлмәне дә азсынасыз.

— Нишләп безгә каныгасыз әле сез, ә? Ярар, чәнчелеп китсен, мин аны бер айга кертергә риза. Тик белегез: кышын урамда туңып үлә калса, мин җавап бирмәячәкмен, шулай дип язызгыз.

Хуҗа артымнан ияреп чыкты. «Кирәкми» дисәм дә үзләреннән ерак түгел генә торучы сеңлесенә озатып куярга булды. Күрәсең, сеңлесе артык сүз сөйләр дип шикләнгәндер. Юл буе «карчыкны» (ул ялгышып кына булса да «әни» дип әйтмәде) сеңлесе Исламия яки Миңнурый карарга тиешлеген тәкрарлады.

— Ул-бу булып, ялгызыгыз гына калсагыз, нишләр идегез? — дип сорадым мин аннан.

— Ә мин алай калырга ашыкмыйм, әлегә сәламәтлегем аллага шөкер, пенсиям йөз егерме сум.

— Балаларыгызга барыр идегезме?

— Бу заманда балалардан кем игелек күргән, бармыйм да, ярдәм дә сорамыйм, алар үлгәндә авызыңа бер кашык су да салмаячак.

Әсма әбинең кече кызы Исламия Бакиеваның да «көчле» дәлилләре бар иде:

— Өч кеше өчен берүзем эшлим, бүлмәм кечкенә, «аны» карарга аерым кеше кирәк, аннары үзе бик усал, теленә ни килсә, шуны әйтә, күңелне кайтара...

Моннан ярты сәгать кенә элек иң соңгы сүзләр белән сеңлесенең тетмәсен теткән абый кеше аның һәр сүзен: «Әйе шул, мин дә шулай дим, Исламия карый алмый, әшәке телле, тиле ул карчык»,— дип җөпләп утырды, әбинең бары тик икенче сеңлесе — Миңнурый гына карый алачагы турында сөйләде. Ул арада баласын ияртеп, әбинең

...ы тиешле Лилия кайтып керде. Сүзнең ни турында ...ылыгын аңлагач, онык үз фикерен кистереп әйтте:

— Безгә дә кирәкми, мин ул ведьманы урамга куып ...рам, квартирантлар тотканчы, пусть малае карасын, ... кызы.

Тагын тавыш-гауга купты. Бүлмә үзара мәсхәрәләшү... ...чмьсез сүзләр белән тулды. Янәшәдә генә кемгә ка... ..., кайдан яклау эзләргә белмичә, ике яше дә тулма... сабый бала басып тора, ә бу вакытта Исламия әнисенә ...ргәткән яхшылыкларын бармак бөгә-бөгә саный иде:

— Таксига туксанышар сум түләп, Көрнәлегә ике мәр... кайттым мин...

Әйе, ул февраль суыгын Исламия Бакирова гына тү... Коры Көрнәледә яшәүче Әсма әби дә, аның тирә-күр...ләре дә бик яхшы хәтерлиләрдер. Туңудан, тамагына ...ле-рәтле ризык кермәгәнлектән, үләргә яткан әбине ...шеләре үзләренә алып чыгалар, карыйлар, хәле әйбәт...мәгәч, балаларына телеграмма сугалар. Берне, икене, ... Ниһаять, кече кызы кайтып төшә һәм күршеләргә җи...ренә башлый: «Ил өстендә чыпчык үлми, үлсә, күмгән ...ыр идегез әле, ник безне аптыратасыз».

Авыл халкы Исламиянең бердәнбер кызы Лилиянең ...чек итеп үз әбисенең җыелып килгән 150 сум пенсия ...часын тотып бетерүен дә, эчеп-исереп кеше мәсхәрәсе ...улып йөрүен дә хәтерли. Ә соңгы яшәү чыганагыннан ...рум ителгән Әсма әби, оныгы киткәч, авыл буенча со...ып йөрергә мәҗбүр була. Ахыр чиктә Исламия Әсма ...не үзләренә алып китә. Авылдан пропискадан төшерт...реп, пенсиясен үзенә күчереп. Кече кызының шәфкать...злеген белгән күршеләр шикләнеп озаталар әбине: «Ай...й, ничек яшәр ул анда»?! Һәм, чыннан да, озак тора ...мый ана кызы янында. Җиңел тормыш белән яшәргә ...нгән Лилия Бакиева карчыкны берничә мәртәбә урам... куып чыгара, төрлечә кимсетә. Әсма әби улы Нурыйга ...ырга уйлый. Нурыйның җавабы кыска була: «Мин ... балконнан бәрәчәкмен». Бу очракта да Исламия ча...сын таба: төенчеген култыгына кыстырган әбине җил...реп апасы Миңнурыйга илтеп ташлый. Әсма әби ул ...ны шунда чыга. Июнь аенда тагын авылга кайтара... Алты ай җыелган пенсия акчасын шул ук төпчек кы... тотып бетерә.

Авылдашлары әбинең олы кызы Миңнурый турында ...й диләр: «Ул моңарчы ярдәм итеп торды, утынын да ...рләште, киемен дә бирде». Барысы да үткән заманда. ...лә бу кызы да әнисе турында онытканмы?

— Онытмадым, юк,— дип сөйләп китте Миңнурый Закирова.— Төннәрен әнинең язмышын исемә төшереп курккып уянам. Нинди хурлыкка калдык бит, бер әнине сыйдыра алмыйбыз...

Күцелгә бераз җиңелрәк булып китте. Ниһаять, «әни» сүзе ишетелде.

— Быел кыш чыгарга алып килүгә ирем каршы,— диде ул.— Чиратлашып карыйк дидем абый белән сеңлемә риза булмадылар, баш тарттылар. Ә Самат әйтә: «Ни өчен әле ике баласы карамаганны, мин карарга тиеш?» — ди. Үзем пенсиядә, ике кызыбыз да укыйлар, кыш чыгарга иремнең әнисе килә...

Кыскасы, Әсма әби биредә дә сыймаячак.

...Тагын көз җитте. Көр рухлы, киләчәктә әле бик күп чәчәкле язларны, ямьле җәйләрне каршылаячак яшьләр өчен бу — елның бер фасылы гына. Ә Әсма, Нәкыя әбиләр өчен бу — гомер көзе. Коры Көрнәледә чагында мин шуны ачыкладым: биредә яшәүчеләрнең өчтән бере пенсия яшендә икән. Алар да киләчәк көннәре турында уйланалардыр, күрәсең. Шулай булмаса, Әсма әби турында борчылып, өзгәләнеп редакциягә хат җибәрмәсләр иде.

Язларны җәйләр, җәйләрне көзләр алыштыра. Кешенең гомере дә шулай. Бүген әниләреннән йөз чөергән Нурыйлар, Исламияләрнең дә капкасын инде көзге җилләр шакый. Гомер көзләрендә аларны нәрсә көтә? Бүген үзләрендә җитәрлек көч-куәт сизгән, үзләре турында гына кайгыртып, тыныч яшәргә омтылган бу кешеләрнең язмышы иртәгә Әсма әбинең ачы язмышын кабатламас дип кем ышандыра ала?

Миңназыйм Сепперов

ӘНИЛӘР, ӘНИЛӘР...

Егерменче гасыр кичергән афәтләргә шаһит аналар бар. Аларның матча яки тәрәзә кашагаларына кыстырылган «батырларча һәлак булды» дип язылган кәгазьләре дә инде саргаеп беткән. Кайдадыр чормада тутыгып, күгәреп беткән урак-чалгылары саклана. Икешәр-җидешәр улы, ире сугыштан кайтмаган мондый ялгыз аналар үзләре дә таушалганнар, картайганнар. Мичкә ягарга, су китерергә, идән юарга мәктәп балалары килгәнне көтеп алалар, мең рәхмәт белән аларны озатып калалар.

Әйе, нәкъ менә шундый аналар өчен Актаныш районының Пучы авылында колхозара (дөресрәге, районара: Актаныш, Минзәлә, Әгерҗе, Мөслим районнары өчен) хезмәт ветераннары йорты эшли.

— Әй, әз генә иртәрәк килгән булсагыз,— дип каршы алды безне ветераннар йорты директоры Әсма ханым Заманова.— Менә яңа гына бер әбине кабул иттек. Кызганыч, мескенкәем...

Сиксен җиде яшьлек Миңлекамал әби Яруллина икән ул. Минзәлә районы Нарат-Кичү авылыннан укытучы Котдус Хәлимов китергән үзен. Аның классы балалары шефлык иткән әбигә. «Бер караучың да, беркемең дә юкмыни соң?» — дигәч, әби: «Юк шул, юк»,— дип елап җибәргән һәм, оялып, әрнеп кенә, бер кызы барлыгын, Нөркәйдә яшәүче кызы Рокыя Мөхәммәтшинаның үзен карамавын әйткән.

Кызганычка каршы, ялгыз, ятим аналар белән рәттән, кызлары, уллары исән-сау булган мондый әбиләрне дә очраттык без бу йортта. Дөрес, аларның күпчелеге ул-кызлары, кыз-кияүләре эштә чакта үзләре генә кала алмаган, һәрчак карау-күзәтүгә мохтаҗ авырулар икән. «Авыру аналарның урыннары, әлбәттә инде, шушында»,— ди андыйларның балаларын да «кызганып» сөйли Әсма ханым.

Әбиләр белән таныша-таныша, караваты өстендә аякларын бөкләп утырган, бик матур кәшемир яулыклы, нурлы йөзле әбекәй янында туктыйбыз.

— Нихәл, әбекәй?! Кәефләрең ничек? — ди Әсма ханым.

— Шөкер, кызым,— ди әби.— Шөкер булмыйча соң, Әсмакаем, бик тәрбиялисең бит. Бик тәрбиялисең! Рәхмәт яусын,— дип кабатлый ул.

Мөсәлләмә әби Хәмидуллинага 94 яшь икән.

— Ике улым сугышта үлде,— ди ул безгә. Тыныч, салмак тавышында сагыш белән бергә горурлык та сизелә: — Зур малаем тракторда эшләде. Бәләкәчем — кәнсәдә, чут эшендә иде...

Без кызы турында сорашабыз. Әбекәйнең йөзенә күләгә йөгерә.

— Чирләшкә ул,— ди теләр-теләмәс кенә. Аннары сөенеп дәвам итә: — Үткән җәй сабан туена авылыма кайттым, Чишмәгә. Чаллыда эшләүче оныкларым алып кайтты... Авылны бик сагынмыйм алай,— ди кинәт боегып.

Әбинең йөрәген авырттырып чыккан «бик сагынмыйм

алай» сүзенең бәһасен без икенче көнне Чишмә авылына (Актаныш районы) баргач белдек.

Машинабыз нараттан салынган биек йорт каршына килеп туктагач, капка янына йөгерә-йөгерә бер хатын чыкты. Әмма безне, ят кешеләрне күргәч, кинәт тукталып калды.

Без өйгә үттек. Болын хәтле өйне башкорт моңнары тутырган. «Без Пучыдан, картлар йортыннан, әнисегез яныннан килдек»,— дигәч кенә, Зәмзәмия магнитофонны сүндерде. Өйдә кабер тынлыгы урнашты, караңгылык инде. Җылы, бик чиста итеп җыештырылган булса да, өйнең яме, нуры юк.

— Бик зур икән өегез. Ялгызыгызга күңелсездер бит? — дибез.

— Ю-у-у-ук! — ди Зәмзәмия.— Минем Чаллы шәһәрендә яшәүче кызым, ике малаем бар. Алар еш кына кайталар, бәпкәччәйләрем. Бала бик кадерле була бит ул. Йөрәгеңнән, бәгыреңнән өзелеп төшкәч.

Без тетрәнеп киттек. Бу сүзләрне шушы болын хәтле йортның хуҗасы, үзен тапкан, үстергән анасын картлар йортына илтеп ыргытучы 50—55 яшьләрдәге хатын әйтте. Кызармыйча, оялмыйча әйтте. Без аның үзенең дә балалык вазифасын — үз анасы каршындагы бурычын исенә төшерәбез. Намус, вөҗдан дигән төшенчәләрне телгә алабыз. Ниһаять, аның үзенә дә картлык киләчәген, аның инде якын икәнлеген искәртәбез...

— Мин бүгенге көн белән яшим. Әле менә кияүгә чыгып фамилиямне алыштырырга җыенам. Мин аның яшенә хәтле яшәрменме — анысы өчен кайгырган юк,— ди Зәмзәмия, «әни», «әнкәй» урынына «аның» сүзен генә кулланып.

Нәрсә бу? Ана белән бала әллә дошманнармы? Ана язмышына карата җанны өшетерлек мондый битарафлык каян килгән?.. Баксаң, әнә җавабы да гап-гади икән: Зәмзәмия бүгенге көн белән яши. Аның үзе өчен генә яшисе килә. Гомере буе Зәмзәмиясе өчен яшәгән анада аның гаме юк.

Без күршеләре белән сөйләшәбез.

Зәмзәмия гомере буе колхозда да, гомумән бер эштә дә эшләмәгән. «Авыру» икән. Ире — колхоз хисапчысы Әхтәм Шакирҗанов — акыллы һәм сабыр кеше булган. йорт эшләрен дә үзе эшләгән. Заманында кызы Зәмзәмия өчен дә колхоз кырларында икешәр норма үтәгән Мөсәлләмә әбинең дә кулыннан һаман эш китмәгән, пенсиягә чыккач, ул оныкларын, әйе, аның — Зәмзәмиянең балала-

рын үстерешкән. Әмма, 1976 елда йөрәк авыруыннан кинәт кенә Әхтәм кияве үлеп киткәч, инде үсеп буй җиткән балалар да Чаллы шәһәрендә эшкә урнашкач, Мөсәлләмә әбинең бу йортта кирәге калмый. Дөрес, Зәмзәмия анасын көне-сәгате белән куып чыгармый әле. Үзләренә чират җиткәч, 90 яшен узган әбидән авыл көтүен көттерә ул. Таягына таянган, көтү артыннан җитешергә тырышып, тыннары кабынган Мөсәлләмә әбине авыл халкы ярдәмсез калдырмый, әлбәттә. Өлкәннәр эштә вакытта, көтүгә, әби янына ярдәмгә мәктәп балалары килә...

Анасын дәүләт карамагына тапшыргач, «авыру» Зәмзәмия үз маллары өчен, ирләр кебек, печәнен чаба, көн саен ялт иттереп болын кебек өен җыештыра, мал-туарын карый.

— Шулай да, киләчәгегезне ничек күзаллыйсыз соң? Илгә-җиргә үз өлешегез кермәгәч, пенсия дә алмыйсыз икән,—дибез моңа.

— Балаларым караячак мине! — ди Зәмзәмия бик нык ышанып.

— Әйе, картлык якынайган саен, үзенең ана булу хокукын даулаячак әле бу гомере буе үз якыннарын кимерүче соры корт,— диде кемдер машинабыз кузгалгач.

Тат. Ямалы авылында да безне шундый ук күңелсезчек каршылады.

— Күңелле хәл түгел шул,—ди авыл Советы председателе Рифкат Вәлиев. — Бер куып чыгардылар аналарын. Ике... Акылга утыртып булмасмы дип, суд-прокуратура органнарына да мөрәҗәгать итеп карадык. Ахырда әбине картлар йортына илтеп кайтырга мәҗбүр булдым. Югыйсә, энисен, бәләкәй булса да йорт-җирен саттырып дигәндәй, Симстраудан Гыйлмегаян үзе барып алган иде...

Кош-корт, мал-туар тулы ихатага барып кердек. Баскычта безгә күлмәк итәкләрен кыстырган бер әби очрады.

— Бу — Гыйлмегаян хатыны Фәниянең бертуган апасы Гафифә,— дип таныштырды председатель. — Алар белән тора.

— Без аны куып чыгармадык,— ди Гафифә әби Миңнеҗиһан әби Әхмәтгалиева турында.— Мин аңа әнә ишек төбеннән, җылы торба янында урын да биргән идем — риза булмады.

Без өй эченә күз салабыз. Газлы. Җылыткыч торбалар үткәрелгән. Гафифә әбинең үз урыны дүрткә бүленгән өйнең түр бүлмәсендә.

— Мал суйганда яки бәйрәмнәрдә генә булса да кунакка алып кайтасызмы соң? — ди председатель.

— Юк. Каз суйганда диң әле! Каз суйганда... Уңа казыбыз — би-ик күп була... Берәр каз илтсп бирсәләр — мин аңа каршы түгел...

Гыйлмегаян Әхмәтнәбиевны без атлары янында очраттык. («Гыйлмегаянның да, Фәниясенең дә хезмәтләренә сүз тидерерлек түгел алай»,— ди председатель.)

— Әнкәйнеме? — Гыйлмегаян бер генә мизгелгә югалып кала.— Ике тәкә башы бер казанга сыймый. Хатынның апасы минем балаларымны үстерде. Шуңа тотам аны. Ә әнинең миннән башка да өч малае бар. Алар карасын! Берсе — Рәвисе Бүләк авылында гына... Тегеләре яшәгән Чайковский белән Пермь шәһәрләре дә җәһәннәмдә түгел...— ди аннары.

Йә хода! Бу сүзләрне инде үзе дә өч бала атасы, ир уртасы кеше әйтә. «Мине дә балаларым туп кебек берберсенә типкәләп йөртерләр картайгач — мин аларга шул үрнәкне бирәм бит»,— дигән уй башына да килми, күрәсең...

Үзебез ана рәнҗеше белән хисаплашмаган шушы кеше белән сөйләшәбез, ә күз алдында һаман да ике әби тора. Берсе — әле бүген дә беләкләрендә көч-куәте булган, шунлыктан, сеңлесе белән киявенең тормышына да хуҗа булып сөйләшкән 70 яшьлек Гафифә әби. Ә икенчесе — гасыр белән бергә, илгә килгән афәтләрне үз җилкәсендә күтәргән, дүрт ул үстереп өйләндергән, көч-куәтен балалар үстерүгә, колхоз эшенә биреп саулыгы какшаган, бүгенге көндәге бөтен байлыгы Ветераннар йортындагы караваты почмагында бәләкәй генә төенчеге булган Миңнеҗиһан әби. Бәләкәй төенчеге белән бергә аның тагын бер байлыгы бар. Ул — әбинең хәтер сандыгы. Ирексездән колакта аның сүзләре яңара:

— Дүрт ел торам монда,— диде ул безгә бик тыныч кына. — Әхмәтгәрәем сугышка киткәндә, ике кашык он белән калып үстергән идем улларымны. Менә картайдым. Сыйдырмадылар. Аяк атлап кермә, диделәр. Рәхмәт инде хөкүмәтебезгә. Бик рәхәт яшим...

Бу язмабызда без Ветераннар йортында яшәүче бары ике генә язмышны сурәтләдек. Бәләкәй генә сурәтләдек. Монда яшәүче 42 язмышны, 42 тормышны өйрәнү, аны шушы юлларга сыйдыру мөмкин түгел. Бу — аналар тарихы. Төрле холык. Төрле язмыш. Әйтик, кар шыгырдавын да, үлән селкенүен дә ишетеп ятучы аналар бар. Мондый аналар балаларыннан хат көтәләр. Өметләре аклан-маса да, алар хат ташучының аяк тавышын сагалыйлар. Миңлебикә әби Мөхәммәдиева, мәсәлән, Украинадагы До-

нецк шахтасында эшләүче улы Исламгали Ишмуллинның хатларын төшләрендә генә укый, уянып китә дә үзәкләре өзелеп елый, 8 ел инде улы ник бер генә тапкыр хат юлласын! Мөнәвәрә әби дә Мәскәүдә яшәүче кызына ай саен хат яздыра икән... Кайбер аналар исән балаларын хәтер сандыкларына бикләп үк куйганнар. Мондый аналар өчен иң истәлекле көннәре булып хезмәт еллары санала. Үзара сөйләшкәндә дә алар көн саен бер үк хатирәләрне яңарталар. «Беренче ударник идем,— ди, мәсәлән, 95 яшьлек Бибигайшә әби Сәетова.— Кардан ак сарык суеп сыйладылар. 5 кадак йон белән бүләкләделәр». Ә Фәрдәнә әби Гыйнетдинова ферма мөдире булып эшләгәнен сөйли. Фермада абзарлар салдырып йөргән көннәрен исенә төшерә. «Кырда кунып эшләдек»,— ди Сәгыйдә әбекәй Камалетдинова.

Кайбер аналар сагынуларын да бик тирәнгә яшерергә тырышалар (бу бигрәк тә балалары исәннәргә хас). Миңнеҗиһан әби Шәрәфиева, мәсәлән: «Монда яши башлавыма сентябрьдә биш ел була. Төш вакыты иде...» — ди. Димәк ки, мондый аналар ашау-эчүдән, гомумән биредәге тормышларыннан канәгать булсалар да, шушында үткәргән көн-сәгатьләренә хәтле санап яшиләр. Сагынуларын яшермәүчеләр дә бар. «Истән чыкмый туган авыл, эчкән су. Нишлисең? Түзәсең. Якын кешеләрем юк. Сугыш харап итте. Ялгыз мин. Рәхмәт хөкүмәтебезгә»,— ди Шәмсебәдәр әбекәй Садыйкова. Гыйлмеҗиһан әби Мирхәйдәрова авыру карчык. Ул да туган авылын (Актаныш районы Колын авылы), кызының балалары — оныкларын, Украинада яшәүче улын сагынуын яшерми. «Бик хәтәр әйбәт яшим, әмма... йөрәгемнән каннар тама — сагынам»,— ди ул...

Әйе, аналарның төрлесе бар. 88 яше тулган Гөлсафа әби Башарова, мәсәлән, һәр ашаган саен ипи валчыкларын җыя. Бөртеген дә калдырмыйча бик кадерләп җыя... Авыру әбиләргә ярдәмгә дә, иң беренче булып, ул килә. Үзе турында бик аз сөйли, күбрәк башкалар язмышы белән яши. Монда яшәү әбиләрнең дә, аларны караучы коллективның да — иң кадерле кешесе ул. Бердәнбер көнне ветераннар арасында яшен яшьнәгәндәй була: менә шул әбинең исән-сау кызы Минзәләдән килеп бала карату өчен әнисен алып кайтырга тели... Юк, бирмиләр Гөлсафа әбине бу хатынга...

Менә шушылай бер гаилә булып яшәгән, төрле милләт (чуваш, мари, башкорт, татар) кешеләреннән җыелган бу дус коллективның үз мәшәкатьләре, үз проблема-

лары бар. Ашау-эчү белән тулысынча тәэмин итсәләр дә бу йортка район җитәкчеләре дә, колхоз җитәкчеләре д бөтенләй диярлек аяк басмый икән. Бәлки, шунлыктан дыр, бөтенләй ят кешене дә алар, хәлебезне белдең, рәх мәтләр яусын, дип сөенеп озатып калалар. Бәлки, мондый йортларны колхоз үзәкләрендә интернат-йортлар салу бе лән алыштырырга кирәктер. Бу очракта авыру әниләр белән яшәгән яшь гаиләләр дә эш-хезмәттән аерылмас лар иде. Әйтик, аналарын атна буе шушы йортта тоталар да, ял көннәренә алып, мунча кертәләр, кунак итәләр Мондый очракта әбиләребез дә сагыну-сагышларынна азат булыр иде. Яшерен-батырын түгел, каберләрене үз авылларында булуына да сөенерләр иде алар...

Ни генә булмасын, хәтта шушы шартларда да Пучы да яшәүче хезмәт ветераннары бүгенге тормышларыннан кызлары-уллары урынына, үзләрен караучы тәрбиячелә реннән бик канәгать. Бик рәхмәтле алар хөкүмәтебезгә

Рәйсә Юсупов

ОЧРАШУ

Җәй башлары иде. Шәһәр урамнарындагы лотокларда беренче кызыл помидорлар күренә башлады. Үзебезне бакчаларда әле помидор өлгермәгән, ямь-яшел, үзләре чик ләвек кадәр генә. Шунлыктан, көньяк өлкәләрдән кит релгән тансык ризыктан һәркемнең авыз итәсе килә — ло токлар янына озын-озын чиратлар тезелде. Бер кулына имчәк баласын кочкан, икенче кулына авыр гына сумка аскан яшь бер ана да чиратка басты. Бу хәлдә аңа оза басып тору бик кыен иде. Яшь ана, сабыен юата-юата читкәрәк чыгып арлы-бирле йөренә башлады. Сугыш ве тераннары, кенәгәләрен күрсәтеп, чиратсыз гына алы китәләр. Аларга сүз әйтүче юк — кулларында законлы кәгазьләре бар ич... Яшь ана да кыюсыз гына сорап кара ган иде, сатучы хатын аның сүзен колагына да элмәде Сатучы ишетмәсә дә, чираттагы апалар аның кыюсыз ава зына колак торгызып өлгерделәр:

— Минем дә сабыйларым өйдә зар җылап утыра анда

— Юри күтәреп чыгалар алар балаларын. Чиратсы алырга.

Яшь ана, башын иеп, чиратына килеп басты.

Шулай туры килде, мин аның белән янә дә очраштым.

Күптәннән күрешмәгән Фатих кордашым янына килгән идем.

Фатих сугыш һәм хезмәт ветераны булу өстенә, тагын әле шәһәребезнең дә ветераны. Илленче еллар башында Сарман ягыннан килеп, нефтьчеләрнең төзү оешмасында балта остасы булып эшли башлый ул. Шәһәрнең... юк, ул вакытта шәһәр түгел әле. Булачак шәһәрнең беренче йортларын салалар алар. Чупай ташыннан бөтен уңайлыклары булган менә дигән ташпулатлар торгызалар, ә үзләре җиңел кулдан гына әмәлләнгән баракта яшиләр. Егет чак, буйдак чак, Фатихның моңа аз гына да исе китми. Иң мөһиме, кулга әйбәт кенә акча керә, өс бөтен, тамак тук. Менә бераз мая туплар да, авылга кайтып үзенә өй салыр, өйләнеп җибәрер...

Әмма корган план-ниятләрең син дигәнчә генә барса икән! Аеруча, мәхәббәт дигәннәре берни белән исәпләшми.

Көннәрдән бер көнне, төзелешкә яңа гына һөнәр училищесын тәмамлаган бер төркем буяучы-штукатурчы кызлар килеп төшә. Айлап кына түгел, көнләп үсеп килүче Әлмәт өчен гадәти бер хәл, югыйсә. Әмма Фатих өчен бер дә гадәти булмый бу хәл. Мәсьәләне якасыннан эләктереп әйтсәк, егетебез шушы төркемдәге бер кара кашка, ягъни Язилә исемдәгесенә колакларына кадәр гашыйк була. «Колакларына кадәр» диюбез шуннан, эш арасындамы, урамдамы Язилә очраса, Фатих, моңарчы телендә ни сандугач сайратучы егет, «ык-мык» итә дә кала, колак яфраклары, утлы күмердәй кызарып китә. Кызны күрүгә, шулай тел көрмәкләнеп, йөрәктәге ялкын колак яфракларында гына чагылып алса да, акыл дигәне бик төгәл фикер йөртә егетнең. «Синеке бу кыз, синеке!» — ди.

Акыл белән йөрәк бердәм икән, озын сугыш юллары үткән солдат өчен мәсьәлә ачык: кыюрак булырга, язмышыңны кулыңа алырга!

— Уйланган — эшләнгән! — дип, алай бик ваклыкларына кермичә генә сөйләгәне хәтердә Фатихның. — Бөтен баракны гөр китереп, туй иттек. Баракны гынамы! Ул чакта ун-унбишләп бараклан торган ул урыннар икенче поселок дип атала иде. Бөтен поселок ду купты туйда.

Туй уза, туйдан соң әле егетләр, әле кызлар барагында гөр-гөр килеп кенә яшәгән чаклар да гомернең иң якты истәлеге булып хәтергә сеңгән. Аннары, бәхет гөлләренең чәчәге булып, уллары дөньяга килә. Менә шуннан соң инде баса башлый иңнәргә дөнья мәшәкате. Фатих аерым

куыш сорап, төрле-төрле кабинетларның бусагаларын таптый башлый. Йөри торгач, алай үзләре салган йорттан өлеш чыгармасалар да, әлеге баракларның берсендә аерым бүлмә бирәләр боларга. «Вакытлыча» дип күңелләрен юаталар яшьләрнең. Әмма бу «вакытлыча» дигәннәре шактый елларга сузыла. Ул арада Язилә икенче малайны да алып кайта. Фатих исә бусага таптауны ешайта. Нәтиҗә — берсеннән-берсе матур вәгъдәләр... Кайтуга, суын ташы, утынын хәстәрлә, бала чүпрәкләре белән мәж кил кибетенә йөгер.

— Яшь чак, көч-куәт ташып тора. Болар бар да уен кебек кенә иде,— дип искә ала Фатих. — Әмма, малай минем болай йөгерүләр, һич көтмәгәндә, башыма хәсрәт булып яуды. Берзаман, шулай теге-бу начальникка керү өчен күпмедер чират көтеп, тагын коры вәгъдә-вәгазь сүзләре генә ишетүдән җаннарым кыйналып кайтып керсәм ни ачык чырайлы Язиләм, тәмам кара коелып каршы ала башлады. Тырт та пырт моның кыланышлары. Нәрсә бу Тормышыбыз көйсезлегенә бирешүеме, әллә мине бул дыксыз бер адәм итеп күрә башладымы? Башта һич аң ламый йөрдем. Аннары әле, ул елларда шундый нәрсә бар иде бит: ягъни, квартир алу өчен кемнәрнедер «көйләргә» кирәк. Мин дә, Язиләм каршында алай булдыксыз адәм булып күренмәс өчен, кемнәрнедер «көйләп» йөргәли баш ладым. Шулай «көйли-көйли» шактый соңлап, әйбәт кенә кызмача кайткан кичләр дә булгалады. Нишлисең, ул чакларда гадәти бер хәлгә әверелгән иде бит мондый чир. Ә Язиләм минем болай артыграк та тырышып йөрүемнән үзенчә нәтиҗә чыгарган. Янәсе, мин ниндидер бер кыска итәккә ияләшкәнмен дә, шуңа башым-күзем әйләнгән.. И, малай, искә дә төшерәсе килми ул чакларны. Бер-беребезгә бүре булып улаган, кулдан тәмам эш төшкән көннәр була иде. Менә хәзер картлар җыелышып сөйләшәбез дә, бер болганмый су да тонмый, дигәндәй, күпләр дә була икән ул андый хәлләр. Гомернең иң гүзәл чорын үзебез үк шулай ямьсезлибез икән. Төптәнрәк уйласаң «үзебез үк» дип тә әйтеп бетереп булмый инде. Яшь чак та — тормышың көйсез, картайгач — тормышың көйле, әмма үзеңнең көең китә башлый икән ул.

Миңа ишекне Фатих үзе ачты.

— Сагынганымны белдеңме, үзең сагынып килдеңме.. Нинди генә фәрештәләр хәбәр салды икән күңелеңә?— дип, күрешергә сузган кулымны ычкындырмыйча түргә таба өстери үк башлады ул.— Әйдә, әйдә, малай, утыры

торасыңмы, диванга сузыласыңмы, мин чәй куеп җибәрим дә... Туйганчы гәпләшәбез әле бер.

— Язилә өйдә юк ахры? — дип сорыйсы иттем; аның ишектән керүемә, инде шактый калынаеп киткән гәүдәсен гаҗәп җиңел йөртеп, үзе һаман да яшьләрчә шук елмаю белән балкып каршылауларын юксынып.

Фатих тавышын акрынайта төште.

— Әби кешенең үз эше әле аның. Ә без пока үзебезчә генә... — дип, Фатих хуҗаларча бөтен әйберсен-ниен бик тиз табып, тәмам шартына китереп өстәл хәзерләп йөри башлады. Куллары, гадәттәгечә, бик өлгер, теле тагы да җитезрәк әйләнә иде кордашның. — Менә шулай, дүрт бүлмәгә икебез генә хуҗа булып, карт белән карчык яшәп ятабыз хәзер. Ара-тирә шыгырдашып алуларны чутламаганда, тазалыклар ничава әле. Үзегездә ни хәлләр соң? Рәсимәнең кәефләре ничек? Һаман да шулай дөньясын онытып, рәхәтләнеп бер көләме? Әйбәт-әт... Балалардан хат киләме? Шулайрак шул инде алар. Безнекеләр дә менә... Олысының Нижневартовскида төпләнеп үк калуы булды ахры. Квартираның бик әйбәтен бирделәр үзләренә. Уртанчысының гына хәле хөртирәк. Әйе, шунда, КамАЗда. Һаман да өчесе бер бүлмәдә. Әле тагын ишәергә торалар шикелле, ә квартира... Вәгъдәләр генә хәзергә. Студент улыбыз соңгы курста хәзер. Төпчегебез, солдат улыбыз, быел җәйгә кайтыр дип торабыз. Дөньялар гына имин булсын.

Чәй янында әңгәмәбез әнә шул дөнья иминлеге турында куерды.

— Үзең дә сизәсендер, малай, бөтен дөньясында шундый да көчле бер саф җил исә бит хәзер. Ил белән ил арасындамы, теге, Көнбатыш белән Көнчыгыш дигәннәре арасындамы бар бәхәс-аңлашмауларны корал кизәнеп, мәгънәсезгә кан коюлар юлы белән түгел, үзара сөйләшү-килешүләр юлы белән, бугазга-бугаз килмичә ярышу-узышу юлы белән хәл итү турында гаять җитди олы сөйләшү бара. Сөйләшү генә дә түгел, бөтен дөнья кузгалды. Гөрли, ярсый дөнья. Уйлап-уйлап йөрим дә, малай, адәм баласының иң борыннан килгән изге хыялы, ягъни мәсәлән, көчленеке бу дөнья! — дип түгел, үзара тату яшәү, дус яшәү, гадел яшәү хыялы тормышка ашар көннәр якынлаша түгелме? Әйтик, ике меңенче елларга, ә?

— Да, кордаш... Гөрли дөнья, гаделлек даулый дөнья! Беләсеңме, кордаш, мин болай уйлыйм. Син әйтмешли, кешелек дөньясының борын-борыннан килгән иң изге хыялы инде ул — бер сүз белән генә әйткәндә, гадел яшәү. Әйтик, Париж коммунарларының байрагында нәрсә иде?

Бер сүз белән генә әйткәндә, гаделлек! Инде килеп, Октябрьдә Ленин күтәргән, большевиклар күтәргән байракта, тагын бер сүз белән генә әйткәндә, шулай ук — гаделлек!

— Менә-менә!.. Безнең бабайлар... Тукта, без алай бик тарихка кереп чуммыйк әле. Әйтәсе килгәне шул: дөнья күләм мәсьәләләрдән алып, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләренә кадәр чын гаделлеккә ирешү җиле исә хәзер... Кая, тагын бер чынаяк яса әле. Тәмле дә пешерәсең икән чәйне. Эчеп туешлы түгел.

Фатихның йөзе мөлаем елмаю белән яктырып китте.

— Без бит карчык белән гомер итә башлаганнан бирле яңача фикер йөртәбез. Тормыш үзе өйрәтте. Икебез дә төзүчеләр, хезмәт хакы да икебезнеке бер чама. Кайсыбызның сменадан буш чагы, өйдәге бөтен эш шуныкы. Электән килгән, теге... Монысы хатыннар эше, монысы ирләрнеке дигәннәрен тормыш үзе баштан җилгәрде... Болай бик мактагач, тагы да тәмлерәк итеп ясап күрсәтим әле мин сиңа чәйне. Бая бераз ашыктым.

Күрше бүлмәдә бала елаганы ишетелде.

— Оныклар аваз саламы анда?

— Юк, бу күршенеке әле. Ярты гына сәгатькә дип, Язиләгә калдырып киткән иде... Әйдә, булмаса, чәй пешкәнче без балконга чыгып бер көйрәтеп керәбез. Ташламадыңмы әле тартуны? Әй, малай, вакыт, бик вакыт та бит... Әгитләп торуның кирәге юк, анысы...

Без балконнан әйләнеп кергәндә, алгы бүлмәгә Язилә дә бала күтәреп чыккан, баланың әнисе дә кайткан — өчәүләшеп гөрләшәләр, чөкердәшәләр иде. Теге хатын баласын кулына алды да рәхмәт әйтеп, хушлашып чыгып китә башлады.

Аны шунда ук танып алдым. Беркөнге помидор чиратындагы яшь ана ич. Минем уемны сизгәндәй Язилә аларның тормышы белән таныштырып үтте.

— Безнең КамАЗдагы улыбызныкы шикелле инде боларның хәлләре. Квартира ягы да. Бая әйткәнчә, яшь чакта тормышның көйсез, картайгач...

—Да, кордаш... — дип тирән сулап куюдан башка сүз таба алмадым.

Фатих та сүздән калды.

— Әллә бик гәпләшә торгач, үпкәләшеп беттеләр инде болар,— дип бүлмәгә Язилә килеп керде. — Җыр тыңлагыз, ичмасам, хәсрәт төенчекләре.

Ул сервант өстендәге магнитофонны уйнатып җибәрде. Бүлмәдә тын гына ягымлы җыр яңгырады.

Инде буй җитсәм дә,
Мин сиңа сабыймын...

Фатих янә дә ачылып китеп:

— Күңеленә хуш җырларын уйната башлады бу. Моннан соң «Әниемнең чал чәчләре» яңгырар, аннары «Су буеннан әнкәй кайтып килә»... Әй ярата да соң! Әйтерсең үзенә генә багышланган.

— Нигә багышланмасын! Алты бала үстергән кеше ич мин,— диде Язилә горурланып.

— Хөрмәткә бик лаек чал чәчле аналар. Монысында сүз дә юк.— Фатих беразга уйчан тынып калды.— Ә менә соңгы вакытта яшь аналарга багышланган җырларны аз язалар. Уйлап баксаң, үзләре дә балалыктан яңа чыккан яшь аналарга нәниләрен аякка бастыру аеруча кыен. Ул шартлары дисеңме, тәҗрибәсезлеге дисеңме...

— Әйе, әйе,— дип эләктереп алдым мин, уй-хисләремнең ургый-чайпала башлавын сиздем.— Ә бит олы художниклар, музыкада да, сынлы сәнгатьтә дә, шигъриятгә дә моңа элек-электән беренче дәрәҗә игътибар иткәннәр. Рафаэльнең «Сикстин мадонна»сы үзе генә дә ни тора! Чайковский тагын. Үзебезнең Такташ ничек дан җырлаган яшь аналарга.

Бу сүзләрне хуплап дәвам иткәндәй бүлмәдә Язиләнең яңа магнитофон язмасы яңгырады.

Әнкәйләрнең бөеклеген
Яши-яши аңлыйбыз.

Рафаил Төхфәтуллин

КҮЛӘГӘЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

...Кемгә-кемгә, ә безгә — шәфкать туташларына — ялгышырга ярамый, хакыбыз юк. Җиде кат үлчә, бер кат кис, дигән мәкаль нәкъ безнең өчен. Ләкин ничек итеп эшне башлаганда ук ялгышмаска? Синең бер генә ялгыш хәрәкәтең дә авыруга өстәмә авырту ясамасын өчен нишләргә? Процедуралар кабинетында өйрәнү үткәндә әнә шулай сорау арты сорау туып кына тора. Билгеле инде, аларга җавап табасы килә. Ләкин процедура кабинетында эшләүче медсестраның синең белергә теләвендә эше юк кебек. Ул һәр сорауны күзләрен зур ачып каршылый һәм аның карашы да, тавышы да гүя синең үзеңне гаепли:

— Шуны да белмисеңме? Система куйганың булмадымы?

Югыйсә бер мәртәбә яхшылап аңлатып, күрсәтеп бирсә, хәзер эләктереп аласың да бит. Юк шул. Күп нәрсәләргә ялгышулар аша үз акылың белән ирешергә туры килә. Кайбер медсестраларның иң гади процедуралар алдында югалып калуына гаҗәпләнә идем. Менә нәрсәдән килә икән ул. Белергә теләмәүдән түгел, ә бәлки белергә теләп тә, тиешенчә өйрәнә алмаудан икән. Хәер, өйрәнү юлында кем белән туры киләсең бит. Берәүләр сиңа һәрнәрсәне яхшылап төшендереп бирә, икенчесенә ник сорадым икән дип үкенәсең.

...Безнең палатада өч әби ята. Өчесенең өч төрле холык. Өчесенең өч төрле язмыш. Мәликә әби кадерле карчык. Аның янына гел килеп кенә торалар. Кызы (үзенә дә инде 60 лар бардыр) көннәр буе янында утыра. Әбинең кан басымы бик югары булды. Хәзер инде әнә рәтләнеп килә. Мин бу әниле-кызлы ике әбинең бергә чөкердәшүенә куанып та, сокланып та карыйм. Икенчесе Мария Павловна. Аның да улы бик еш килә, оныгы килә. Кайчак оныгы аны коридор буйлап култыклап та йөри. Тик менә Зөләйха әби янына килүче юк. Аның йөрәге авырта.

Беркөнне ул миңа болай дип мөрәҗәгать итте:

— Кызым, син мине карарга берәр кеше таба алмассың микән? Өйгә чыксам да, монда да берьялгызым. Карар кешем юк. Пенсиям җитәрлек, акча түләр идем...

— Борчылма, әби, табарбыз! — дидем мин ышаныч белән. Һәм аның үтенечен курсташларыма җиткердем. Без бергәләп аның янына килеп йөрергә булдык.

Икенче көнне иртә белән әбине сөендерим дип керсәм, аның караваты буш иде.

— Әбине кая күчерделәр?— дигән соравыма күрше караваттагы ападан:

— Бүген иртән дөнья куйды,— дигән җавапны ишеттем.

Шундый кыен булып китте. Кара инде син! Әбинең соңгы үтенечен дә үти алмадык. Шәфкатьлелек өчен ул пенсиясеннән өлеш чыгарырга әзер иде бичара! Моны белеп тору икеләтә авыр.

...Балалар ята торган палатага килеп керүгә, безне Артем белән Юрик каршылый. Артемга тугыз ай. Шулай да утырып та тора белми әле. Ләкин бөтенесен аңлый. Карап торуга аны алты айлык дип беләсең. Кечкенә генә, ябык.

Безнең килүне зарыгып көтеп тора. Артемны поезд вагонында ташлап калдырганнар. Аның янында бернинди документ та булмаган. Шуңа күрә аның күпмелек икәнен чамалап кына язып куйганнар, исемен дә балалар йортында кушканнар. Артем бронхит белән авырый. Ә Юрикны тугач ук бала тудыру йортында калдырганнар. Анысына яшь ярым. Ләкин физик үсеше буенча ул да яшьтәшләреннән күпкә калыша. Килеп керүгә, алар безне үзләренчә шатланып каршылыйлар. Шуларны кулга алып сөймичә, бераз күтәреп йөрмичә түзеп булмый. Югыйсә палатадагы сестра ачулана:

— Күтәрмәгез, артык иркәләмәгез,— ди. — Аннары безгә бик кыен була. Төнлә йокламыйлар...

Ул да хаклы, әлбәттә. Бала өчен иркәләү вакытлыча гына түгел, һәрчак кирәк. Ләкин аларның үзләренчә нидер дәшүләрен, күзләренең очкынланып китүен күрәсе килү тыюлардан көчлерәк. Кулга алмыйча һич мөмкин түгел. Без аларга тәмам ияләнеп беттек. Алар да безгә шулай ук. Шулар өчен генә практиканы озынайтасы иде. Һич югы шушы ике бала терелеп чыкканчы!

Бер килүемдә сумкасына уенчыклар, күчтәнәчләр тутырган бер ханымның врач янында утырганын күрдем. Соңрак белдем: бу ханым Артемны алырга уйлый икән. Хәзергә килеп йөриячәк, үзенә ияләштерәчәк. Шуны ишеткәч, аның йөзенә ныграк игътибар иттем. Сөйкемле күренә. Ышанычлы булырга тиеш. Шулай гына булсын! Артем өчен күңелем тынычлана төште. Ә менә Юрикны кем алыр? Терелеп беткәч, яңадан балалар йортына китәрме, әллә аның өчен дә әни табылырмы?

...Кичке сәгать алтылар тирәсе иде. Иптәш кызым белән хәрби-инженерлык училищесы территориясе яныннан узып барабыз. Шунда бер кызык хәл күреп, тукталып карап тордык. Күрер күзгә чибәр генә ике кыз таш койма аша училище территориясенә керергә азапланалар. Икесе дә заманча киенгән, бизәнгән. Безнең яшьтәшләр. Күңелдә сорау туды: нигә соң әле болар капка аша түгел, койма аша йөриләр? Башларына нинди эш төшкән?

— Дискотекага болар чакырылмаган кунаклар,— дип аңлатты иптәш кызым. — Чакырылганнарны анда каршылыйлар, ә боларга тырышырга туры килә...

Я хода, бу кызларны ирексездән кызганып куйдым. Ничек итсәләр иттеләр, койма аша тәки уздылар! Коймасы да бит әле урамның иң күп кеше йөри торган ягында. Шулай әрсезләнеп хәрби училище территориясенә элә-

гү мәртәбә микәнни? Я ул кызларның бернәрсәдә дә эше юкмы? Һәрхәлдә, алар өчен безгә оят булды.

Ләйлә Зарипова

СОҢАРГАН КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ

Тормышларына мәңге юылмаслык кара тап төшергән теге январь киче булмаса, бу үсмерләр бүген үзләрен ничек тотарлар иде икән? Мөгаен, башка яшьтәшләре кебек Марат, Камил, Олег та шау-гөр килеп мәктәпкә барырлар, иптәшләре белән киногa йөрерләр, кызлар белән очрашырлар, укылган китаплары турында кызып-кызып бәхәсләшерләр, киләчәктә кем булу турында хыялланырлар иде.

...Суд бара. Гаепләнүчеләр эскәмиясендә 14 яшьлек үсмерләр. Марат Вахитов — Казандагы 2 нче интернат-мәктәп укучысы. Хөкем каршына икенче тапкыр басуы. Ике очракта да караклык өчен. Камил Гафаров 23 нче мәктәптә, ә Олег Васильев 7 нче мәктәптә сигезенче класста укыганнар. Җәмәгатьчелек алдында йөзләре ак түгел аларның. Караклыкта гаепләнәләр. Судка чакырылган шаһитларның да күбесенә әле 15 тә тулмаган.

...4 январь кичендә алар гадәттәгечә, Химиклар культура сарае янындагы бакчада очрашалар. Бераз этенеп-төртенеп торганнан соң якындагы наратлыкка юл тоталар. Аларга үзләре белән бер яшьләрдәге ике үсмер очрый. Әлеге «геройлар»га нәкъ шул гына кирәк тә. Башта малайларның кайда яшәүләре белән кызыксыналар. Башка районнан икәнлекләрен белгәч, әлеге «батырлар»ның каннары уйнаклап ала. Берсен (Ивановны) читкәрәк алып китәләр һәм даулашкан арада Камил аның күн перчаткасын тартып ала. Әтәчләнгән үсмерләр моның белән генә чикләнмиләр. Төрлечә янап, Патрикиевтан акча таләп итәләр, көчләп кесәләрен актаралар. Җиргә төшкән күпмедер акча, шулай ук малайның кул сәгате алар табышына әверелә.

Кылган эшләреннән зур канәгатьләнү хисе кичергән җинаятьчеләр тыныч кына өйләренә таралыша. Берсен дә вөҗдан газабы борчымый, «мин бу ахмаклыкны ник эшләдем соң?» дигән уй берсенең генә дә башына килми. Киресенчә, бу «эш»ләре тыныч кына төгәлләнү белән канатланган «геройлар» берничә көннән яңадан шул ук урынга җыйналалар. Ул бу көнне чыршы карарга килгән 9 нчы

класс укучысы Светлана Егорова аларның чираттагы корбаны була. Алар кызны аяк чалып егалар һәм аның мохер шарфын тартып алалар. Куркудан ни эшләргә белмәгән кыз торып йөгерә башлый. Ләкин аны тагын куып тоталар. Яңадан аяктан егарга маташалар. Кызның кычкырган тавышын ишетеп, бер ир-ат килеп чыга. Ул арада җинаятьчеләр күздән югалып өлгерәләр. Шулай итеп, икенче «батырлык» та җәзасыз уза. Шуннан бу үсмерләр бөтенләй чыгырдан чыгалар. Икенче көнне дә кичен алар буш кайтмыйлар. Янау юлы белән Казан төзүче-инженерлар институты студенткасы Татьяна Вдовинаның муенындагы мәрҗәнен салдыралар, мохер шарфын, кулындагы сумкасын тартып алалар. Җиңел кәсеп белән акча табуның тәмен татып өлгергән үсмерләр җинаять эшләүне дәвам иттерәләр.

Суд барышында алар үзләренең бу кыланышларын: «Болай гына... Эш юклыктан... Кызык өчен генә...» дип аңлаттылар.

Әйе, хәзер алар үзләренең нинди тайгак юлдан барган булуларын аңлаганнар кебек: үкенәләр, гафу итүне сорыйлар, елыйлар. Ләкин болар — соңарган күз яшьләре. Әхлак нормалары — намус, җәмгыять, ата-ана алдындагы изге бурыч турындагы төшенчәләр бу малайлар өчен әле кайчан гына буш сүз булган. Кылган җинаятьләре өчен җаваплылык тоймаган, нәрсә эшләсәң дә ярый дип санарга күнеккән үсмерләр әхлак һәм җәмгыять законнары белән исәпләшмичә яшәп биргәннәр.

Халыкта: «Кырык көннең «бәйрәме» бер була», диләр. Бу очракта да нәкъ шулай килеп чыга. Үсмерләр суд каршына бастылар. Һәм халык суды аларга тиешле җәзаны билгеләде.

Ләкин хикмәт кемнең күпме вакытка хөкем ителүендә түгел. Үсмерләр җинаять юлына ничек баскан? Тайгак юлның башы кайда? Нигә вакытында кисәтүче, ярдәм итүче, аларның мондый ярамаган эшләренә чик куючы булмаган? Мәсьәләнең асылы да менә шунда. Әгәр малайларның ышанычлы өлкән дуслары, авыр вакытта ныклы таянычлары булса, мондый аянычлы хәл килеп тә чыкмас иде. Бу яшьтәгеләргә гаилә, укытучылар коллективы, район эчке эшләр бүлегендә балигъ булмаган үсмерләр белән эшләүче хезмәткәрләр шундый ышанычлы таяныч булырга тиеш иде бит. Тик алар әлеге үсмерләрнең язмышына битараф караганнар. Иң аянычы — малайларга дөрес тәрбия бирүдә бу коллективлар үзләренең көчләрен берләштерә алмаганнар. Нигездә исә, бала язмышы өчен иң беренче чиратта, гаилә җаваплы. Уллары тайгак юлдан тәгәрәгәндә

ата-аналары кайда булганнар соң? Хөкемгә тартылган үсмерләрнең өчесе дә ата назы күрмичә, ярым ятим гаиләдә үскән. Әтиләре исән була торып та, алар «әти» сүзен әйтергә тилмереп яшәгәннәр. Әти-әнисе исән була торып та Марат Вахитов башта балалар йортында, уку яшенә җиткәч интернат-мәктәптә тәрбияләнә. Аның әтисе яңа гаилә корган, әнисе даими эчүчелек белән шөгыльләнгән өчен ана хокукыннан мәхрүм ителгән булган. Бала исә беренче тапкыр җинаять ясаганнан соң, киңәшкә әтисе янына килә. Ләкин әтисе аны куып кына чыгара.

Олегның әтисе, улын тәрбияләүгә караганда эчүчелекне өстен күргән. Камилнең дә әтисе шундый юлга баскан.

Дөрес, малайларның әниләре аларны дөрес тәрбияләү өчен тырышканнар. Ләкин, һәркемгә билгеле булганча, әни кешегә гаиләдә барлык вазифаларны да үтәү кыенга туры килә. Барыннан да бигрәк, балага гаиләдә үрнәк кирәк. Ир бала аеруча атага охшарга омтылучан була.

Билгеле, һәр ата-ана да балага бертөрле тәрбия бирә алмаска мөмкин. Мондый очракта мәктәп иң якын ярдәмче булырга тиеш. Үсмерләр язмышында ул нинди роль уйнаган соң? Дөресен әйтергә кирәк, чын мәгънәсендә тәрбия мәктәбе була алмаган ул. Әйтик, Олег Васильев мәктәптә үк берничә тапкыр җинаять эшләгән: классташының 30 сум акчасын урлаган, киемнәр элә торган бүлмәдән икенче бер иптәшенең мех эчле ботинкасын алып киткән. Аның бу җинаятьләре үз вакытында ачылган. Ләкин бу эшләргә укытучылар коллективының артык исе китмәгән. Алар Олегны класста тикшереп, вәгазь уку белән генә чикләнгәннәр.

23 нче мәктәп укучысы Камил Гафаров балалар инспекциясендә күптәннән бирле исәптә тора. Әмма шушы вакыт эчендә бөтен бер коллективның аны дөрес юлга алып чыгарга көче җитмәгән. Бу очракта урам йогынтысы, мәктәптә Камил белән үткәрелгән чараларга караганда үтемлерәк булган. Балалар инспекциясе шулай ук кичекмәстән чара күрмәгән, үсмерләр белән тәрбия эше алып барырга да ашыкмаган. Алар да кичен малайларның өйдә булу-булмауларын ачыклау белән генә чикләнгәннәр. Ә үсмер урамда нишләп йөри, кемнәр белән дус, кайларда була? Бу сораулар аларны әллә ни кызыксындырмаган. Кызганычка каршы, инспекция әле үзе башкарырга тиеш төп вазифаны — исәптә торучы балалар белән эшләүне җайга салмаган. Моның үзенә күрә сәбәпләре дә бар кебек. Беренчедән, штат кыска. Инспектор эш вакытының шактый өлешен теге яки бу оешмага белешмә, информация биреп

үткәрә. Аның мәктәптә булып, тәрбиягә авыр бирелә торган укучы белән очрашып сөйләшергә, үсмернең укуы, үзүзен тотышы, буш сәгатьләрен ничек үткәрүе белән кызыксынырга вакыты калмый диярлек. Шунлыктан ул мәктәпкә килгән очракта да, директор яки аның тәрбия эшләре буенча урынбасары янына кереп, үзенә кирәкле мәгълүматлар алу белән генә чикләнергә мәҗбүр. 2 нче интернат-мәктәп укучысы Марат Вахитовның язмышы кыл өстендә торганда да нәкъ менә шулай килеп чыккан. Совет районы балалар инспекциясе малайның җинаять юлына басуын күреп, белеп торган. Ләкин нинди дер чара күрергә, хәтта аны исәпкә алырга да ашыкмаган. Бу хакта мәктәпкә хәбәр итү белән чикләнгән.

Хәзер инде җинаять кылынган. Эш узган, суд булган, гаепләнүчеләр тиешле җәзасын алган. Әмма бу күңелсез вакыйга калганнарга — әлегә җиде юл чатында адашып калган үсмерләргә дә, үсмерләр язмышына кагылышлы кешеләргә һәм оешмаларга да сабак булсын, аларга да, әниләренә дә соңарган күз яшьләре түгәргә туры килмәсен иде.

Роза Рәхмәтуллина

АРМИЯ ТОРМЫШЫННАН БЕРНИЧӘ КӨН

Элек мин Армия хезмәтен «Советлар Союзына хезмәт итәм!» дигән тапшырулар буенча гына белә идем. Баксаң, армия тормышының башка — уставка сыешмый торган яклары да бар икән әле. Демократия, хәбәрдарлык арткан саен бу өлкәгә дә көн яктысы үтеп керә башлады. Шул форсаттан файдаланып, мин үземнең кайбер тәэсирләрем белән уртаклашмакчы булам.

Рота командиры — өлкән лейтенант Видаков кызык кеше булып чыкты. Характеры кискен, капыл кабынып китүчән, мондагыча әйтсәк, «дуремар». Тагын шул ачыкланды: ул студентларны күралмый икән.

Безнең беренче танышу болай булды:

— Синең исемең ничек?

— Риф.
— Студентмы?
— Юк.
— Алдашма, студент икәнең танавыңа чыккан.
— Гафу итегез, иптәш өлкән лейтенант, әмма мин студент түгел.
— Күрсәт әле кулларыңны!

Мин кулларымны алга суздым. Ул текәлеп карады һәм куанычлы ачыш ясагандай кычкырып җибәрде:

— Ә-ә, син бит чикылдаган студент!

Шаярудан башланган кебек тоелган сөйләшү кинәт һич уйламаган якка борылды. Кешенең кәефе шулай кискен үзгәрергә мөмкин микәнни? Лейтенант капыл гына ярсып китте, күзләре акайды һәм аты-юлы белән сүгенә башлады. «...Нарядка сине, сука! Мин сине ничек яшәтергә белермен, студент!»— сүгенү өянәге әнә шундый сүзләр белән тәмамланды. Әйе, бик үзенчәлекле кеше. Күрәсең, нәфрәт инде маниягә әверелгән. Йөрәккә якын алмаска кирәк, мондыйларга үпкәләү — үзе үк ахмаклык. Их, ярар, ни булса шул булыр!

...Отбой игълан ителде. Йокларга ятабыз. Күзләремне йомам: «Менә хезмәтнең тагын бер көне узды». Тагын туган йорт искә төшә, сагыну, ялгызлык хисе. Йоклап китәм...

Колак төбемдә кискен тавыш яңгырый: «Встать!» Күзләремне ачам, торыр вакыт җитте микәнни? Юк, тәрәзәләрдә караңгылык — төн узмаган, эш нәрсәдә? Янымда солдат басып тора (йөзе таныш, ул безнең ротадан). «Нәрсә булды?» — дип сорыйм. «Киттек каптеркага. Багышлау үткәрәбез!» Берни дә аңламыйм, әмма аның артыннан кузгалам. Каптерка — солдат мөлкәтләре склады: шинельләр, бушлатлар. Күрәм, карантин вакытында танышкан иптәшләремне дә бирегә алып килгәннәр; барысы да йокылы-уяулы. «Кызык, нәрсә булыр икән? Мәшәкатьле солдат тормышы. Көндез дә, төнлә дә тынгы юк». Каптеркага тагын өч «карт» солдат керә.

Беренчесе сүз башлый: «Бездә шундый тәртип: бер ел борының белән җир сөрәсең, аннан бер ел ял итәсең».

Сүз дәвамында шулар аңлашыла: хезмәт срогы һәркайсы яртышар елдан торган дүрт этапка бүленә икән: «салабоннар», «молодойлар», «черпаклар» һәм «дедушкалар». Салабоннар һәм молодойларның төп бурычы — «сөрү». Бу нәрсә дигән сүз? Бөтен кара эшне үз өстеңә алу, дедушкаларны карау-тәрбияләү, йомышчы һәм хезмәтче булу. Чер-

пaклар белән дедушкалар, әлбәттә, сөрүдән азат, алар арыганнар. Салабоннар һәм молодойлар кеше чутына керми. Буйсынмасалар, аларны җәза көтә. Гомумән, «карт»лар теләсә нәрсә кылана алалар. Тышкы кыяфәттә дә аерма булырга тиеш: молодойларга солдат киемен үзгәртеп тегү, шачоклар тагу тыела, барысы да Уставта язылганча гына булырга тиеш.

Багышлау тәгәлләнде: «Я, ничек, егетләр, политика аңлашылдымы?» Барысы да, нишләптер, карусыз гына рилалаштылар. Нигә алар минем өчен дә җавап бирә? Шулай кирәкме соң, тиешме?

Армиядәге дедовщина турында миңа гражданкада күп ишетергә туры килде. Өлкәнрәк дусларым һәм иптәшләрем кайбер частьларда язылмаган законнар яшәве, яшь солдатларның «картларга» хезмәт итүе, ә үзләре «картайгач» башкаларны изеп яшәүләре турында сөйләделәр. Һәр яшь солдат шушы сынау аша уза, диделәр. Дедовщина бүре законнары буенча яшәү булып чыга лабаса! Авыр уйлар белән йокларга яттым. Күзләремне йомдым...

Кемдер бөтен көченә җилкәмнән селкетә. Уянасым килми. «Тор!» Күзләремне ачсам, каршымда таныш түгел сержант. Тәрәзәләрдә караңгылык — димәк, төн. «Ник?»— дип сорыйм. «Киттек!» — ди сержант.

Кузгалабыз. Ул мине дневальный янына алып килә: «Менә сиңа салабон». Һәм китеп бара. Дневальныйның пыялаланган күзләрендә — бушлык.

— Нигә кирәк булдым?— дип сорыйм.

— 5.40 ка кадәр биредә торачаксың,— ди дневальный,— аннан мине уятасың. Аңлашылдымы?

Аңлашылмады, билгеле: мин бит нарядта түгел. Шуңа күрә сорау бирәм:

— Ә мин кайчан йокларга тиеш?

— Син салабон әле. Аңладыңмы?

Әйе, аңладым, мин кеше түгел икән.

Дневальныйга аның өчен нарядта торырга җыенмавым турында белдердем. Ул минем өскә ташлана, тибә һәм... йокларга китеп бара. Мин чуалган зиһенемне туплап урынымда басып калам, сәгатемә карыйм —1.20. Дневальный турында уйлыйм: чып-чын дебил. Аның өчен мин монда каңгыраеп торыр дип ышана микәнни? Юк инде, үләсәм үләм, әмма мондый мескенлеккә төшмим. Һәм мин урыныма барып ятам. Күңелдә астыртын уй бөтерелә: «Нәрсә булып бетәсен иртәгә күрербез».

Иртән барыбызны да сикертеп торгызалар. Ашыга-ашыга киенәбез. Тезеләбез. Коридорда капитан — батальон де-

журные котырынып йөри: «Кая дневальный»! Ниһаять йокысыннан айнып өлгермәгән дневальный күренә. «Чират тан тыш өч наряд!» Шул кирәк аңа, дип уйлыйм эчтән генә

...Берсүзсез буйсыну дигән нәрсәгә һич иялэшеп бет алмыйм. Уставта: армия буйсынучыларга һәм начальник ларга бүленә дип язылган. Мин аңламыйм, сугыш вакы тында шулай булырга тиеш, әмма тыныч шартларда мон дый бүленешнең кирәге бармы соң? Устав бөтен нәрсәне (вак-төяккә кадәр) регламентлый. Мисал өчен, рядовой үзеннән югары хәрби хезмәткәрләр яныннан узганда честь бирергә тиеш. Бу таләп һәрвакыт үтәләме соң? Солдат прапорщикка честь бирсә рәхмәт әйтерсең, ә сержантка бирми дә бирми инде ул. Уставлар ничек кенә дөрес, яхшы булмасыннар, үтәлмәгәч аларның хаҗәте нигә?

Һәм, гомумән, властьны акыллы кешеләр кулына бирергә кирәк. Әгәр керделе-чыктылы кеше баш булып алса? Ул чагында нишләргә? Бу нисбәттән армия тормышында җанлы мисаллар җитәрлек. «Мин фәлән-фәләннәрне эшләргә боерам!» Ә ул фәләннәрне эшләү зур ахмаклык һәм мәгънәсезлек булса? Алай түгел бит дип каршы төшеп кара — стенага төртеләчәксең. Нәтиҗәдә, һәрнәрсәгә карата битарафлык туа.

Сезнең генерал килер алдыннан сары чирәмне яшел төскә буяганыгыз яки «яшел күренешне бозмасын өчен» миллионнарча сары тузганак чәчәкләрен йолкыганыгыз бармы? Безнең булгалады. Ә берзаман кара төстә булсын өчен строевой плацны итек щеткасы белән ваксалап чыгарга мәҗбүр иттеләр. Болар армиядә миңа үз күзләрем белән күрергә туры килгән тилелек, идиотлыкның (бүтәнчә ни дисәң?) өстә ярылып яткан кайбер кечкенә мисаллары гына.

Ахмак боерыкларны үтәргәме! Үтәми ярамый — Устав куша, ә үтәсәң — үзең үк ахмаклык тудырасың. Уйламаучыларга (роботларга) рәхәт. Ә мин, кызганычка каршы, моңа өйрәнмәгән. Армия кайчагында шундый бурычлар куя ки, ничек ерып чыгарга белми аптырап каласың. Менә бүген рота командиры боерык бирде: «Төнлә төзелеш объектына барып торбалар, цемент һәм кулга ни эләксә шуны урлап кайтырга. Моны сиздерми генә эшләргә һәм тотылмаска. Боерык бирелгән икән, үтәргә кирәк. Ләкин ничек итеп? Монысы табышмак. Урламасаң да, урлаганда тотылсаң да, син үзең гаепле булачаксың.

...Минем белән аеруча нык кызыксынучыларның берсе «карт» Васька.

— Әй, карале, синең тормыш максатың бармы?

— Бар, әлбәттә.

— Ә ни өчен кешечә яшәмисең: тәмәке тартмыйсың, сүгенмисең? Гражданкадагы гадәтләреңне онытырга вакыт инде.

— Мин үземчә, үз принципларым буенча яшим.

— Хыялый, армиядә нинди принциплар ди ул? Мин сиңа нәрсә кушам, син шуны үтисең — менә шул була принцип. Аңладыңмы? Яле, сүгенеп җибәр! Ишетәсеңме, мин сиңа сүгенергә боерам!

Мин дәшмим.

— Тор! Минем янга кил!

Мин кымшанмыйм.

— Сүгенәсеңме, юкмы? Хәзер мин сине кыйный башлыйм.

— Юкка тузынасың, барыбер сүгенмәячәкмен!

— Син мине аңламадың ахры, солдат. Мин синең белән кети-мети уйнарга җыенмыйм. Хәзер тотып изәм, аннан төне буе аягүрә бастырып торгызам.

Вася каршыма килеп баса.

— Син нигә минем боерыкларны үтәмисең?— Кизәнә. Аннан китереп суга. Мин дәшмим. Бөтен көчемне йодрыгыма туплап, үзенә дә әйләндереп җибәрәм. Вася бер мәлгә өнсез кала:

— Син беләсеңме нәрсә эшләдең? «Карт»ка суктың. Беләсеңме моның өчен нәрсә була? Ник туганыңа үкенерлек итәм мин сине.

Мин берни булмаган кыяфәттә урыныма барып ятам. Вася һаман китми, канысуын дәвам итә:

— Син, үҗәт салабон, армия тормышының нәрсә икәнен белмисең әле, әмма беләчәксең.

Мин Васяның мыгырдануын тыңлый-тыңлый уйланып ятам. Бездә, яшьләрдә, оешканлык, бердәмлек юк шул. Кая ул «карт»ларга җиту, аларда чып-чын мафия.

— Менә моның аркасында бүген салабоннар йокламаячак,— ди Вася һәм миңа төртеп күрсәтә.— Бүген төне буе сөрәчәксез. Салабоннар — каптеркага!

Иптәшләрем карусыз гына кузгалалар. Җаным әрнүгә түзә алмый торып басам, ләкин мине шунда ук ике «карт» тотып ала: «Кая киттең, салабон, син йокла, ял ит, ә иптәшләрең сөрсеннәр». Нинди кабахәт тактика, әмма тиешле тәэсирне ясый. Нәрсә эшләргә? Барысы да мине башкаларга каршы куюга юнәлдерелгән.

Иртән артымнан каравыллап йөрүчеләр күренмәгәндә, җаен туры китереп, иптәшләремә мөрәҗәгать итәм:

«Егетләр, аңлагыз, алар сезне юри миңа каршы котырталар». Егетләр хәлне аңлаганнарын белдереп башларын изиләр: «Ярар инде, әйдә, түзәрбез». Әмма сизеп торам: кайберәүләр инде хәзер үк кырын карый башладылар. Нәрсә эшләргә, бу хәлдән ничек котылырга, дип көне буе баш ватам. Нињаять, катгый карарга киләм: сугышырга — нәрсә булса шул булыр.

Отбой. Каравылчыларым һаман янәшәмдә бөтереләмине ял иттерәләр. Түзәр әмәлем калмагач, берсенең йөзенә китереп сугам. Картлар көтүләре белән өстемә ташланалар һәм, кулларымны каерып тотып, дөмбәсли башлыйлар. Шайтан алгыры, бөерне эштән чыгаралар ахры. Ишек артында Васьканың тавышы ишетелә: «Салабоныгыз аркасында таң атканчы сөрәчәксез. Кешечә яшисегез килсә, акылга утыртыгыз үзен!» Әллә кичерешләр тәэсире, әллә кан басымы — борын каный башлады. Юынып килергә кирәк. Ләкин юлны бүләләр: «Кая барасың, эшлексез?..» «Юынырга, дим, бу хәлдә офицерлар күрсә нәрсә әйтерләр? Аргумент ышандыра. Арттан Вася кычкырып кала: «5 минуттан әйләнеп киләсе бул, тикшерәчәкмен».

Иптәшләрем коридорда идән юалар. Климов күзенен агы белән карап кала: ул бик йомшак кеше, аны хәзер кем күпме тели, шуның кадәр изә. Электр щитына җиткәч, башка кинәт бер уй килә. Җәһәт кенә щитның капкачын ачам. Күрәм, егетләр катып калды, дөрес аңламадылар ахрысы. Минем кулда тимер торба. Аны сак кына өч контакт аша уздырам. Бу бик куркыныч, ләкин баш мие төгәл эшли. Бер секундтан мин торбаны кулдан ычкындырам, үзем читкә сикерәм. Шартлау тавышы яңгырый, ут көлтәсе атылып чыга, очкыннар сибелә, аннан тирә-як караңгылыкка чума. Ә миңа күңелле, мин көләм, чөнки моны мин эшләдем. Караңгылыкка күз ияләнгәч янәшәмдә Васьканың төсе качкан йөзен, хайвани курку белән туры карашын күрәм. Кинәт ул көлә башлый: «Син исәнмени, салабон! Ә мин тагын....

...Бүген мин нарядта, тагын йокы туймаячак. Иң йончыткан нәрсә — физик ару. Каршы торырга бернинди көч юк. Әллә бу принцип дигән нәрсәләрдән ваз кичәргәме? Туйдырды, гарык булдым. Мәкерле тавыш колакка пышылдый: «Мондый җәмгыятьтә принципларны кушканча яшәп буламыни? Төкер барысына да». Бөтен тәндә, җанда — битарафлык, хайвани миңгерәүлек. Димәк, кыйблама арт белән борылырга? Юк, бу беркайчан да булмаячак. Алар мине берничек тә сындыра алмаячаклар!

Ниһаять, нарядтан кайтып урыныма аудым, җеп өзәрлек тә хәлем калмаган. Янәшәмдә күршем кыбырсып ята. Йоклый алмый, күрәсең. Ул — дембель. Инде өч айдан бирле өенә кайтып китәргә җыена. Һаман да китә алганы юк. Менә ул торып утырды, авызына тәмәке капты һәм шырпы эзли башлады. Тапмады. Аннан миңа текәлде: «Салабон, шырпы!»

— Мин тартмыйм.

— Синең тарту-тартмавың мине кызыксындырмый. Бар, шырпы эзләп кил!

Мин дәшмим. Дембель кискен генә күкрәгемә тибә.

— Син нәрсә, салабон...

Мин кузгалам, ләкин шырпы эзләргә түгел, ә юынырга. Нервлар соңгы чиккәчә тартылган, елыйм. Ярый әле, берәү дә күз яшьләремне күрми. Җитте, бүтән мондый мәсхәрәләүләргә түзеп тормаячакмын. Бераз тынычлангач урыныма киләм, шырпы турында оныттым. Ләкин дошманым онытмаган, ул шырпы көтеп утыра. Көт әйдә, көт.

— Син кайда йөрисең, шырпы алып килдеңме?

Дәшмим.

Ул чыгырыннан чыга башлый. Белеп торам, хәзер йодрыкларын эшкә җигәчәк, әмма мин җавапсыз калмаячакмын, тик ул бу хакта белми. Дембель эчемә китереп суга. Мин сыгылып төшәм һәм кинәт тынычланып калам. Мин аннан курыкмыйм, тик ул көчле. Аны җиңеп булмаячак. Мин читкә сикерәм һәм кулыма табуретка эләктерәм. «Рота, подъем!»— дип кычкырам. Табуретка дембель өстенә оча. Хәзер ул аягына басачак, аннан инде хәлләр мөшкел булачак. Шуңа күрә йөгереп килеп аны караваты белән бергә әйләндереп ыргытам. Мә, сиңа! «Рота, подъем!»— бу юлы тавышым тагын да көчлерәк яңгырый. Күпләр күзләрен ачты, нәрсә булганын аңлый алмыйча аптырашып калдылар. Ә бу вакытта табуреткалар мине рәнҗетүчеләр өстенә оча. Үземнең җитезлегемә үзем гаҗәпләнеп мин табуреткаларны уңга-сулга тондыруымны дәвам итәм. Кайберәүләр котырынып сикереп тордылар. Мин почмакка таба чигенәм. Беләм, хәзер изәчәкләр. Битем ут яна, сулышым еш, йөрәк читлегеннән чыгам-чыгам дип тибә. Кинәт башыма нәрсә беләндер китереп суктылар. Мин стенага ышкылып акрын гына чүгә башладым. Ниндидер караңгылык пәрдәсе аша сизәм — кыйныйлар: биткә түгел,- ә тәнгә сугалар...

Һушыма килгәндә мин салкын идәндә ята идем. Бөтен кием манма су булган. Туңудан бөтен тәнем калтырана, аркам сызлый, эчемнең әллә кай җирләре авырта. Кайда

соң мин? Ә, бытовкада икән. Торып басам. Тез буыннарым калтырый. Чыкмакчы булам: ишекне тыштан бикләгәннәр. Тагын идәнгә ятам. Йоклап китеп булмый, бөтен тәнем-җаным яна һәм калтырана. Теге кабахәтләрнең мине ничек кыйнауларын искә төшерәм.

Тагын аякка басам. Тукта, тәрәзә ачыла икән бит. Тәвәккәлләргә кирәк: биек түгел, беренче кат кына... Вакыт 4.10. Казарма йоклый. Дневальный күзләрен түгәрәкләндереп карап кала. Мин кулыма яңадан табуретка алам. Кемнән башларга? «Рота, подъем!»— дип кычкырам. Бу юлы барысы да бик тиз уяна. Мин яшен кебек очам. Хуҗалары белән бергә берсе артыннан берсе караватлар әйләнә, табуреткалар оча. Бу юлы мин өскә килгәннәрен күтәп тормыйм, үзем беренче булып ташланам. Мин юләр кеше сыман, үзем кемгә сукканымны да, миңа кемнәр сукканын да сизмим. Мине матрацлар белән каплыйлар, кулларымнан әләктерәләр, кыйныйлар. Мин тыпырчынам һәм аңымны җуям...

Бу юлы каптеркада аңыма килдем. Баш чатный, хәл юк. Гәүдәмне кемнәрдер капшый сыман. Ике «карт» килгән икән: «Тор, сәгать 9,— диләр.— Хәлләр ничек?» Дәшмим. Сизәм, боларга минем хәл-әхвәлне ачыклау бик мөһим. Берсе сүз башлый: «Куркытып та куйдың үзең: беркем берни аңламый...» Дәшмим. «Нарядта булуың яхшы әле. Синең белән беркем дә кызыксынмады». Һәм, ниһаять, иң төп сорауны бирә: «Сатачаксыңмы инде хәзер?» «Сатсаң» бик әйбәт булыр иде бит, ләкин бу минем принципларга туры килми. Гадәттә, көчсезләр генә әләкләшә һәм зарлана. Шуңа күрә мин «юк» дигәнне аңлатып башымны селким. Картларның йөзләре ачылып китә: «Ә син чын салабон».

...Отбой. Кубрик. Караңгылык. Сөйләшеп яту, кагыйдә буларак, картларга гына рөхсәт ителә, салабоннар сорауларга җавап кына бирергә тиеш.

— Их, егетләр, гражданкада минем күпме кызларым булганны белсәгез иде сез,— дип, сүз башлый Саня.— Миңә хәзер шуларның берәрсе монда ятсын иде.

— Алай тәкатең калмагач, самоходка чыгып кер.

— Юк, бүген Вайтенко тикшереп йөри, шунда ук сизеп алачак. Ә гомумән алганда, хатын-кызларның барысы да фәхеш җаннар. Аларга ышанырга ярамый. Гражданкада чакта без егетләр белән күрше авылга танцыга йөри идек. Салып алабыз да, «Ява»ларга утырып элдертәбез. Аны беренче тапкыр шунда күрдем. Нәзек кенә, кечкенә генә... Күрүем

булды — иссез-һушсыз калдым. Ярый, таныштык. Мила исемле, фельдшер булып эшли. Кешелекле, йомшак характерлы. Мин өйләнергә карар бирдем. Үзенә дә әйттем: шулай-шулай, яратам дим. Бу елап ук җибәрде: «Юк, булмый. Мин инде кыз түгел»,— ди. Ә мин ул чагында малайшалай кебек муеннан гашыйк. «Син нинди булсаң да миңа барыбер. Син — минеке, мин синеке, беркемгә дә бирмим»,— дим. Шулай дидем дә, туйга әзерләнергә кайтып киттем. Берзаман шул авылда яшәүче туган тиешле кешебез йөгереп килгән: «Акылыңнан шаштың мәллә? Син ул Миланың кем икәнен беләсеңме?— ди.— Ул бит өстерәлчек, кем сораса шуңа биреп йөри!»

Билгеле, мин ышанмадым ышануын, әмма күңелгә шик төште. Төн уртасында моның өенә барып кердем. Һәм нәрсә булды дип уйлыйсыз? Рәхәтләнеп бирәү белән йоклап ята. «Мин мәңгегә синеке генә!»— дигән кеше. Чак кына суймадым үзен...

— Әйе, хатын-кыз мәче белән бер инде ул.

— Ә теге туган тиешле кешене тотып кыйнадым.

— Ә нәрсә өчен, Саша?

— Күп белгәне өчен. Мин ул Миланы әле дә оныта алмыйм...

Төнге сөйләшү дәвам итә, ә мин Ленаны искә төшерәм. Сөйкемле һәм саф күңелле Лена. Кайда син хәзер, нишлисең? Нигә синнән һаман да җавап юк?..

— Салабон, әй, радиомастер, ишетәсеңме? (радиомастер — минем кушамат)

— Радиомастер, йоклап киттең мәллә?

— Юк.

— Ә ник дәшмисең? Телеңне йоттыңмы?

— Минем исемем бар.

— Харап икән, салабонның исеме бар! Сиңа исемең белән бер елдан эндәшә башлаячаклар. Ярар инде — миннән булсын яхшылык. Риф, синең кызың бармы?

— Анысы минем эш.

— Климов, аның кызы бармы?

— Бар дип әйткән иде шикелле. Лена исемле бугай.

— Радиомастер, ә син аның кызлыгын алдыңмы?

Мин дәшмим. Бөтенесе дә канәгать, ә Васька көлә. Һәм үзенең яраткан темасын башлый:

— Хатын-кыз белән эш итүнең дә җае бар. Менә, безнең салабонны гына алыгыз: нәрсә белә ул бу тормышта? Ул хатын-кызның кулына кагылырга да куркадыр әле, ә үзен әллә кемгә куйган булып маташа: ир кеше, янәсе.

Нindидер принциплар уйлап чыгарган, дуңгыз. Әй, син мине ишетәсеңме?

— Ишетәм.

— Син нигә һаман үз киреңә катып йөрисең? Мин сине барыбер сындырачакмын. Сине стукач (әләкче дигән мәгънәдә.— *ред.)* итәргә кирәк. Син бит стукач, шулай бит?

— Юк.

— Стукач. Сиңа безнең тормыш ошамый бит. Сине мыскыл итәләр, кыйныйлар, ә барыбер бөтен нәрсәгә тыгыласың, кысыласың. Син дә стукач булмыйча, кем булсын тагын!

— Җитәр, телеңне тый!

— Минем исем-акылым китә: нинди кеше соң син? Синең кебекләрне армиядә үтерәләр. Телисеңме, сине алда нәрсә көткәнен әйтеп бирәм: син яки частьтан качачаксың яки атылачаксың. Шулай бит?

— Хыяллану беркемгә дә тыелмый. Ә инде эш атышуга килеп терәлсә, башта мин сине атачакмын, Вася.

— Син нигә шундый киребеткән, ә? Кем дип беләсең син үзеңне? Син бит чүп, буш урын, әрвах. Бөтен кеше кеше төсле, ә син... Кем соң син?

— Кеше... ә син дебил...

...Ул солдат миңа башта ук бик сәер күренде. Өстендә соңгы үлчәмдәге пычрак гимнастерка, бөтен килеш-килбәте шыксыз, эленке-салынкы. Аңа күз ташлау белән, бу — салабон дип әйтергә мөмкин. Әмма мин төгәл беләм: ул инде ел ярым хезмәт итә. Һәр солдат аны типкәләргә-төрткәләргә генә тора, теле белән дә, кулы белән дә төрлечә мәсхәрәли. Ә ул, әзмәвердәй гәүдәле була торып, дәшмитынмый гына йөри, барысына да түзә. Ник ул мондый эт типкесенә калган? Сәбәбен карт солдатлар аңлатты, шул ук Васька да төшендереп бирде: «...Ә, Штупинковны әйтәсеңме, стукач бит ул. Офицерлар колагына пышылдап йөрүче. Танавы белән җир сөрүче».

— Ә ник алай?

— Әйтеп торам бит, стукач дип. Безнең бер егетне саткан кабахәт! Шуннан стукачка әйләнде. Хәзер үлгәнче өшкереләчәк. Әгәр теләсәң барып берне сылый аласың, мин рөхсәт итәм. Телисеңме, аңа синең аяк чолгауларыңны юдыртабыз?

Шулай итеп Штупинковның кем икәнлеге аңлашылды. Армиядә шикаятьчеләрне, әләкләшүчеләрне гомумән яратмыйлар, кешегә санамыйлар. Биредә язылмаган традиция яши: әгәр армия коллективы тормышы, атмосферасы сиңа

ошамый икән — аны үзең хәл ит: каршы чык, үздереп фикереңне әйт, кирәк икән — сугыш, әмма беркайчан да кешене сатма, зарланма. Үзен яклый алмаган кешене бирәдә ихтирам итмиләр. Әгәр инде ул, җиңеллек өмет итеп, зарлана башласа, аңа бөтенләй көн бетә.

Мондый кешеләр минем үземә дә ошамый, чөнки аларның политикасы тайгак: бер яктан зарланалар (бу протестның бер формасы — дедовщинага каршы чыгу булсын ич), ә икенче яктан шул дедовщина системасына карусыз буйсыналар — «сөрәләр» дә «сөрәләр». Әгәр дедовщина белән кендегеңне өзгәнсең икән, нигә үзеңне гаепле кеше сыман хис итәргә, «картлар»ның артыннан җыештырырга, аз гына да каршылык күрсәтмичә, төрле мыскыллауларга түзеп яшәргә? Мондый кешеләрнең язмышы бик аянычлы. Алар муеннан эшкә батканлыктан үзләрен карарга өлгермиләр, шуның нәтиҗәсендә офицерлар тарафыннан да җәбер-золым күрә башлыйлар. Кыскасы, мондыйлар шәхес булудан туктыйлар, бөтен кешелек сыйфатларын югалталар... (Бу аларның армия тормышыннан соңгы язмышларына да йогынты ясамый калмыйдыр, мөгаен.)

Ләкин арада бүтән төрлеләр дә очрый. Менә, мисалга Виталикны алыйк. Ни өчендер, белмим, аны берарада стукач дип саный башлаганнар. Әмма бу егетне мәҗбүриләп эшләтергә яки мыксылларга омтылып кара син! Үлсә үлә, әмма үзен рәнҗетергә бирми. Мин аңлыйм, аңа бу чорны кичерү бер дә җиңел булмагандыр. Ләкин ул бирешмәгән. Хәзер аны беркем дә стукачка санамый һәм ул хәтта «картлар» арасында да тиз арада хөрмәт яулады.

Гражданкада миңа кешеләрнең барысы да диярлек әйбәт кебек тоела иде. Ничек нык хаталанганмын. Еш кына кешегә килеш-килбәтеннән чыгып бәя бирәсең, ә бит чын кеше теләсә нинди шартларда да чын кеше булып калырга тиеш. Хәзер мин матур һәм дөрес сүзләр генә сөйләүчеләргә шикләнебрәк карыйм: бу битлек кенә түгел микән?

Менә бер мисал. Карантинда мин Мәскәү егете Роман белән таныштым. Белемле, укымышлы, ә иң мөһиме — уй-фикерләре туры һәм дөрес. Ул үзен коллектив җанлы, тирән культуралы иптәш буларак күрсәтте. Мин аңа бераз көнләшеп тә карый идем: «Менә, ичмасам, бу кеше. Ул үзенең идеалларыннан беркайчан да читкә тайпылмаячак». Бераздан, гаҗәпләнүемә каршы, аның дедовщина алдында баш июен күрдем: каршылык күрсәтергә маташып та карамады. Ә мин тагын үземчә уйлап йөргән булам: Роман,

энәсе, үзен түбәнсетергә, рухын сындырырга юл куймая
чак.

Әлбәттә, явызлыкка каршы чыгу бөтен кешенең д
хәленнән килми, чөнки моның өчен егетлек, характер, их
тыяр көче кирәк. Соры масса булып, көтү нәрсә эшләс
шуны кабатлап йөрү җиңелрәк. Ләкин, минемчә, агымг
каршы бара алган, үз кыйбласын югалтмаган, бүтәннә
кайгысына битараф калмаган кеше генә үзен чын кеш
дип санарга хаклы.

...Мин беләм, күп кенә яшьләр армия хезмәтенә тискәр
мөнәсәбәттә. Соңгы вакытларда пацифистик карашлар д
көчәя бара. Бу нилектән шулай?

Армия кешене чыныктыручы һәм чын ир итеп тәрбия
ләүче мәктәп диләр. Монысын бөтенләй үк кире кагып бул
мый. Бүгенге яшь кеше матур киенергә, йомшакта йоклар
га, тәмле ашарга күнеккән. Әзергә-бәзер яшәргә өйрәнгән
нәр өчен армия — кырыс мәктәп. Гражданкада син — шә
хес, син, юк сәбәпне бар итеп, кара тавыш чыгара аласың
бөтен нәрсәне «мин телим», «миңа кирәк» дигән канунна
чыгып бәялисең. Гражданкада тискәре сыйфатларыңны
тирәнгәрәк яшереп, кешеләргә яхшы сыйфатларыңны калку
итеп күрсәтү мөмкинлеге бар. Гражданкада җәмәгатьчелек
ихтирамын казану да җиңелрәк: эштә — син хезмәт баты
ры, өеңдә — кайтасың да сузылып ятасың.

Армия бөтенләй икенче дөнья. Чәчеңне кыркыткач һәм
өстеңә солдат формасы киеп алгач, син үз йөзеңне югал
тасың. Хәзер инде башкалар нинди булса, син дә шундый.
Биредә өскә калкып чыгу, коллективның ихтирамын яулау
ай-һай авыр, гражданкада үзеңне кабатланмас кеше дип
санарга күнеккән булсаң, бигрәк тә. Рухи яктан да бик
авыр. Яшерен-батырын түгел, кайберәүләрнең канатлары
каерыла, дөньяга карашлары үзгәрә, ә кайберәүләр хәтта
кешелеклелек сыйфатларын югалталар. Арада протест белдерергә омтылучылар, хәтта атылучылар да очрый. Мин
андыйларның позициясен кабул итә алмыйм: кеше ничек
кенә булса да чыгу юлын табарга, тормыш куйган мәсьәләне чишәргә тиеш. Шуның өчен ул Кеше дип атала. Матур сүзләр, китаптан укылган канатлы фикерләр артында
эш, инану торырга тиеш. Шулай булмаганда синең матур
уйларың һәм хыялларың — коры сафсата. Матур хыяллар
гамәлгә ашсын өчен бөтен көчеңне һәм сәләтләреңне җигеп эшләргә кирәк. Гамәлгә ашырылган идеяләр генә яшәүчән һәм тормышчан.

Әгәр син бүген явызлыкка каршы чыга алмыйсың, моның өчен үзеңдә сәләт тә, көч тә сизмисең икән, син нинди Ватан сакчысы?

...Васька — дембель. Тиздән ул поездга утырып өенә кайтып китәчәк. Моннан бер атна элек комбат боерык укый: «Үрнәк хезмәт иткәне өчен сержант Василий Николаевны запаска старшина званиесе биреп чыгарырга».

Язмыш ниләр күрсәтми: мондый «үрнәк хезмәт» өчен аңа дисбат та аз.

Башкалардан аермалы буларак, Вася минем белән дусларча хушлаша. Мин җавап бирмим, чөнки үткәннәрне онытмадым. Әмма ул үпкәләми, аңлыйдыр, күрәсең...

...**Дедовщинаның тамырлары кая барып** тоташа? Кемдер әйткән: «Кешедән дә гүзәлрәк һәм кешедән дә куркынычрак берни дә юк»,— дигән. Бу фикер белән тулысынча килешәм. Кешегә акыл бирелгән, ә явызлыкка юнәлдерелгән акылдан да куркынычрак тагын нәрсә бар?

Дедовщинаның сәбәпләрен мин, беренчедән, хәрби частьларда дисциплинаның начар булуыннан күрәм. Элементарь тәртип булмаган, Устав таләпләре үтәлмәгән һәм һәр адымда күз буяучылык хакимлек иткән частьларда дедовщина гөрләп чәчәк ата. Икенчедән, офицерларның хәрби хезмәткә мөнәсәбәте бу мәсьәләдә хәлиткеч роль уйный. Әгәр офицер үз бурычын намус белән үти, солдат тормышының бөтен нечкәлекләренә үтеп керә икән, биредә дедовщинага баш калкытуы авыр. Әмма күпчелек очракта дедовщина офицерга файдалы, нәкъ менә файдалы. Чөнки дедовщина аны күп мәшәкатьләрдән азат итә һәм ниндидер эзлекле бер тәртип урнаштыра. Дедовщина тулы анархия дигән сүз түгел. Ул үзенә күрә бер тактика һәм биредә рольләр бик төгәл бүленгән: максатка ирешү азчылыкка өстенлекләр бирү хисабына тормышка ашырыла.

...Өлкән лейтенант Видаков — сәер кеше. Студент-солдатларны бөтен җаны-тәне белән күралмаса да, аның, гомумән алганда, солдатларга мөнәсәбәте бик яхшы. Әгәр син бу офицерның ротасында икән, тиешле бөтен нәрсәләрне алачагыңны, сине беркайчан да онытмаячакларын төгәл белеп торасың. Бу кешенең арка таянычы булуын сизә башлыйсың.

Кызганыч, әмма солдатларны чын-чынлап аңлаучы офицерлар бик аз. Армиядә хәтта «Офицер — кеше түгел» дигән әйтем дә йөри һәм мондый мәзәк сөйлиләр: солдат

армиядән әнисенә хат яза: «Әни, мин кайтышка эт алы
куй һәм аңа лейтенант Петров дигән исем куш». Әнисе га
җәпләнә: «Улым, нигә сиңа мондый сәер исемле эт?» Җа
вап: «Кайтып керү белән бәреп үтерәчәкмен».

Мондый офицерлар өчен солдатлар — «соры масса»
«эшче көч». Солдатка кычкырырга, сүгенергә мөмкин, бүтә
кешегә булган ачуыңны алу өчен дә солдат бик кулай. Ал
лага шөкер, бөтен офицерлар да мондый түгел, юкса ар
миябез нишләр иде.

Әйе, офицерлар арасында төрле кеше бар. Менә баталь
он командиры. Симез, үшән подполковник. Йөз метрга йө
герсә йөрәге ярылып үләчәк, ә офицер. Аның өчен солдат
гомумән кеше түгел. Көннәрдән бер көнне ул безне бер рай
онга элемтә урнаштырырга җибәрде. Һәм без, бурычы
бызны үтәп, биш тәүлек элемтә сакладык. Ашыгычлык бе
лән китү сәбәпле, коры паек бер тәүлеклек кенә бирелгән
иде. Полковник «Барысын да китерерләр»,— дип вәгъдә ит
кәнлектән, көтәбез, өметләнәбез. Тик тавыш-тын ишетел
ми. Тамак тәмугка кертә ди: кулга нәрсә төшә, шуны ашый
быз. Элемтәне ташлап китеп тә булмый — өйрәнүләр бара
Бишенче тәүлек киткәч боерык килде: «Җире кайтырга»
Без, онытканнарына үпкәләп, арып-талып кайтып кердек
полковникка шәхси доклад ясадык. Һәм нәрсә булды ди
уйлыйсыз? Полковник безне эттән алып эткә салып сүге
ташлады. Баксаң, без аны төшке аш вакытында борчыган
быз икән. Моннан, без кеше исәбенә кермибез икән, дигән
нәтиҗә чыга. Полковникның разводлар вакытында кабат
ларга ярата торган формуласы хәтергә мәңгегә сеңеп кал
ган: «Солдат уйларга тиеш түгел, солдат кушканны гына
үтәргә тиеш!»

...Иртән мине батальон командиры үзенә чакыртып ал
ды. Чырае сытылган, сүгенә, котырына. Мин аны ишетмим
тыңламыйм, миңа барыбер. Аннан замполит үз бүлмәсенә
алып керде: «Нәрсә, дөреслек эзләүче, тагын иске эзгә төш
теңме?» Мин дәшмим. Замполит ишекле-түрле бүлмә буй
лап йөри: «Бәлки син хаклыдыр да. Ләкин армиядә андый
булырга ярамый, аңлыйсыңмы? Син әйбәт солдат, әмма
синең белән яшәү авыр». Сизеп торам, ул миңа нәрсәдер
әйтергә җыена, ләкин җөрьәт итми. Ниһаять, катгый ка
рарга килеп, өздереп әйтә: «Син авырыйсың, хәзер үк сан
частька кит. Боерыкны аңладыңмы? Начмед барысын да
бела, ә бер атнадан командировкага китәрсең».

Армиядә хезмәт итә башлавыма нәкъ 8 ай тулган көнне
санчастьта каршыладым. Кичә рота командиры керде һәм

мине икенче частька күчерүләре турында әйтте. Үзем дә мин шуңа таба бара бугай дип чамалап тора идем. Димәк, барысы да яңадан башлана. Яңадан башлау ул, билгеле, ничар түгел, ләкин мин инде икенче кеше. Дөньяны үзгәртергә уйлаган идем, «астан» шәхси үрнәк белән генә моны эшләп булмаячагына төшендем, үзем өчен нәтиҗәләр ясадым, әмма принципларым үзгәрешсез калды. Дөреслек бер генә, аны чәчәкле-чуклы бизәкләр белән алыштыру мөмкин түгел. Минем иң зур хатам шунда — мин япа-ялгыз идем, ә бәлане күмәк көч белән генә җиңәргә мөмкин. Бергәләшеп, иңгә-иң торып...

Рифкать Зарипов

КЕМНӘРНЕ ҮСТЕРДЕК?..

Казанда шомлы хәбәрләр йөри. Кешеләр, бер-берсеннән ишетеп, җан өшеткеч вакыйгалар турында сөйлиләр: «Өергә-өер сугышучы үсмерләр тагын бер малайны үтергәннәр. Һуштан язып егылганчы кыйнаганнан соң, сәнәк белән кадаганнар...», «Эштән кайтып баручы бер хатын ишетеп торган — берничә үсмер үзара сөйләшә икән: «Әйдә, барып тимерчыбык белән күзенә кадыйбыз, тизрәк үләр...» Бу хатын сиздермичә генә артларыннан киткән, канга батып җирдә ятучы малайны күргәч, сөрән салган. Әлеге хатынны нишләткән булырлар иде, билгесез, бәхетенә каршы, бергә эшләгән иптәшләре килеп чыккан...» һ. б., һ. б.

Әлеге хәбәрләр дөреслеккә ни дәрәҗәдә туры килә? Бәлки кайберәүләр күпертеп яки үзләреннән өстәп сөйлиләрдер? Әйдәгез, икейөзлеләнмичә, дөресен таныйк: хәлләр җитди. Һәм мондый хәлләр турында шомартмыйча, ничек бар, шулай сөйләргә вакыт җиткәндер.

Үз авылындагы хәлне күрше авылдан сора, диләр. Мәскәүдә чыга торган «Неделя» атналыгының 12 нче санында «Усобица разделила молодежь Казани на враждующие группировки» дигән мәкалә басылып чыкты. Мәкаләдә ассызыклап үтелгәнчә, төркемгә төркем сугышу берничә «калай әтәчнең» чәкәләшүе генә түгел. Бу инде — к ү р е н е ш. Казанда берничә елдан бирле яшәп килүче катлаулы к ү р е н е ш.

Без бу хакта элегрәк белә идекме? Белә идек. Мәктәп һәр җыелышта ата-аналарны кисәтә килде: «Иптәшләр,

мәсьәлә бик җитди. Фәлән районда мондый хәл булган, төгән мәктәптә... Берүк балаларыгызга күз-колак булыгыз, озатып куегыз, каршы алыгыз...» Әйе, белә идек. Ләкин тормыш ыгы-зыгысы, көнкүреш мәшәкатьләре белән барысы да онытыла килде. Ә кайбер «калын тиреле» ата-аналар, мәктәп һәрвакыт өркетергә ярата инде ул диеп, моңа кул гына селтәделәр.

Кул селтәүләр турында әле безнең алдарак сүз булыр, ә хәзер кайбер гыйбрәтле саннарга һәм фактларга мөрәҗәгать итик. 1988 елның соңгы ике аенда гына да Казанда үзара бәрелешләр вакытында биш үсмернең гомере өзелде. Заманында мондый сугышларда йодрыклар гына җигелгән булса, хәзер «арсенал» тимер таяклар, кургаш шарлар, шартлаткыч кушылмалар тутырылган баллоннар, пычаклар, утлы корал белән баетылды. Бүгенге көндә Казанда һәркайсы уртача 20—100 кешене берләштергән 80 гә якын төркем бар.

Казанлылар хәтерлиләрдер: 70 нче еллар ахырында бүреләр законы буенча берләшкән төркем — «Тяп-ляп» («Теплоконтроль») котырынып алды. Банданың башлыклары хөкем ителде, шәһәрдә киеренкелек басылды, җәмәгатьчелек тынычланды. «Тяп-ляп» гыйбрәтле сабак иде. Ул гади генә ишегалды компанияләренең дә социаль яктан куркыныч төркемнәргә берләшергә мөмкин булуын, психологик яктан да, әхлакый яктан да өлгереп җитмәгән үсмерләрнең зур-зур группаларга тупланыуына бик сак карарга кирәклекне күрсәтте.

Әле кайчан гына формаль булмаган берләшмәләр һәм аларның хәрәкәте турында сүз чыкканда «Социалистик җәмгыятьтә «хиппилар», «панклар», фәхишәлек, наркомания өчен җирлек юк» дигән җавап төп аргумент буларак кулланыла иде. Без: «Мондый күренешләр егет-кызларыбызның чын омтылышлары белән туры килми, кайбер аңсыз яшьләр генә Көнбатышның азындыручы йогынтысына иярә»,— дип тәкрарлап килдек. Тискәре үзгәрешләргә кул селтәп карау, аларны күрмәмешкә салышуның яшьләр белән эшләгәндә нинди зур зыян салуын бүген берәү дә кире какмый. Хәзер без нәтиҗә белән түгел, ә беренче чиратта аны китереп чыгарган сәбәпләр белән көрәшергә кирәклекне аңлыйбыз.

Ә сәбәпләр нинди соң? Үсмерләрнең вәхшилеккә тиңкыланышлары нәрсә белән аңлатыла? Моңа ничек чик куярга, эшне нәрсәдән башларга? Бу сорауларга җавап эзләгәндә миңа милиция хезмәткәрләре, комсомол работниклары, мәктәп, ПТУ укытучылары, ата-аналар, студент-

лар, психологлар, җинаять эшләгән үсмерләрнең үзләре белән сөйләшергә туры килде. Һәм мин алардан мондыйрак җаваплар ишеттем:

— Без яшьләрнең буш вакытын, файдалы ялын оештыру дип лаф орабыз. Төрле спорт корылмалары, Культура сарайлары салып куябыз. Күңел ачсыннар, ял итсеннәр, янәсе (кайчан арырга өлгергәннәр соң әле?!). Ә боларга алар әйләнеп тә карамыйлар, алар өчен күрше район малайлары белән сугышып йөрү кызыграк, күрәсең.

— Безнең мәктәптә дә бер имгәк үсмер бар. Ул укытучының бөтен тәрбия эшен бер селтәнүдә сызып ташлый, классны боза. Аны кеше рәтенә кертү өчен күпме интеккәнебезне сөйләп кенә аңлату мөмкин түгел. Кайчан җинаять эшләр дә, кайчан утыртып куярлар икән дип көтәбез. Аннан котылу өчен кырыкмаса-кырык инстанция узарга кирәк, ә нәтиҗәсе барыбер булмаячак: тәрбияләгез, сезнең эшегез шул, диячәкләр.

— Көтүгә берләшкән үсмерләр белән инстинктлар идарә итә, аларга рәхимсезлек хас. Көтүдә уйлап тору юк, лидер нәрсә эшләсә, шуны кабатлау гына бар. Бүгенге яшьләрнең кайберләре интеллектуаль үсеш ягыннан 50 нче, 60 нчы еллардагы яшьтәшләреннән калышалар.

— Мин авыру кеше, шуңа күрә үсмерләрне балконнан бик еш күзәтәм. Кайчагында алар иртәдән кичкә кадәр бер урында утыралар. Эшсезлектән әлсерәп бетәләр. Аларның башларына нинди генә уй килмәс?..

— Мәктәптә, ПТУда, коллективта тәрбия процессының нәтиҗәлелеге турында күпме генә сөйләсәк тә, гражданлык позициясенең нигезе өйдә формалаша. Үсмер — беренче чиратта ата-ана тәрбиясе җимеше. Өйдә ул чын тормышның газеталарда язылганча булмавына төшенә. Ата-ананың телевизион тапшырулар вакытында ыргыткан репликалары, эштәге хәлләр, тормыш турында үзара сөйләшүе — болар барысы да аңа акрынлап сеңә бара. Нәтиҗәдә үсмердә тормыш максаты, хезмәт, чын рухи байлыклар турында дөрес булмаган караш тәрбияләнә.

— Минем ПТУда дәресләргә кергәнем бар. 30 кешелек группада 14 кеше генә утыра. Алларында ни дәфтәрләре, ни ручкалары юк. Алар бирегә ял итеп чыгарга гына кергәннәр. Алар укысалар-укымасалар да аттестат алачаклярын беләләр, ялганга өйрәнәләр...

Ишеткәннәрнең барысын бер җепкә тезсәң, мондый нәтиҗә чыга: хәзерге яшь буын эшсезлектән интегә, рәхәтлеккә чыдый алмый, аларны тәрбияләү үзагымына куелган, шунлыктан теләсә ничек узыналар. Проблеманы

болай гади генә аңлатсаң, бу беркатлы караш булыр иде Дөрес, без бүгенге яшьләр эшләп үсә, хезмәтне ярат дип мактана алмыйбыз. Үсмерне оныткан бер келәм кагарга чыгару яки кибеткә ипигә җибәрү, мәктәп шеф лыкка алган колхозның чөгендер басуына чүп утарга куа лау яисә укыту-производство комбинатында кадактан бе ясарга өйрәтү белән генә аңарда хезмәткә мәхәббәт тәр бияләп булмый. Эштән арып кайткан ата-ананың: «Аша дыңмы? Дәресеңне хәзерләдеңме? Тешенне чистарттың мы?» — дигән сораулар белән генә түгәрәкләнгән «тәрбия эше» дә камиллектән ерак тора. Мәктәптән дә әлегә күп нәрсә өмет итеп булмый. Югарыдан төшерелгән планнар заданиеләр, саннар, өлгереш турында отчетлар ташкыны на күмелеп эшләгән укытучылар, билгеле инде, тиешле тәрбияне бирә алмыйлар. Безнеңчә, югарыда ясалган нә тиҗәдә хаклык зур, ул тамырлары бик тирәнгә киткән проблеманың бер тармагын тәшкил итә.

Студент кыз сөйләгәннән:

— Ул көнне без стипендия алган идек. Иптәш кызым да — 100, миндә — 200 сум акча бар иде (шуның 150 се — пальто алырсың дип әни җибәргән акча). Кичәдән кай тышлый безне бер төркем үсмер әйләндереп алды. Чама белән 7—8 класс укучылары, араларында өлкәнрәкләре дә бар. «Я безнең белән бер җиргә барып киләсез, я бер тиенен дә калдырмыйча бөтен акчагызны чыгарып салагыз», — диделәр. Без башта шаярталар дип уйладык, аннан курка калдык. Алар түгәрәк ясап безне бер-берсенә таба этәли башладылар... Акчаларыбызны алгач, көлешеп, арттан төрле мәсхәрәле сүзләр кычкырып калдылар. Без йөгердек...

Тагын бер очрак: ике үсмер егет — Сафиуллин белән Гыйләҗев Үзәк универмаг каршындагы уен автоматлары залына керәләр. Алар янына Сабитов белән Семенов килә һәм «Сез кайдан килдегез?» — дип сорыйлар. Тегеләр «Грязнушка»дан дип җавап бирәләр. Сабитов белән Семенов аларны аулак урында «сөйләшеп алырга» чакыра. Сугыш башлана. Сафиуллин Сабитовка пычак белән кадый. «Ник кададың?» — дигән сорауга Сафиуллин: «Мин аны үтермәсәм, ул мине үтерә иде», — дип җавап бирә.

7 класс укучысы М. Ивановны, өенә кайтып барганда, бер төркем яшүсмер чолгап ала. Төркем башлыгы ПТУ укучысы Ю. Космылин аннан: «Син кайда яшисең?» — дип сорый. Малай җавап бирергә дә өлгерми, аның башына ике тапкыр тимер таяк белән суга, ә төркем җиргә егылган үсмерне типкәли башлый...

Менә без Космылин белән кара-каршы утырабыз.

— Юра, сезгә бернинди зыяны тимәгән һәм гомумән бернинди төркемгә дә карамаган мәктәп укучысына тимер таяк белән сукканда син кеше үтерәм дип уйладыңмы?

— Нәрсә уйлаганмындыр, хәзер инде хәтерләмим.

— Төркемнәргә берләшү, кемнәр беләндер сугышу, нәрсәдер бүлешү нигә кирәк?

— ...

— Төркем сиңа нәрсә бирә?

— Дуслар белән бергә буласың, табигатькә чыгасың...

— Синеңчә, кешенең чын дуслары ничәү булырга мөмкин? Берме, икеме, унмы?

— ...

— Син матур киләчәгеңне үз кулларың белән сызып ташладың, күпме кешене гомерлек кайгыга салдың. Күңелеңдә үкенү хисе бармы, киләчәк язмышың турында нәрсә уйлыйсың?

— Уйлап ни файда? Хәзер барыбер берни дә үзгәрмәячәк.

Күпме генә тырышсам да, мин Космылинның күңелен «кузгата» алмадым. Аның күзләрендә бернинди гамь әсәре юк, ә бары тик төпсез бушлык, салкын битарафлык кына иде.

Үсмерләрдә кансызлык, каты бәгырьлелек, миһербансызлык каян килә? Бу сорауга иң киң таралган җавапларның берсе мондый: иркәләп бозып бетердек, шуңа күрә тыңламыйлар, санга сукмыйлар. Шушы «иркә» балалар белән психологлар кызыксына башлагач, һич көтелмәгән нәрсә ачыклана. Баксаң, әхлакый «умырткасы» булмаган, рухи яктан гарипләнгән үсмернең формалашуына ата-ана мәхәббәте җитенкерәмәү зур йогынты ясый икән. Белгечләр раславынча, авыр үсмерләр — ата-ана назыннан мәхрүм, ата-ана мәхәббәтенә мохтаҗ үсмерләр. Баланы ярату — аның өстен-башын карау, тәмле ашату, яхшы мәктәпкә урнаштыру гына түгел. Балага йөрәк җылысы кирәк, ул үзен кеше дип санауларын тели. Әгәр бу ихтыяҗ канәгатьләндерелмәсә, үсмердәге хис-кичерешләр ташкыны икенче эздән китә, аның кыйбласы үзгәрә.

Әгәр без үзебезне бала урынына куеп карасак, аның кечкенә йөрәгенең нинди зур фаҗигаләр кичерүен аңлар идек. Менә сабыйны беренче тапкыр балалар бакчасына китерәләр. Аның өчен ят дөнья, чит кешеләр. Ул елый, әнисенә кулларын суза. Һәм еш кына ана кеше, кызып китеп, аның арт ягына шапылдата. Бу рәхимсезлек түгелмени? Мәктәптә булсын, өйдә, булсын, балага юк кына

нәрсә өчен кычкыру, аны робот кебек, нәрсә кушсалар, шуны эшләргә мәҗбүр итү, ихтыярын сындырырга омтылу — бу кырыслык түгелмени?

Кешелекнең язмышы тулысы белән үсеп килүче буынның нинди тәрбия алуына бәйле. Кешеләр — мохит һәм тәрбия җимешләре. Әгәр без яшьләр үзгәрде дип әйтәбез икән, димәк, мохит, тәрбия үзгәргән. Ни чәчсәң, шуны урырсың, диләр. Бүген без чәчкәннәребезне урабыз. Балаларыбызны беркем дә читтән килеп бозмады, барысына да үзебез гаепле, «авыр» яшьләрне без үзебез үстердек. Торгынлык чорында киң тамыр җибәргән законсызлык, намуссызлык, ялагайлык, карьерачылык тәэсирендә әхлакның деформацияләнүе, бер төрле уйлаган, икенче төрле сөйләгән, өченче төрле эшләгән заманнарда формалашкан психология, әле һаман да хәл ителмәгән күп кенә социаль проблемалар, формальлеккә корылган тәрбия системасы, рухи дөньябызның саегуы, идеаллар булмау — болар барысы да бүгенге яшь буында чагылыш тапмый кала алмый. «Тулаем алганда, яшьләребез әйбәт безнең...» — дип, үзебезне әледән-әле юатып торсак та, бүген яшьләребез тормышына эчкечелек, наркомания, рухи ярлылык, миһербансызлык, тупас көчкә табыну, намуслы хезмәткә түбәнсетеп карау, икейөзлелек кебек тискәре сыйфатларның үтеп керүен танырга үзебездә көч табыйк.

Исмәгыйль Шәрәфиев

КАЯ СОҢ СЕЗ, ДЖЕНТЛЬМЕННАР?!

Джентльмен сүзе безгә инглизләрдән кергән, ул «әдәпле, инсафлы кеше, ягъни буржуаз моральне төгәл үтәүче» — дип бирелә сүзлектә, һәм анда ул хатын-кызга яки ир кешегә карата аерып та әйтелмәгән. Шулай да без джентльмен сүзен ирләргә — чын ир-егетләргә — карата кулланабыз.

Тик менә, кызганычка каршы, бу исемгә лаек ирләребез генә һаман саен сирәгәя бара. Әле без бәләкәй чакларда гына да алар күбрәк кебек иде. Үзебез белән укый торган малайлар мәктәптән кайтканда кулларыбыздан букчаларыбызны тартып алып әйе, «тартып алып», чөнки алар матур итеп сорый белми — авыл баласы бит. Сорый белсәләр дә без бирмәскә тырышабыз, чөнки олыларның: егетләр белән йөри башлаган, дип әйтүләреннән

оялабыз), күтәреп кайткан булалар иде. Өлкәнрәк кешенең авыррак эш эшләгәнен күрсәләр, йөгереп барып булышалар иде. Әти, абыйлар да шулай: күрше карчыгының җил аударган капкасын урнаштырып бирүне, тузган читәнен яңартуны бернигә дә санамыйлар иде. Әле үзләренең кемгәдер файда китерә алуларына үзләре үк сөенәләр дә иде сыман. Гомумән, олы кеше каршында исерек килеш күренеп йөрүдән дә оялалар иде бугай әле ул чакларда. (Балачакта илтифатсыз гына тоелсак та хәзер миңа ул еллардагы әллә никадәр вакыйгалар бәйнә-бәйнә күз алдына килә.) Ә бит бөтен авылга бер укымышлы кеше юк, бар да чабаталы авыл мужигы, хәтта авыл Советы һәм колхоз председательләре дә 7 класс белемле генә иде. Каян килгән аларга, алар тәрбияли торган малайларга шундый әдәплелек, ярдәмчеллек. Нигә без бүген ирләрдәге шул сыйфатлар турында «иде» дип кенә сөйлибез.

Мин үзем хәзер шәһәрдә яшим. Һәм Казандагы ирләрнең тәрбиясезлегенә, әдәпсез-культурасызлыгына гаҗәпләнеп бетә алмыйм, алар монда гына шулайдыр, ә авыл ирләре элеккечә үк әйбәтләрдер кебек тоела. Юк шул, авылда да джентльменнар бетеп бара. Нәрсә сәбәп булды аңа — аракымы?..

Балалары авылны ташлап киткән ялгыз карчыкның коймасы ауган — аны утырттырырга аракы эзли ул. Уллары кайтмый да, кайтса да аны төзәтеп тормый. Ә авыл ирләре акчага риза түгел. (Хәер, ул карчыкның үз улы да читтә шулай эшли.)

Ял-бәйрәм көннәрендә авыл араларындагы баткак юллардан балалар, аналар (һәм бу очракта аталар да) үзенең талонга тигән шикәрен, аракысын, сабынын һәм базардан ике бәягә сатып алган чәен күтәреп әти-әнисе, әбибабасы янына кайталар (һәм китәләр), ә колхоз председателе, район хуҗалары (хатын-кыз түгел шул алар) алар яныннан уазикта выжлап узып китәләр. Утыртмыйлар, янәсе колхозда (районда) эшләмисез әле. Ә үз улкызларын (авылда, районда эшләмәсәләр дә!) дистәләгән генә түгел, йөзләгән чакрымнарга да колхоз, учреждение машинасы белән озаттыралар.

Хәер, соңгы вакытта, ягъни илдә барган демократия рухына авыл кешеләре дә кушыла башлагач, авыл, район хуҗалары район, шәһәр якларына автобуслар йөртү чарасын күрә башладылар. Монда тагын бер могҗиза ачылды. Ул килеп туктауга, этәсен этеп, төртәсен төртеп, автобуска иң беренче ир-ат бәреп керә. Әлбәттә, урын да

аңа эләгә, һәм сәгатьләр буе янында басып барган хатын-кызга исе дә китми, рәхәтләнеп җәелеп утырып бара ул...

Шәһәрдә дә нәкъ шулай. Трамвай, троллейбуска утырганда игътибар итегез әле бер генә. Аерым игътибар итмәсәк без аны сизмибез дә, чөнки аңа күнеккәнбез инде.

Аннан соң ир-атларыбыздагы тагын бер ямьсез сыйфатка кыскача гына тукталасым килә. Җиргә, тротуарга какыру-төкерү, борын сеңгерү аларга берни тормый. Бүгенге чүпрәк заманында кулъяулыгы йөртеп булмый микән ни соң? Беренчедән — җирәнгеч, икенчедән — кемдә нинди авыру булмас...

Сүгенү турында әйтеп тә торасы юк инде. Монысы иң әшәке, иң йогышлы авыруга әйләнде. Тик аның «профилактикасы» турында гына әлегә уйлаучы юк.

Әлбәттә, ирләребезнең болай елдан-ел түбәнлеккә төшә баруында аракының тәэсире көчле булды. Эшләп арыгач та эчтеләр алар, диплом алгач та эчтеләр, хәтта күлмәк яки ыштан алгач та «юабыз» дип эчтеләр... Югарырак постка куелгач та, җыелыш-семинарлар булып узгач та, хәтта съездлар үткәч тә эчтеләр... Бәби туса, аның тәпиен юдылар, эти-әниләрен күмсәләр, кайгыларын кудылар...

Шулай итеп әкренләп бөтен белемнәрен, көчләрен, хисләрен, намусларын... юып бетереп киләләр. Ә бит әле дә булса гаилә дә, хуҗалык та, ил дә шул аракы коллары кулында. Ярый ла авыл мужигының эчеп кайтып хатынын, балаларын туздырганын бөтен авыл белә. Ә бит председательнең, райком секретареның, мәктәп директорының, предприятие хуҗасының һ. б., һ. б. шундый бик күп җитәкчеләрнең гаиләләре күргән газапны белүче генә юк. Чөнки кешегә чыгарырга ярамый, ирләренең авторитетына зыян килә. Шуңа күрә без бүген шәһәрдә дә, авылда да иң гади катлау ирләр генә эчә дип уйлыйбыз. Кызганычка каршы, алар гына түгел шул, безнең җәмгыятебезнең кеше турында — аның культурасы, белеме, эше, киләчәге турында кайгыртучы, аның тормышы, көнкүреше белән идарә итүче иң җаваплы җитәкчеләр, белгечләр дә эчә.

Бүген бу сүзне авыз тутырып ук әйтергә җайсызрак та кебек, чөнки моннан 4—5 еллар электәгечә үк эчүләр тыелды, әмма ул чордагы эчкечеләрнең зур күпчелеге әле дә булса үз постларында утыра бирәләр. Шулай булгач аларның саф акыл белән җитәкчелек итәргә сәләтле булулары күңелне шикләндерә. (Ни өчен соң әле авыл мужигы аракы сатуны тыйганнан гына эчүен ташламады

да, җитәкче кеше ташлый алырга тиеш — логикага сыешмый!)

Эчүчелек ирләрне гомосексуализмга китерде. (Аек акыл белән кайсы ир, кайсы егет аңа барыр иде икән!) Әхлакый яктан тотнаксызландырды.

Барыгыз да хәтерлисездер: моннан ике ел элек Бразилиядә эшләнгән Изаура турындагы фильмны караган идек. Безнең күзе төшкән (күңеле төшкәнне котеп тә тормыйча) хатын-кыз күргән саен мәхәббәт сатарга күнегеп беткән ирләребез өчен Леонтийның үз-үзен тотышы бигрәк гаҗәп булды инде. Үз колың белән үзең теләгәнчә эшли алма әле янәсе, «булмаганны», «әкият» диделәр алар. Әйе, Леонтий фильмда иң мәкерле, иң тискәре тип итеп бирелгән. Әмма ул бит безнең ирләребез заманы, алар җәмгыяте кешесе түгел. Ул колбиләүчелек заманы кешесе, әмма һәр җәмгыятьнең, һәр чорның үз таләпләре, үз кануннары булган. Леонтий исә, нинди генә явыз булмасын, җәмгыять алдында, һич югында әти-әнисе каршында җаваплылык кичерә. Әгәр ул Изауранны мәсхәрәләсә, ә тегесе хурлыктан үз-үзенә кул салса — Леонтийга җавап тотарга туры киләчәк бит. Ә бүген, бездә андый хәлләргә күлеп кенә карыйлар. «Татарстан яшьләре» газетасында эшләгәндә колхоз председательләренең терлекче хатын-кызларны хур итеп, гаиләләрен бозулары турында дистәләгән хатлар килә иде, тик урынга тикшерергә җибәргәч, шик аларның берсенә, тикшерелеп, чара күрелү турында җавап алынсын. Гомумән, өлкән генә ир врачларның авыруларга, ир укытучыларның укучыларга һ. б., һ. б. бәйләнү очраклары азмы әллә. Шулай булгач, яшьләрнең бүгенге бозыклыгына һич гаҗәпләнерлек урын юк.

Минем карашка, ирләребездә тагын бер җитди кимчелек бар. Ул да булса аларның хатын-кыз белән булышып, тартышып, телләшеп яшәве. Менә күптән түгел генә төрле дәрәҗәдәге властьларга депутатлар сайладык. Алар арасында хатын-кызларыбыз күпме соң? Авыл, район Советларыннан кала (боларга депутатлык пособиесе түләнми, льготалары да шул территория чикләрендә генә) югарырак Советларга гел ирләр омтылды (гәрчә алар кулында депутат вазифаларын болай да үтәргә тиешле власть булса да). Чөнки алар бик мөһим эшем кешеседәй өйләреннән, төп хезмәт вазифасыннан аерылып, җыелыш-кинәшмәләргә китүне, үз фикердәшләре белән гостиницаларда, рестораннарда очрашып төксе, тозсыз анекдотлар сөйләшүне, аннан зур җыелышларда ярым йоклап яки хатын-кызлар тормышын җиңеләйтү турында мәңге тормышка

ашмас планнар корып утыруны бик зур, бик авыр хезм
дип саныйлар. Һәм менә шушы «авыр хезмәт»не хаты
кыз кулына бирмәс өчен ни генә эшләмиләр. Үзләрен
альтернативалары арасына эләккән хатын-кызларны ал
таптап үтәргә әзерләр. Әлбәттә, элек тә әз булса да үт
ләр иде хатын-кызларыбыз депутатлыкка (процент өчен
тик алар Фәүзия Бәйрәмова кебек кыю фикерле булган
өчен түгел, ә нинди шартларга да риза булып, дәшм
тынмый башын иеп, ат кебек эшләгәне өчен, яки — әл
серме — эше күренерлек булмаса, үзе күренерлек булган
өчен үтәләр иде.

Һәрхәлдә хатын-кызлар мәнфәгатьләрен яклап күр
шер өчен түгел иде инде. Бу уңайдан язучы Фәүзия Бә
рәмовага карата берничә ирнең сүзләрен ачыктан-ачы
язып үтәсем килә. Тыштан караганда могтәбәр генә б
лып күренгән ул әфәнделәр «теге хатын үткән бит тәк
хәленнән килмәгән җиргә ник үрелергә кирәк. Халык өч
нәрсә эшли ала инде ул, безнең халык сарык бит ул, ш
ны да аңламый... һ. б., һ. б.», дип тезеп китәләр. Әлбәтт
халык өчен Нигъмәтуллин (Саба районы партия комит
тының ул чактагы беренче секретаре, Бәйрәмова бел
депутатлыкка альтернатив кандидат) депутат булмаса д
эшләргә тиеш, шуның өчен бер тапкыр коммунистлар т
рафыннан сайланып куелган бит инде ул. Безнең халы
депутатлары арасында капка төбендә шоферы белән м
шина басып тора торган җитәкчеләр генә булса, Фәүзи
кебек сөткә дә, юл билетына да, көндәлек транспортка
сәгатьләр буе чират торып яшәүчеләр, көннәр буе авы
ис аңкып торган абзарларда, фабрикаларда эшләүче х
тын-кызларыбыз хәлен кем аңлар да, аннан котылуны ке
хәл итәр соң?

Әйе, Фәүзия Бәйрәмова бүген экономик яктан һә
хуҗалык итү мәсьәләләрендә райком секретаре дәрәҗ
сендә үк фикер йөртә алмаска да мөмкин. Чөнки әле у
тәҗрибәсез, ай саен 7—8 көн социаль-политик мәсьәлә
«хәл итеп» киңәшмәләрдә дә утырмаган... Әмма ул ишл
ярлы гаиләдә туып-үскән. Җәмгыятебездәге гаделсезле
нең ачысын татып яши. Шуңа күрә үз хуҗалары каршы
да тәлинкә тотып, үзеннән түбәннәр каршында йодры
законы файдаланып, авыл, район, республика белән ид
рә итүче ирләргә һич кенә дә тынгылык бирми һәм би
мәячәк тә. Моңарчы эшкуар булып кыланып илебез
бүгенге кризис хәленә китергән ир-хуҗаларның бернич
сен генә булса да айнытырга, күктә очып йөргән хәлл
реннән халык арасына төшеп атларга мәҗбүр итәчәк.

Фәүзия белән җитәкчеләр, аппаратчылар гына түгел, ıаманга яраклашкан әсәрләр иҗат итеп, шыпырт кына, җайлы гына яшәп ятучы ир язучылар да көрәшә. Алар безнең яраткан язучыларыбыз Нәбирә Гыйматдиновага ца, Мәдинә Маликовага да (гәрчә болары безнең ир-атларыбыз белән власть бүлешергә омтылмасалар да) үзләренең төксе репликаларын аталар. Ә бит безнең бу язуıы хатын-кызларыбызның һәркайсы бала үстерәләр, гаилә тоталар, күпме җәмәгать эшләре алып баралар.

Каян килә безнең ирләргә бер карасаң бу хәтле властька, тормышның түренә омтылу, икенче карасаң шушы кадәр түбәнлек? Җыелышларга игътибар итегез әле, залца күпчелек ирләр, ә президиумда гел ирләр, анда очраклы гына булса да берәр хатын-кыз эләгә икән, аның урыны арттагы рәттә булыр, безнең «культуралы» ирләребезнең ник берсе аны алга чакырсын, юк инде, күкрәк киереп алда утырырга алар үзләре күнеккәннәр. Моңа ıракы гына да сәбәпче микән соң? Чөнки эчүчелеккә бирелү үзе дә ир-атларыбызның әдәпсезлегенең бер күренеше бит.

Әллә соң бу безнең халык арасында югары идеяләр, күркәм әхлаклылык сыйфатлары таратырга тиешле интеллигентлар хәзерләүче югары уку йортлары программаларының тарлыгыннанмы? Аларның берсендә дә бүгенге кешелек этикасы өйрәнелми. Шулай ук интеллигентлар интеллигенты булырга тиешле вуз преподавательләренең күбесенең культура-әдәплелек дәрәҗәсе бик түбән. Алар арасында студентлар белән рюмка чәкештереп утырып, зачет куючылар да, лекцияләр өчен бирелгән сәгатьләрнең яртысын дөнья гайбәте сөйләп уздыручылар да бар.

Инде, авыр булса да, бүгенге буын ир халкының илтифатсызлыгын, тәрбиясезлеген күрсәтә торган тагын бер сыйфатка тукталыр идем.

Ватан азатлыгы өчен көрәшүчеләргә, Әфганстанда интернациональ бурыч үтәүчеләргә карата минем хөрмәтем бик зур. Тик мин аларны көндәлек тормышта да шундый ук кыю, кешелекле бүгенге малайларга, егетләргә чын үрнәк итеп күрәсем килә. Югыйсә кайчакта аларның үзүзен тотышларыннан балалар, яшьләр алдында безгә, апаларга, оялырга туры килә. Әйтик, магазинда сөткә 8–10 кеше чират тора. Алар арасында җил иссә дә егылып китеп җан бирергә торган әбиләр дә була. Шунда чип-таза, йөзенә чиертсәң чәчрәп каны чыгарга торган мәһабәт кенә өлкән ир-ат килә дә книжкасын күрсәтеп, сөт алып китә. Сүз дә юк, алар үзләренә бирелгән льготалар-

дан файдаланырга тиешләр. Әмма 5—10 минутлык чи ратта, дефицит булмаган товар өчен торганда алар эн шул ирләре, уллары сугышта үлеп калган, я булмаса го мерләре буена ирләр белән бер сафта хезмәт итеп тәмам саулыкларын югалтып картайган әбиләрне хөрмәт итәрг тиешләрдер бит инде. Әлбәттә, сугыш ветераннарыны барысын да әрсез-сансыз дип булмый. Алар арасында го мере буена да хәрби билетларын файдаланмаучылар д күп.

Ирләр мине гафу итсеннәр, безне барыбызны да бе үлчәүгә салган димәсеннәр. Араларында джентльмен исе менә лаек чын ир-егетләр дә күп, әлбәттә. Тик менә ала үз затларына тап төшерүче замандашларына йогынт ясаудан ерак торалар.

Хатын-кыз бит, мескен, тормыш йөге күпме генә авы булмасын, бер-берсен тәрбияләргә дә омтылган була. Әй тик, хатын-кызлар советы эчкечелеккә бирелгән, балала рын тәрбияләүдән баш тарткан, я булмаса (тагын шу ук балык башы) исерек иреннән аерылырга теләгән, гаи ләле ир белән чуалган кайбер аналар, хатыннар, кызла белән тәрбия эшләре алып бара (югарыда санап үтелгә сыйфатларга ия булган ирләр җәмгыятендә яшәгәч — ха тын-кызларыбызның бозылуы да һич гаҗәп түгел). Шу лай булгач, нигә ирләр советы да оештырмаска, һәм без нең инфантиль (йомшак итеп шулай атыйк инде) ирләре безне тәртипкә, әдәплелеккә, намуска чакырмаска.

Без, хатын-кызлар, тормыш йөгенә үзебез җигеләбез властька үреләбез, ялгызлыкка омтылабыз икән — бола бит чарасыздан ясалган адымнар. Әгәр ирләребез эче кайтмаса, вакланып тиеннәре өчен бездән отчет таләп итмәсә, эштә ярты көннәрен тәмәке төтене астында гай бәт сатып уздырмаса (гомуми норма үтәү тагын хатын кыз җилкәсенә төшә), әгәр эштә дә, тормышта да безне чын таянычыбыз булсалар, без кыска эш көне белән эш ләп (яки бөтенләй өйдә генә торып), балалар тәрбияләп кенә утырыр идек тә бит...

Нишлисең, әлегә болар хыялыбыз гына шул безнең.

Язилә Абдулкадыйров

АК ҮЛЕМ—КАРА ЯЗМЫШ

Бу бәла Европа илләренә, Америкага күптән килгән иде инде.

Дөнья матбугаты туктаусыз язып торды: миллионлаган кешеләр үз теләкләре белән «ак үлем» корбаннары булганнар, наркоманнарга әйләнгәннәр... Безнең халык өчен әле бу ят сүз, ят нәрсә. Әмма... наркоманнарның эше белән танышканда якташларыбыз фамилияләре дә еш очрый. Татар авыллары, районнарында, шәһәрләрендә наркомания нокталары табылып тора. Киң халык массалары өчен ят, билгесез күренеш булса да, бу куркыныч чирнең тамырлары инде Идел буйларына да үтеп кергәнлектән, бүген инде бу турыда ачыктан-ачык язарга кирәк.

Шулай итеп, кем ул наркоман? Җәмәгатьчелек һәм кешелек өчен нәрсәсе белән куркыныч ул? Һәм яшьләр ничек наркомания юлына басалар?

Менә алар минем каршымда утыралар, наркомания белән шөгыльләнеп, биш елдан ун елга кадәр иреккләреннән мәхрүм ителгән ир-егетләр. Хәер, бирелә ир-егетләр сүзе бик үк барамы икән? Берничә минутлык «ләззәт» өчен үзләре теләп акылларыннан шашкан, тормыштан, гаиләдән, мәхәббәттән, хезмәттән ваз кичкән бәндәләр алар. Күз карашлары томанлы, аларда бернинди тормыш, җан юк. Хәрәкәтләре салмак, әйтерсең гәүдәләрен җыеп ала алмыйлар. Йөзләрендә — битарафлык: шатлык та, кайгы да юк. Баштанаяк карадан киенгән бу «тере мәетләр» бер-берсе яныннан шәүлә кебек кенә үтеп йөриләр, әйтерсең барысы да ниндидер бер куркыныч төштә яшиләр. Ләкин бу төш түгел — тормыш. Һәм бу шәүлә кебек йөргән кешеләрнең дә кайдадыр ата-аналары, якыннары калган, кайсыларының балалары, хатыннары бар... Ләкин болар барысы да үткәндә калган. Наркомания белән шөгыльләнә башлаган кешенең киләчәге караңгы. Дөнья тарихында моңа мисаллар күп. Дөрес, наркоманнарны бирелә дәвалап карыйлар, тәрбия эше дә алып баралар. Ләкин, Кавказ якларыннан китерелгән бер наркоманның әйтүенчә: «Барысын да эшлиләр — веналарны да чистарталар, канны да алмаштыралар, ләкин теләкне генә үтерә алмыйлар». Димәк, иреккә чыккач та болар үз эшләрен дәвам итәчәкләр — үз-үзләренә укол кадап, гашиш-анаша тартып, тагы «ак үлемгә» барачаклар, дөньядан ваз кичеп, башкаларны да шул юлга тартачаклар. Шуңа күрә наркомания җәмгыять өчен икеләтә куркыныч, яшьләрне

аның агуыннан саклап калу өчен бүгеннән үк аңа каршы зур эш башлап җибәрергә кирәк. Шушы максаттан мин яшьләргә, шул ул вакытта аларның ата-аналарына да берничә кешенең наркомания юлына ничек аяк басуын сөйләп бирмәкче булам.

Ирек авыр гаиләдә туып-үсә. Атасы алкоголик була, эчеп-исереп өйдә гел тавыш чыгара. Эчкән баштан бер яшьлек улы Ирекне бик нык куркыта, соңыннан бала тотлыга торган булып кала. Малайга җиде яшь чагында ата-ана аерыла, ана ике ир бала белән ялгыз кала.

Малай аз аралашучан, авыр холыклы булып үсә. ГПТУда укыганда үзенә «дуслар» таба. Үсмерләр бакчалардан мәк җыеп сыекча кайнатып, аны кан тамырларына җибәрәләр. Берникадәр вакытка бөтен дөньядан ваз кичеп торалар. Үсмерләрдән уку, тормыш уе кача. Аларның организмнары инде шул уколларсыз яши алмас хәлгә килә.

Кул астында үзләре хәзерләгән наркотиклар беткәч, үсмерләр урлашу юлына басалар. 15 килограмм мәк урлап чыкканда тотылалар. Ирек тә өч елга ирегеннән мәхрүм ителә.

— Әниеңнең килгәне бармы? — дип сорыйм мин аннан.

Егетнең башы аска иелә, ләкин йөзе үзгәрми. Кайгырамы, борчыламы, белеп булмый. Тавышы әкрен, сүзләрен сузып кына сөйли.

— Әни авыру. Больницадан кайтып керми. Кая монда килсен...

— Әниең синең ни белән шөгыльләнгәнеңне белдеме?

— Каян белсен... Ул әле хәзер дә аның нәрсә икәнен белми...

Күп ата-аналар наркоманиянең нәрсә икәнен белмиләр. Балаларындагы үзгәрешне, аларның нәрсәгә тартылганнарын да сизмиләр. Югыйсә бу үсмерләрнең күбесе мәк белән өйдә кайнашалар бит. Иң мөһиме башлатмаска. Бер башлагач организмның котырган омтылышларын туктата алырлык берниндп көч юк. Кызыксынып кына, шаярып кына башланган «мәк чире» кешене мәңгегә тормыштан аера, «ак үлем» аларның кара язмышына әверелә. Үзенә дару агуын юнәтү өчен, наркоман берни каршында да туктап калмый. Урлашудан кеше үтерүгә хәтле барып җитәргә мөмкин.

Юл читләрендә үсеп утырган кыргый киндер үсентесен күргәнегез бардыр. Кешелекне гомер буе киендергән, туен-

ырган киндер дә бүгенгесе көндә наркоманнар «азыгына» әйләнде. Байкал буйларында, Кыргызстан далаларында үскән кыргый киндер бүген күпләрне «ак үлем» упкынына ташлады. Аннан кеше организмына, баш миенә, психикасына коточкыч көчле тәэсир итә торган тәмәке — гашиш-анаша ясыйлар. Ә ул безнең якларга әзер килеш ничек килеп эләгә соң? Аны күпләп, теләгән саен тарту өчен юл буенда үскән киндер генә җитми бит.

Гашишның безнең якларга килеп эләгүенә типик бер мисал. Соңгы елларда кинәт кенә Азнакай эшчеләр поселогында гашиш тартучылар, ягъни наркоманнар барлыгы ачыла башлады. Гашиш тартучылардан сорау ала башлагач, аларга бу «котырган тәмәкене» шушы поселок кешесе сатканлыгы беленде. Ә ул аны кайдан алган? Баксаң, Кыргызстаннан алып кайткан икән ул аны.

Кайвакытта шундый фикер дә килергә мөмкин: чит кешегә зыяны юк икән, тартсыннар, тилерсеннәр, зыяны үзләренә бит дип тә әйтергә мөмкиннәр. Бу кешеләр үзләре юкка чыгып җәмгыятькә бер зыян китерсәләр, тәэсирләре, корбаннары белән мең зыян салалар. Организм сораганда кул асларында наркотиклар булмаса, алар талау, үтерү юлына да басалар. Менә Краснодардан Бабуцкий эше. Ул төзелештә эшли, наркомания белән шөгыльләнә. 1985 елның 13 июлендә кичен гашиш эзләп чыгып китә. Үзе белән балигъ булмаган үсмерне дә ала. Алар үзләренең танышларына килеп керәләр. Ир өйдә булмый, хатыныннан гашиш таптыра башлыйлар (аның ире дә гашиш тарта торган була). Тапмагач, хатынны бик нык кыйныйлар, ваннага ябып, салкын су астында мыскыл итәләр, җәзалыйлар. Иртә белән генә өйдән чыгып китәләр...

Наркотик таба алмагач, кеше ярсудан ерткычка әйләнә. Дусты өенә кереп явызлык, оятсызлык кылып чыгып китә. Акылы томалана, каны агулана (Бабуцкий 10 елга ирегеннән мәхрүм ителгән).

Ә аның якташы Рева наркомания аркасында кеше үтерүгә хәтле барып җитә. Бу җинаятьче-наркоманнар группасына 14 кеше керә. Наркотиклар табу өчен бу группа талау, юлбасарлык белән шөгыльләнә. Дистәләгән квартирага, складларга керәләр. Иннектән башлап келәм, алтын әйберләргә хәтле урлап чыгалар. Наркотиклар бик кыйммәт тора, ә наркоманнарның күбесе бер җирдә дә эшләми. Һәр минутлык ләззәткә чуму өчен кеше каны коела...

Соңгы вакытта бу төр наркоманнар аеруча күбәеп киткән. Алар арткан саен, аптекаларда дарулар кими. Йокы дарулары юк, иң каты сызлануларны да баса торган морфин юк. Авырулар газаплана, ә бу дарулар наркоманнар канына күчә. Алар юләрләнә, дөньяларын оныта, хыял, ләззәт диңгезендә йөзә, ә кемдер бер тамчы, бер төймә дару булмаганнан сызланып тилмерә. Нәрсә, шуннан соң наркоманнарны, үзләре исбатлаганча, кешеләр өчен зарарсыз дип әйтикме? Ләкин фактлар бөтенләй башканы сөйли... Менә Лениногорскидан Леонтьев эше. Милләте буенча чуваш, ике баласы бар, наркоман. Бу группага 11 кеше кергән. Леонтьев та юлын мәк урлаудан башлый. Ләкин мәкнең калтырата, агулый торган гадәте бар икән һәм Леонтьев та агуланып больницада ятып чыга. Терелтәләр, бушлай дәвалап чыгаралар. Леонтьев мәк белән маташуын ташлый, ләкин... даруга күчә. Лениногорск үзәк район больницасы поликлинкасының онкология кабинетында медсестра булып эшләүче Михайлова белән элемтәгә керә. Һәм поликлиникадан рецепт ташу башлана. Инде рецепт белән генә алган дарулар җитми башлагач, Михайлова аның өчен даруларны урлый башлый. Көчле авыруларга сызлауны басарга ярдәм итә торган даруларны урлый. Леонтьев — наркоман, ул үзенә «тиешен» алу өчен теләсә нинди җинаятькә барган. Ә медицина хезмәткәрләрен бу юлга нәрсә этәргән соң? Акча. Җиңел генә акча эшләү юлы. Әйтик, 10 ампула дару өчен Леонтьев бервакыт Михайловага дефицит күз буявы һәм 6 сумлык ирен буявы биргән. Шәфкать туташы шушы чүп-чар өчен авыруларның авызыннан соңгы өметләрен — соңгы даруларын тартып алган.

Леонтьев 7 елга, медсестра Михайлова һәм Еремина шартлы рәвештә 3 елга ирегеннән мәхрүм ителә.

Наркоманнар арасында медицина хезмәткәрләре шактый. Үзләре сәламәтлек сагында торырга тиешле кешеләр ничек шушы чиркангыч юлга басканнар соң? Ленинградтан китерелгән наркоман-хирург белән сөйләшәбез. Аның фәлсәфәсе гаҗәеп сәер, ул үзен һич кенә дә җинаятьчегә санамый. Канына наркотиклар җибәрүне «арыганлыкны бетерү өчен кирәк иде», дип исбатлый.

Наркотиклар кабул иткәч, организмның нинди халәткә килүен сөйләтәм.

— Бу дөньядан китәсең,— ди ул ашыкмый гына.— Берни кирәкми. Гади нәрсәләр дә илаһи, матур булып күренә.

— Ә шул вакытта операция өстәлендә авыруыгыз үлеп

ятса? Сез бит эш вакытында да наркотиклар кабул иткәнсез?

— Кеше үлү очрагы булмады.

Аның белән бәхәсләшүдән мәгънә юк. Ул, татлы елмаеп, барыбер үзенекен сөйли.

— Моннан чыккач та врач булып эшләргә уйлыйсызмы? — дим.

— Әлбәттә,— ди ул.

— Наркоманияне дә ташлый алмыйсыз инде?

— Ә ул миңа зыян итми, киресенчә...

Мондый врачка операциягә керергә язмасын...

Пикуль дә хирург. Ул хөкем ителгән наркоманнар янында эшләгән һәм үзе дә наркоманга әйләнгән. Авыруларга дигән көчле даруларны әкрен генә үзенә җибәреп яткан. Һәм нәтиҗәсе — 7 елга хөкем ителгән, үзе хәзер наркоманнар белән утыра.

Үзебезнең якташ, татар врачы Баһаветдинов турында да дәшми калып булмый. Дөрес, ул инде җәза срогын вакытыннан элек утырып, иреккә чыккан. Ләкин аның «дело»сында наркомания белән бәйләнешле һәр кылган эше акка кара белән теркәлеп калган, намусындагы кара җөй кебек...

Баһаветдиновка хезмәт хакы гына җитми, күрәсең, ул законсыз рецептлар язу белән дә шөгыльләнә башлый. Бу рецептлар буенча Тюменов, Исмәгыйлев, Храмов аптекалардан көчле тәэсир итә торган бик күп дарулар алалар. Ә соңрак Баһаветдинов даруларны урлый башлый. Аларны бакчада агач астына яшерә, соңыннан башкаларга бирә. Баһаветдинов РСФСР Җинаятьләр кодексының тиешле статьялары буенча хөкем ителә.

Наркоманнар арасында төрле һөнәр кешеләре бар — врачлар, электриклар, музыкантлар, шоферлар, рәссамнар, фельдшерлар, штурманнар, элемтәчеләр, сәүдә хезмәткәрләре, пешекчеләр, ташчылар һ. б. Бер җирдә эшләмәүчеләр дә күп. Алары күбрәк. Ләкин аларның барысының да фәлсәфәсе бертөсле: «Без кешеләргә зыян китермибез. Безгә рәхәт. Безгә тимәсеннәр, без дә тимәбез».

Югарыдагы мисаллардан наркоманнарның кешеләр өчен, җәмгыять өчен зыянлымы-түгелме икәнен аңлавы кыен түгел.

Ләкин наркоманнардан килгән тагын бер хәсрәт бар әле. Аны бернинди «дело»ларга да теркәп булмый, бернинди үлчәүләргә дә сыймый ул хәсрәт... Баласын «ак үлем» тартып алган ана хәсрәте ул. Мин ул аналарны үз күзләрем белән күрдем! Кешеләрнең күзенә туры

карарга да кыенсына алар. Балаларын тик бер күрер өчен меңәр чакрым юл үтеп, тилмереп, көзге пычракта таш койма буенда басып торалар. Чәчләре вакытсыз агарган, йөзләренә сары иңгән. Таш койманың теге ягында — аның улы. Ул анасын күрә дә, күрми дә. Карашы — үле, мие томаланган, зиһенен, иң якты хатирәләрен агу каплап киткән. Уята алырсыңмы син аны яңадан, ана? Кеше итә алырсыңмы?

Кешелеккә килгән хәвеф булып, көзге яңгыр астында ана белән бала бер-берсен танымыйча басып торалар.

Фәузия Бәйрәмова

ҖАННАРДАН ИМАН КАЧТЫ

Ул көн мәңге онытылмаслык булып хәтеремдә калган. Ниндидер ят кешеләр өй саен кереп, түр башына эленгән аятел-көрсиләрне куптарып йөрделәр. Карчыклар мыштым гына елады, әйтерсең аларның җаныннан иманнарын тартып алалар иде. Хатыннар да елады, кайберләре тавышсыз гына каргады, әмма берәү дә каршы сүз әйтмәде, ярамый иде. Тегеләр аятел-көрсине хуҗаның күз алдында ук ут төртеп яндыралар да икенче йортка юнәләләр...

Ул чакта мин сабый бала гына, мәчет сурәте төшерелгән серле гарәп язуын яндыра-яндыра бу адәмнәрнең кем белән, нәрсә белән көрәшкәнен аңларлык яшьтә түгел идем. (Баксаң, алар дин белән көрәшүчеләр булган икән!) Хәтеремдә, кинәт көчле җил чыкты, ул кара күмергә әйләнгән кәгазь кисәкләрен урам буйлап очыртып алып китте.

Әнә шулай, җимерелгән мәчет тузаны, көлгә әверелгән изге китаплар, аятел-көрсиләрнең изге юллары еллар буе җил очыртып йөрде-йөрде дә, менә бүген бумеранг булып кире әйләнеп кайтты.

Әйе, ваттык-җимердек, өздек-ботарладык, яндырдык-көйдердек һәм шушы батырлыгыбызга масаеп «яңа тормыш» төзибез дип, күкрәк кага-кага мактандык. Әбиләр заманы, бабайлар заманы безгә көлке иде. Алар саклап килгән гореф-гадәтләрне, йолаларны, бәйрәмнәрне мәгънәсез иттек. Ә үзебезнең меңәр ел тупланган рухи байлыкка каршы куярлык иманыбыз юк иде. Ә бит үткәнеңне төбе-тамыры белән йолкып атканчы иң әүвәл хәзинәдә булганны барларга кирәк иде. Ә андый хәзинәне арты

гасырда гына ничек булдырасың! Әнә шул ут төртеп яндырылган аятел-көрсиләр урынына да заман баласы иман яңартырлык бернәрсә дә куя алмады шул. Түр ягы буш торды... Җаннарыбызда да әкрен генә бушлык хасил булды. «Дин — искелек калдыгы, алла — уйдырма» дип, сәхнәгә менеп нотык укыган атеистлар да ул бушлыкны тутырырлык бүтән «алла» тәкъдим итә алмадылар. Шаулап утырган яшел урманны тураклап ташлау белән бер иде бу. Урман киселә, турала, ә яңасын утыртмыйлар, чөнки запаста үсенте юк... «Дин белән бәйләнмәгән, яңа көнкүрешкә җавап бирә торган гражданлык йолалары кертсәк, ул дини йолаларга каршы көрәштә көчле чара булачак» дип, халкыбызга хас булмаган төрле яңа йолалар уйлап таптык.

Күмү йоласын гына алыйк. Имеш, мәет өстенә мулла-фәлән чакырып тормыйбыз, табутны чәчәкләр белән бизәп, матәм маршы уйнатып заманча җирлибез. (Шәһәрне исәпкә алыйм, сүз авыл турында бара.) Университетта укыганда «Атеизм» фәне укытучысы безне шушы уңайдан интектереп бетергән иде. «Ата-анаң картаеп үлсә, аны ничек күмәр идең? Искечәме, ягъни мулла чакыртыпмы, әллә яңачамы?» дип, берәм-берәм сорау ала башлагач, кайбер студентлар — авыл балалары бик аптырады. «Яңача» дисә, әти-әнисен рәнҗетүдән курка, «искечә» дисә, укытучыдан шүрли: тиздән имтихан бирәсе бар.

Без ике ут арасында калдык. Авыл җирендә күмүҗыюны гомер бакый җиренә җиткереп ил картлары башкара иде. Әби-бабайлар катына барып ялварасы, «килегез, зинһар» дип, үтенәсе дә түгел. Язылмаган тормыш кануннары аларны кайгылы йортка үзе китерә. Инде хәзер бу авыр, мәшәкатьле миссия авыл җитәкчеләре җилкәсенә төшә, имеш! Бик шикләнеп карадым мин бу яңа йолага. Һәм укытучыга ярхшатланып кына аны мактап та чыкмадым. Шикләнүем урынлы иде. Ай-һай, бөтен авыл җитәкчеләре дә әзер микән соң моңа? Юк, әлбәттә. Кайберләренә тәҗрибә белән осталык, кайберләренә кеше кайгысына сизгерлек җитмәс, мөгаен.

Шикләрем рас килде. Моннан берничә ел элек Чүпрәле районының Зур Чынлы авылында яшәүче 54 яшьлек каенатам котельный миченә якканда газдан агуланып үлде. Күмер ташлый торган көрәген тотып, эштә үлде. Җиһазландырылмаган бинага газ җыелган булган. Мәрхүмне күмгән көнне ник бер авыл җитәкчесе килсен! Кая ул хөрмәтләү, ичмасам балалары кайгысын уртаклашып берәр җылы сүз әйтсен иде авыл Советы яки колхоз рәисе. Көт син

яңа йоланың кымшанганын, ник үлгәнеңә үкенерсең! Ярый әле шәфкатьле йоласын онытмаган авыл картлары бар: юа, җыя, кадерләп соңгы юлга озата. Ярый әле: «Китап сабыр булырга куша, сабыр булыгыз, балалар»,— дип юатучы авыл мулласы бар...

Әтиебез вафат булганнан соң бер ел үтеп китте. Уллары-кызлары, киленнәре бергәләшеп аның соңгы бәйрәменә — ел ашына кайттык. Әти изге күңелле, ачык йөзле, ярдәмчел кеше иде. Авыл халкы да бик ярата иде үзен. Шуңа күрә халык салкын җилле көн дип тормады, иртән дә, төшке якта да, кичен дә аның еллыгын үткәрү мәҗлесенә җыелды. Җилдә тирбәлгән чәчәкләр сыман әкрен генә чайкалып мөнәҗәт әйтүче карчыкларны тыңлап тордым. Нинди моң! Нинди илаһи сафлык! Ерак чорлар авазы ишетелеп киткәндәй тоелды. Алардан бу мөнәҗәтне кемнәр отып алыр икән? Бармы андый яшьләр бу авылда? Гомумән, меңәр ел берәмтекләп җыйган рухи байлыкны кемнәр кулына тапшырып китәр өлкән буын? Матур-матур гореф-гадәтләребезне кемнәр кабат терелтер икән?!

Сораулар, сораулар... Хәзер төшендек. Күңелне авыр хис биләп алды. «Яшьләр арасында атеистик тәрбияне никадәр иртәрәк башласак, шул кадәр тизрәк уңышка ирешербез» дип, тырыша торгач, без буыннар чылбырын да өзеп ташлаганбыз икән бит. Ике төркемгә бүленгәнбез. Бер якта — дин сөреме белән агуланган «томана», «надан» әби-бабайлар, янәсе. Ә икенче якта — яңа тормыш сафында атлаучы шат күңелле пионерлар, комсомоллар. Аларга әбиләр җырын җырларга кушмадылар. Мәктәпләрдә гарәп телен өйрәтүне дә кирәк санамадылар, чөнки дини китаплар гарәпчә иде. (Яшь буынны шулай дип алдадылар.) Укытучы башына тукып: «Синең әбиең дини китаплар укып шыр надан калган, аның хәленә төшмә, сабагыңны әйбәтләп өйрән»,— ди торган иде. Аның каравы, чит тел белү мәҗбүри саналды. Мәсәлән, Карасу сигезьеллык мәктәбендә (Аксубай районы) минем чорда алман теле «укыттылар». Китаптан мишәрчәләп немецча сукалыйбыз да укытучы белән бергә тәрҗемә итәбез, чөнки бу фәннән аның махсус белеме юк, ул да безнең белән өйрәнә... Шуннан чамалагыз инде алман телен ничек белүебезне! Бәлки, мин гомергә дә Германиягә бармам һәм аның тарихы да алай ук кызыксындырмас. Ә менә үз халкымның тарихын мәктәп елларында ук белмәвем бик аяныч. Безгә чын дөреслекне яшереп ялган тарих укыткан заманнарда, рәхмәт, әлеге дә баягы «надан» әбиләребез «Йосыф-Зөләйха» китапларын, «Идегәй» дастаннарын

бисмилла урынына кабатлап иманнарына тугры булып калдылар...

Хәдичә карчык йорт-җире янгач, безнең күршедәге иске генә бер өйгә күченде. Икәү капка төбендә утырабыз. Кич. Авылга көтү кайта. Әби тояк тавышларын да, этләрнең һауылдап өргәнен дә ишетми, илһамланып яттан миңа «Йосыф-Зөләйха» кыйссасын сөйли. Хәтердән генә «Казан утлары»нда басылган варианты белән чагыштырып барам. Бөтенләй икенче төрлесе! «Каян өйрәндең, әби?» — дигәч, гаҗәпләнеп: «Бәрәч, иске китаптан! Без шуларны укып үстек инде»,— диде. Аннан әрнеп өстәде: «Өем белән бергә китапларым да янды, кызым». «Әйберләреңне алырга өлгердеңме соң, әби?» — дим, кызганып. «Юк шул. Бердәнбер аятел-көрси исән калган. Әз генә читләре көйгән шунда. Сиңа бирермен. Төсем итеп сакларсың». «Бә-әк борынгы аятел-көрси...»,— мин үпкәләгәндәй күбенеп үк куйдым.

Әйе, әлифне таяк дип белмәгән килеш кулдан кулга гына күчереп йөртерлек борынгы китапларга карата яшь буында битарафлык, битарафлык кынамы, нәфрәт тәрбияләп без нихәтле хаталар җибәрдек. Китабы ят булгач, өлкән буынның яшәү рәвеше дә ят булды. «Сөйләмә миңа әбиләр әкияте!» дип кул селтәргә өйрәндек. Алар кебек яшәүне хурлык санадык. Ә бушлык торган саен зурайды, торган саен куркынычрак төсмер ала башлады.

Минем эти, биш бала атасы, әбидән яшереп тарта иде. Урамда әби күренсә, без тизрәк этине кисәтергә йөгерәбез. «Әби килә!» Бу сүз этигә шундый да көчле тәэсир итә иде ки, ул ашыга-ашыга тәмәкесен сүндерә. Ярамый, газиз әнкәңне санга сукмау була икән. Китап кушмый, ди. Ә хәзер анасының йөзенә төтен өрә-өрә тарта яшьләр. Картлар әйтмешли: «Алладан да, мулладан да курыкмый». Табынырлык алласы булмаганга, гасырлар дәвамында тупланган әхлак кануннарын белмәгәнгә, белсә дә, санга сукмаганга күрә бүгенге яшь буын күңел бушлыгын наркотиклар, урам сугышлары белән тутырмакчы була да инде. Яшермик, 15—16 яшьлек кызлар арасында фәхешлек юлына басучылар, «ромашка» уеннары оештырып, ямь табучылар азмы? «Бу ни хәл?!», дибез, аптырыйбыз. Гаепләне эзлибез. Мәктәп ата-ананы, ата-ана мәктәпне гаепли. Үзара талашып туйгач: «Нәрсә карый, пик тәрбия эшләре алып бармый? — дип, комсомолны сүгәбез. Без кызып-кызып бәхәсләшкән саен наркоманнар, фәхишәләр күбәя генә. Без: «Яшь буынга әхлакый тәрбия бирүнең нинди яңа алымнарын эзләп табарга?» — дип,

баш ватканда ташланган картлар, ташланган балалар саны һаман арта тора. Ә үткәндәге аяныч ялгышларыбызга күз салмыйбыз. Өзелгән буыннар чылбыры турында эндәшмибез. «Диндар» дигән ярлык такмасыннар дип куркабызмы? Ә бит халкымның меңәр ел буе тупланган тәрбия чараларын, адәм баласын тугач та тәртипкә, инсафлыкка, миһербанлылыкка, гаделлеккә, иманга өндәгән һәм өйрәткән әхлагын, изге гореф-гадәтләрен, йолаларын, матур-матур бәйрәмнәрен дини дип бәяләп, рухи һәм акыл дөньябыздан йолкып ташларга берәүнең дә хакы юк...

Нәбирә Гыйматдинова

КАҺӘРЛЕ «ИГЕЛЕК»

«Кама Исмәгыйле» авылында яшәүче Мөбарәкшина Мәрьям турында язып үтәсе килә. Ул бер өйдә ике ир белән яши. Берсе — никахлы ире, икенчесе — чит хатын ире.

Мәрьям белән аның хәзерге ире Шәмсетдин бик нык эчәләр, балалар атасы Мөхтәрне бик мыскыллап, җәберләп яшиләр. Хәтта яңа ире исерек килеш: «Чыгып кит өйдән!» — дип Мөхтәрне куа ук башлаган. Кыскасы, берсе — чирле ир белән, икенчесе чирле хатын белән яшәүдән баш тартканнар...

М. Фаракшина».

Әйе, бу өйдә алар өчәү яши: Мөхтәр абый, аның законлы хатыны Мәрьям апа һәм Мәрьям апаның йортка керткән ире Шәмсетдин абый. Өчесе дә пенсия яшендә. Мәрьям апаның ике ир белән яши башлавына алты ел икән. Мөхтәр абый белән Мәрьям апаның өч улы (өчесе дә читтә) һәм Шәмсетдин абый белән аның аерган хатыны Вәсимә апаның кызлары да (алар да читтә) кунакка шушы йортка кайталар.

Менә шушындый кеше ышанмаслык хәлләр бар Әлмәт шәһәреннән ерак түгел генә урнашкан Кама Исмәгыйле авылында. Хат авторыннан кала, моңа биредә игътибар итүче дә юк. Әйтерсең гадәти бер хәл, әйтерсең моннан 100 ел элек мөселман ирләренә күп хатын белән яшәү

табигый булган кебек, хәленнән килгән хатыннарга да теләсә ничә ир белән торырга ярый торган чак.

Кемнәр соң болар, җәмгыятебез өчен бөтенләй чит, ят рәвешле гомер кичерүчеләр?

Мөхтәр абый. «Адәм баласы бит, чалып ташлап булмый, асрарсыз инде»,— дигән, янәсе, аның турында Ибраһим абыйсы. Шәмсетдин шулай ди. Юк, бу сүзне ул юри әйтәдер. Мөхтәр абый кебек кечкенәдән колхозның иң кара, иң кыен эшләрен җигелеп тарткан (дуңгызлар көткән, ат караган, җир эшкәрткән һ. б.), ә хәзер сәламәтлеген җуйган кешегә карата мондый сүз әйтергә беркемнең дә теле әйләнмәс. Мөхтәр абый авылның иң хөрмәтле кешесе булырга хаклы. Әмма ул күкрәк сугып элекке хезмәтләре белән мактанмый, үзенә өстенлекләр бирү һәм ташламалар ясауны да таләп итми. Ул элеккечә үк сабыр, тыйнак, таякка таянып йөрсә дә, йорт тирәсендә үзенә һаман эш табып тора.

«Нык буранлы көн. Йомышым төшеп аларга керә идем. Вакыт шактый соң булуга да карамастан, Мөхтәр абый капка төбендә кар көрәп ята. Мескеннең куллары өшегән. Туктап-туктап өреп җылыта. «Ташла, Мөхтәр абый, туңгансың, өегезгә кер инде»,— дим. «Юк әле, тегеләр салып утыра. Андый чакта тәмсез сүзләр сөйләшәләр, керәсем килми» ди,— дип сөйли күрше хатыны.

Бу йортта Мөхтәр абыйның эшен күрүче, күңелен күтәрүче, арыса — ял итәргә чакыручы, авырса — җиләкләп кайнар чәй эчерүче, сызланса — хәлен җиңеләйтергә теләп, тирәсендә бөтерелеп йөрүче кешесе юк. Дөрес, уллары кайткалап китә икән. Ләкин алар үз мәшәкатьләре белән мәшгуль. Ә Мөхтәр абый өчен аларның кайтуы, мөгаен, әйтеп, аңлатып бетерә алмаслык газап, әрнү генәдер. Чөнки ул бит бу гаиләнең тулы хокуклы хуҗасы була торып, йортта артык бер кешегә әйләнгән. Моның өчен уллары, киленнәр алдында хурланудан күңеле өзгәләнәдер аның. Әмма аның күңеле, хәтере турында уйлаучы да юк. Әниләренең башка сыймаслык бу кыланышына балалар да киртә куярга җыенмый. Ә бит әтиләре горурлыгы өчен көрәшү бу ир-егетләрнең үз горурлыкларын да саклау булыр иде.

Мәрьям. Үзе сөйләве буенча, Мәрьям Мөхтәргә җиңгәсе белән бергә яшисе килмәгәннән генә чыккан. Шул чакта аны Мөхтәр абый яратып, ышанып үзенә сыендырган. Дөрес, Мәрьям дә эшкә карусыз булган. Баштарак дуңгыз көтүен дә бергәләп көткәннәр. Аннан Мәрьям фермага сыер саварга күчкән. Макталган чаклары да аз бул-

маган. Өч улны эшкә өйрәтеп, кеше итеп үстергәннәр Мөхтәр абый белән бергәләп.

Һәм менә, тормышлар көйләнеп, балалар урнашып җитте дигәндә, Мәрьям Мөхтәр абыйның тыныч картлыгын челпәрәмә китергән. Баштарак аракы белән бәйләнешкә кергән, аннан күзенә чит ир-атлар чалына башлаган...

— Тормыш авырлыгына түзәр хәлем калмады...— дип аңлата ул Шәмсетдинне йортка кертүенең сәбәбен.

Шәмсетдин. Бу кеше башта шахта якларында йөри. Хатыны Вәсимә апаны да шуннан алып кайта.

Аның хатынының матурлыгына сокланмаган кеше булмый. Шушы курчак кебек хатынын, ике баласын Шәмсетдин әнисе кулына тапшыра. Зәһәр каенана килен өстеннән ни теләсә, шуны эшли. Ямьсез сүзләр белән мәсхәрәли, кыйный, алай гына ачуы басылмаса, киленен Шәмсетдиннән тукмата...

Бу гаиләдә Вәсимә апага карата кылган явызлык, вәхшилек турында авылдашлары сөйләгәнне язып бетерү мөмкин түгел, язсаң да аларга кеше ышанмас. Аңа бары Вәсимә апаның вакытсыз агарган чәчләре, елап гомер кичерүдән нурсызланган күзләре, әледән-әле аяктан егып җәфалаган авыруы гына шаһит.

Шәмсетдиннең өйдән чыгып китүенә сөенә генә ул. Бүген аның җаны тынычлыкка мохтаҗ. Тормыш-көнкүреше авыр булса да, аяктан егылганда караучысы булмаса да риза Вәсимә апа бүгенге ялгызлыгына. Хәтта кызларының үзен чит итеп, үги әни янына кайтып йөрүләренә дә рәнҗеми. Ә кызларында — этиләре каны, әбиләре тәрбиясе. Кечкенә чактан ук, әбиләренә ияреп, әниләрен «Вәси тәре» дип кыйнап үстеләр, диләр авылдашлары. Дөрес, авылга кайткач, әниләренә булышкалап, азмы-күпме кучтәнәчен калдырып китәләр икән. Аларны күкрәк сөтен имезеп үстергән, балалар хакына дип нинди газапларга түзеп яшәп шушы көнгә калган ана хәсрәтен, ана фаҗигасен инде үзләре дә башлы-күзле булган кызлары бөтен тулылыгы белән аңларга тиеш иде югыйсә... Ә алар үз әниләре янына, үз нигезләренә Мәрьям янына кунакка кайткан җирдән сугылып кына чыгалар. Алар Мәрьям йортына кайтып йөрүне оят эшкә дә, хурлыкка да санамыйлар.

Авыл ни уйлый? Мәрьямнең бер өйдә ике ир белән яшәгәнен Кама Исмәгыйле авылында гына түгел, тирә-юньдә дә беләләр. Район үзәгенә дә ирешкәндер бу сәер хәбәр. Әмма, нигәдер, моңа чик куярга уйлаучы юк. Ярый,

Шәмсетдин абыйның авыру хатынын аерсыннар да ди (барыбер Вәсимә апаны гүргә кертмичә кыйнау-җәфалаудан туктамас иде ул). Ә Мөхтәр абый? Шәмсетдин белән Мәрьям аны үз яннарында асрауны игелеклелек дип саныйлар. Нәрсәсе игелеклелек соң моның?

Мәрьям: «Бүрәнәнең юан башы гел миңа булды»,— дип зарлана. Тик нигә соң, алай булгач, алдан ук бөгелеп төшмәгән? Алай гынамы, анда әле яңадан бер ир белән тормыш башлап җибәрерлек дәрт, гайрәт калган. Әгәр аңа ир бүрәнәнең авыр башын күтәрер өчен генә кирәк икән, нигә уллары күтәрми ул бүрәнәне?

Мәрьям инде яшь кеше түгел, авыл хатыннарының сугыш елларында күргән хәсрәт-михнәтләрен дә, аннан соңгы елларны да яхшы хәтерлидер. Илгә күпме аяксыз-кулсыз, чукрак-сукыр ир кайтты. Аларны сөйгән кызлары, хатыннары колач җәеп каршы алды, хөрмәтләп тәрбияләде. Бүгенге тормышта да азмы әллә урын өстендә яткан ирләрен, әти-әниләрен, туган-тумачасын карап-тәрбияләүгә үзенең яшьлеген, хәтта бөтен гомерен багышлаган хатын-кызларыбыз? Һәм моны без мәхәббәткә, антка, илгә-көнгә тугрылык, игелеклелек, кешелеклелек дип атыйбыз. Бу игелеклелек Мәрьямнәр һәм Шәмсетдиннәр «игелеклелегенең» капма-каршысы.

Соңгы сүз. Су буендагы ярым җимерек йортта Вәсимә апа моңлана, яшьлеген сагына, укенечле гомере турында уйлана. Өч кыз үстергән ананың серен сөйләрлек кешесе, хәлен җиңеләйтерлек таянычы юк бүгенге көндә.

...Авылның кыр ягы читенә урнашкан шактый таза нхата тирәсендә таягына таянган Мөхтәр абый нидер эшли. Күңелендә, уйларында нинди ут икән аның?

Менә шушы ике кешенең какшаган саулыгы, сынган рухы, рәнҗетелгән җаны хисабына гомер итәләр бүген Мәрьям белән Шәмсетдин. Бернинди вөҗдан газабы кичермиләр, авылдашларының күзләренә туры карыйлар.

Ә авыл гүя күзләрен йомган, колакларын томалаган. Ул берни күрми һәм берни ишетми.

Язилә Абдулкадыйрова

БЕР МӘХӘББӘТ ТАРИХЫ

Көзнең бер матур киче иде. Сап-сары яфрак яңгыры ява. Яфраклар очынып-талпынып безнең эскәмиягә килеп куналар да, «Инде кая барыйк»,— дигәндәй искән җилдән

калтыранып куялар. Янәшәмдә утырган ханымны мин инде җәйдән бирле очратам. Ничектер бер-беребез белән сөйләшеп кенә китә алганыбыз юк. Минем кебек аңа да бу тыныч, аулак урын ошый бугай. Ошамаска ни! Яныбызда гына, эскәмиягә сыенып, пар каен үсә. Ул эссе җәй көннәрендә үзенең күләгәсе белән, ә көзләрен алтынсу матур төсе белән ымсындырып, чакырып тора. Аннан соң монда урам гөрелтесе ишетелми, каршыдагы сукмактан үтеп-сүтеп йөргән кешеләр дә комачауламый. Кыскасы, арган-талган җаныңны тынычландырып, рәхәтләнеп һава сулап утыр.

Менә яфраклар өстенә вак яңгыр сибәләргә тотынды. Мин, салкын яңгыр тамчыларыннан качарга теләп, зонтигымны җәеп җибәрдем. Ханым да җилкәләрен җыерып, бөрешеп куйды. «И без, адәм баласын,— дип үз-үземне тиргәп алдым,— ләм-мим сүз сөйләшмибез. Әллә ул, әллә мин кыенсынам. Әллә дөнья мәшәкатьләренә күмелеп шундый да тирән уйларга чумуыбыз микән? Кемдер башлап эндәшергә тиеш, ләбаса!»

— Ышыкланыгыз,— дидем мин зонтигымны аңа табан сузып.

— Рәхмәт,— диде ул,— мин озак утырдым, хәзер кузгалам инде.

— Алайса, иртәгә күрешәбез икән. Бу эскәмияне икебез дә үз иттек бит.

— Шулай шул. Ләкин мин иртәгә дә, берсекөнгә дә килә алмыйм. Китәм мин. Казаннан бөтенләйгә күчеп китәм.

— Ераккамы?

— Төмәнгә.

Кыска-кыска гына сүз алышкач, без тынып калдык.

— Кара әле, үскәнем,— диде ханым кинәт йөзе белән миңа табан борылып,— йөрәгемдә китмәсен әле, серемне сөйләп калдырыйм әле үзеңә. Бу эскәмияне саклавым тикмәгә түгел бит минем. Син үзең дә сизмәстән, минем бәхетле мизгелләремнең шаһиты булдың. Хәзер алдыбыздагы сукмактан бер кеше узып китәчәк. Бераз кичекте, киңәшмәсе бугай. Ул күренгәнче сөйләп өлгерәм әле.

— Гаиләбез ишле иде,— дип башлады ул сүзен.— Бер әнигә җиде бала. Сигезенче классны тәмамлагач, авылда сыер саудым, аннан шәһәргә килеп урнаштым. Больницага, җыештыручы булып. Җыям, юам, бернәрсәдән чирканмыйм. Беркөнне хирургия бүлегенә берәүне китерделәр. Йөзе сап-сары, көзге яфрак төсле, күзләреннән нур сүн-

гән, иреннәре күм-күк. Төрлесен күргән бар иде, ә моны нерым кызгандым. Ир кеше, утыз яшьләр тирәсе булыр. Операция ясадылар моңа. Хәле бер дә әйбәтләнми, гел кирегә бара. Врачлар ни генә кылса да, файдасыз. Тукта, мәйтәм, япь-яшь килеш гүрдә ятмасын инде бу бәндә, сестралар өлгерми, җыештырып чыгам да тегенең палатасына ашыгам, үземчә җан өрмәкче булам. Тешләрен шытырдатып кыскан иде, каерып ачып су салдым. Ике йотым. Аннан мамыкны салкын суга манчып битен-кулын сөрттем, чәчен тарадым. Аннан йөгердем базарга, алдым тавык, әйбәтләп пешердем шулпа һәм тагын авыру янына чаптым. Башын күтәреп шулпаны да эчердем. Капты, өч-дүрт кашык чамасы. Шулай да ярый. Бер сестра әйтә: «Нәрсә шуны тәрбиялисең? Барыбер теге дөнья кешесе бит ул»,— ди. Аның шомлы хәбәреннән соң тагын да үҗәтләнебрәк карый башладым. Кишер согы ясап каптырам, алма согы, гөлҗимеш суы кайнатып апкиләм. Төнлә дә дежур тора башладым. Минсез үткән ярты сәгать тә зур югалтуга китерер: явыз үлем аңа тырнагын батырыр сыман. Атна-ун көннән моның хатыны килде. Чибәр. Иләһи әйбәт киенгән, гел импорттан. Озак утырмады, дару исеннә күңелем болгана, ди. Киткәндә мине коридорга чакырып чыгарды да:

— Үлгәч хәбәр итәрсез, менә өй телефоны,— дип кулыма кәгазь тотырды. Ачуымнан кызарсам-бүртенсәм дә кайтарып дәшмәдем, берни булмагандай, кире палатага кердем. Үзем сиздермичә генә авыруның йөзенә карыйм, иреннәрен кысып тешләгән, ә хәрәкәтсез калган күзләрен миңа төбәгән.

— Минем хәлем ничек? —дип сорады бу.

— Синең хәлең әйбәт, тиздән тереләсең,— дидем мин.

— Алдашма,— диде ул, — алдашма, сестра. (Ул мине сестра дип уйлый иде.)

— Алдашырга вакытым юк әле,— дигән булдым,— синең җилкәңә массаж ясыйсы бар. Бүген чәчеңне дә юабыз.

Дөресен генә әйткәндә, хәлләре начар иде бит... Ләкин мин өметсезлекне өмет белән алмаштырырга уйладым. Йокы туймаудан башым әйләнсә дә, арысам да, ябыксам да бишенче палатадан чыкмадым. Ике айдан соң авыру беренче мәртәбә елмайды, беренче мәртәбә күзе төшеп бер телем карбыз сорап ашады. Ә мин шатлыгымнан елап җибәрдем. «Елама, сестра, болай булгач яшибез»,— ди мескенем. Тиз-тиз генә урын-җирен алыштырдым, чиста киемнәр кигездем, битен юып, чәчләрен тарадым. Хатынын чакырырга иде исәбем. Шалтыраттым, нин-

дидер нәзек тавыш: «Ул отпускада. Кара диңгез буенда ял итә»,— диде.

Шул рәвешчә көннәр ага торды. Авыруның йөзендәге сары төс кимеде, ул торып утыра башлады. Ашавы да рәтләнде. Ризыкны гел үзем пешерәм, үзем кашык белән ашатам. Күрәм, көннән-көн алга барабыз, ул миңа хәтта җырларга да куша. Авыз эченнән генә көйләп йөрүемне ишеткән күрәсең. Мин оялмыйм, җырлыйм. И кайнар яшьлек! Җыр запасым аз иде, бер төнне иптәш кызымның магнитофон тасмасына яздырган бөтен җырын өйрәндем. Җырым белән бик тә сөендерәсем, хисләндерәсем, яшәүнең рәхәтен татытасым, үлемне җиңдертәсем килә иде бит.

Шул чакларда әллә нинди хис уянды бит мин тиледә. Кара чәчләрен тарак белән түгел, назлап күз карашым белән тарыйм, битен су белән түгел, мәхәббәтем белән юам. Яраттым мин аны, гыйшкым төште. Хирург: «Теге иптәшне син генә терелттең,— ди. Бу хәтлесен үз өстемә ала алмыйм. Тырыштым инде, бик каты тырыштым. Бәгырькәемне иңнәремә таяндырып коридор буйлап йөртә идем. Арыса, кулларыма күтәреп палатага кертеп салам. Җанымны бүлеп бирергә әзер идем, билләһи.

Терелеп үз аяклары белән больницадан чыгып киткәндә ул миңа:

— Син сестра түгелмени?! Җыештыручы гынамы? — дип әйтеп китте. Үзәкләрем өзелде инде, ботагыннан җил тартып өзгән алма кебек өзелде. Тик сүзләренә рәнҗемәдем. Үлеп яраткан кешеңә рәнҗеп булмыйдыр ул. Рәхмәт тә көтмәдем. «Күр дә тор, врач булачакмын»,— дип ант иткәнем хәтердә. Аңа тиңләшергә тырышып, кыенлыкларны җиңә-җиңә кичке мәктәпкә укырга кердем, медицина училищесына имтихан тоттым. Училище тәмамлагач, институтка. Врач мин, кешеләр дәвалыйм. Мәхәббәтем миңа алдагы тормышымда көч бирде, дәртләндерде..

Мин түземсезләнеп ханымга сорау бирдем.

— Сез аны күргәнегез бармы соң?

— Ашыкмагыз, хәзер,— диде ханым.— Ул хәлләрдән соң егерме ел үтте, үскәнем. Очрамады түгел, әйбәт-әйбәт кешеләр очрады, күңел генә тартмады. Оныта алмадым мин аны. Күз алдымнан бер генә минутка да китми иде. Ара-тирә сорашып, белешеп тордым. Эшли, исән-сау, дәрәҗәле кеше булган. Бервакыт шулай урамнан барам. Каршыма ул килә. Торараташка әйләнеп катып калдым бит. Кешеләр бәрелеп-сугылып үтеп китә, ә мин торам да торам. Менә ул: «Исәнме»,— дип кул биреп күрешер, ба-

рысын да, сорашыр, ә мин үземнең уңышларым турында сөйләрмен, аңа — мәхәббәтемә — мине рухландырып яшәткән өчен рәхмәт әйтермен, дим. Танымады, бүтәннәр сыман бәрелеп узып китте. Мөгаен, ашыккандыр. Култык астына папка кыстырган иде. Язмышның шаяруын күр син! Икенче мәртәбә алдыбыздагы сукмакта күрдем үзен. Шушы эскәмиягә ял итәргә утырган идем, бу узып бара. Шуннан бирле... Биш ел рәттән бирегә киләм мин. Ул һәркөнне кич белән, төгәл бер вакытта өенә кайта. Ә мин яшертен генә аңа карап калам. Яшь чаклардагы кебек җүләрлегем булса ике дә уйламый: «Мин сине яратам!» — дип кычкырыр идем. Юк шул, кырык яшьлек хатынга алай дип кычкыру килешмәс. Миңа болай да рәхәт. Аны күреп, аның исән икәнен белеп яшәү рәхәт. «Әлләниләр бирер идем, сине бер күрер өчен»,— диләр бит. Җан тарткан кешеңне күрер өчен чынлап та, әллә ниләр бирерсең. Була, җан тулып ташкан чаклар да була, аның белән бер утырып сөйләшергә тилмергән көннәр... Яшермим, зуррагына да хыяллана идем, яшь чакта инде. Икәү пароходта йөзәргә яки җырлый-җырлый болыннарда чәчәк җыеп йөрергә. Яшьлегем артта калган саен хыялны салкын акыл йөгәнләде. Инде урам чатына басып өч сүз алышсам да риза.

Ханымның зәңгәр кыңгырауларны хәтерләткән күзләрендә яшь бөртекләре җемелдәште.

— Түбәнгә китүем — аны онытыр өчен түгел. Мәңге йөрәгемдә саклап тотар мәхәббәтем бит ул минем. Түбәндә врачлар бик кирәк. Безнең коллективта тәкъдимнәр булды да мин ризалык бирдем. Үз профессиясен яраткан, хөрмәт иткән врачка кайда да бер. Китәм инде, бүген соңгы тапкыр сүзсез генә саубуллашам да...

Шунда ханым иелеп миңа пышылдады:

— Әнә ул!

Мин сискәнеп сукмакка карадым. Болай таба ике ир-ат килә иде. Берсе чәчәк тоткан, икенчесе, тәбәнәк буйлысы, култык астына папка кыстырган. Мөгаен, икенчеседер. Менә ул якынлаша, якынлаша... Тиздән узып та китәр... Аның каршына атылып чыгасы да: «Синең җаның бармы? Тукта, ичмасам, бер генә минутка булса да тукта!» — дип кычкырасым килде...

Нәбирә Гыйматдинова

ЯЗМЫШТА НИК ЯЛГЫШ БАР?

...Диплом алган көненнән дә куанычлы көн булмагандыр Фәрит өчен. Канатланып класска кергән минутларын төш кебек кенә хәтерли ул. Көчле математик укучылар күңелен бик тиз яулады. Бигрәк тә малайлар укытучыга якынайдылар. Фәрит Мәхмүтович та алар өчен вакытын кызганмады. Артык сәгатьләр даулау белән дә мавыкмады. Дәрестән соң күбрәк укучыларны үз янына җыя иде. Бергәләп бәхәсләшә-бәхәсләшә теорияләр исбатладылар.

Мәктәп, укучылар Фәритнең икенче гаиләсенә әверелде. Яшь укытучының күңеле берсеннән-берсе матур хыяллар белән тулды. Әтиләр, укучы малайлар белән эшләнәсе эшләр, оештырыласы чаралар планлаштырыла барды аның уенда. Әммә тормыш дигәнең син теләгәнчә генә акмый икән шул. Өйләнүгә үк Фәрит ике ут арасында калды. Торыр, яшәр урын проблемасы килеп басты. Рәзинәсенең олылардан аерым яшисе килде. Фәрит эзләп тапкан бүлмә аңа ошамады. Эшкә әби кеше керешге. Ул үз зәвыгына, кызына ошаган фатирны тапты. Һәм җае чыккан саен киявенең кем квартирасында яшәвен искә төшерә торган булып китте. Фәрит моңа игътибар итмәскә тырышты. Йөрер юлы озынайды. Гаилә мәшәкатьләре өстәлде. Шулай да ул укучылар янында булу вакытын киметмәде. Я барганда, я кайтканда әти-әнисе янына кереп хәлләрен белде, эшләренә булышты. Яшь кәләш аны елмаеп каршы алды. Ләкин бу яктылык озакка бармады. Фәрит беренче хезмәт хакын алып кайтуга, ул өреп сүндергәндәй булды.

— Нишләп бик аз? Сигездән-сигезгә хәтле эшләп алган акчаң шушымыни? — диде Рәзинә, иренә сораулы караш ташлап.

Фәрит өчен көтелмәгән сорау иде бу. Шуңа күрә башта аптырап, югалып калды. Аңлатырга керешсә, гаепсездән аклану кебек тоелды. «Аз түгел ич»,— дип җавап бирү белән чикләнде. Ә яткач йоклап китә алмый интекте. Хатынының шикле соравы башыннан чыкмады. Ахырда ике арада аңлашуны кирәк тапты ул. Рәзинә, аны аңлагандай, хезмәт хакы турында бүтән сүз кузгатмады. Ләкин бер атнаның шимбәсендә Фәритнең әбисе белән бабасы килеп чыкты. Чәй эчәргә утырганчы, алар Фәриткә зал өчен җиһазлар гарнитурына чират алу юлын өйрәтә башладылар. Гап-гади гаиләдә үскән егет затлы җиһазлар түгел, ә туачак бәбиләре турында, аны чыныктырып, сәла-

мәт итеп үстерү өчен шушы өйнең бер почмагында үзе ясап куячак нәни корылмалар турында хыялланып йөри иде. Шулай да олы кешеләр сүзенә каршы төшмәде, әдәпле генә тыңлап утырды. «Аны гына уйлап йөрмәсләр, оныттырлар, үтәр әле»,— дип уйлады. Әмма бөтен гомерләрен күрше-тирә, туган-тумачадан көнләшә-көнләшә дөнья малы җыеп яшәгән әбисе белән бабасы бу фикерләрен килгән саен күпертә генә бардылар.

Давылның көчлесе Фәритнең улы туып, хатыны өйдә бала белән утыра башлагач кузгалды. Тәҗрибәсез әти кешене тәки үз уңаена бөкте бу җил-давыл. Ул җәйге ялында «шабашник»ларга ияреп авылга китте. Колагында үз нәниенең тавышы, укучыларның күңелле гөрелтесе тынмаса да, эштә яңа дусларыннан калышмады. Эшне төгәлләп, исәп-хисапны өзеп кайтканда, кесә шактый калын иде Фәритнең. Ул моны улы хакына гына эшләвен, киләчәктә беркайчан да кабатламаячагын күңеленә беркетте.

Укучылары да бик сагынганнар иде аны. Шулай да үпкәләрен әйтми калмадылар: «Фәрит Мәхмүтович, быел булмады инде, үзегез әйткән Идел буйлап сәяхәткә икенче елга чыгарбыз, яме»,— диделәр. Тик аларның планы икенче елны да барып чыкмады. Укытучы абыйлары тагын «шабашник»ларга иярде.

— Хатының белән балаңны туйдырырлык та акча алмагач, төкерим мин синең югары белемеңә,— дип кызып китте әби кеше бер килүендә. Фәрит: «Нишләп алай булсын»,— дип әйтеп бетерә алмады, ул тагын тезә башлады:

— Харап икән, 150 тәңкә акча ала. Нәрсәгә җитә соң ул? Я, нәрсәгә җитә? Үзеңә тупырдап торган малай тапты, ә син хатыныңа шуның өчен нәрсә бүләк иттең? Биш тәңкәлек чәчкә, әйеме? Биш йөз тәңкәлек тун кирәк иде аңа. Я эшеңне алыштырасың, я кызымны алып китәм,— дип кырт кисте ул ахырда.

Әбисенең артык узына башлавыннан шактый ярсыган күңелен басарга теләп һәм үзенең бу гаиләнең башлыгы икәнлеген дә белгертеп:

— Мин дә эшемне алыштырмыйм, Рәзинә дә китми,— дигән генә иде, моңарчы бу сөйләшүне сабыр гына тыңлап торган хатыны: «Эшләгәнең үз расходың белән квартирага түләп торырга да җитми бит, җаным, тотма син мине, бала белән утырганда булса да әниләргә китеп торыйм, аннан күз күрер»,— дип, әзерләнә үк башлады...

Эшен күпме генә яратса да, баласын ятим итүдән курыкты Фәрит. Бердәнбер мәхәббәтен — Рәзинәсен дә бик

ярата иде шул. Шушы ике изге зат хакына үз хыялларын корбан итүне үзенчә ирлек дип санады. Төзелеш бригадасына эшкә урнашты. Балта эшенә элек тә һәвәслеге зур иде. Инде бөтенләй остарды. Беренче сентябрь көннәрен генә авыр кичерде.

Бүрәнәләрдән очкан йомычкадай кәрзинләп кергән акчасын алган саен өенә очынып кайта ул. Хатынын, улын, кызын куандырмак була. Әмма дөньяны куып тотып буламыни? Рәзинәгә дә, үскән саен балаларга да һаман күбрәк кирәк була бара. Әти кеше алып кайтып салган акчаны тиз-тиз санап урнаштыралар да рәхмәт әйтергә дә онытталар.

Кооператив йорттан өч бүлмәле квартира алдылар. Өй эчендәге малның чиге юк. Гаражда «Москвич» тора. Рәзинәнең муен-беләкләрендә асылташлар җемелдәшә... Тик тормышларының бер генә куанычы да юк. Әнигә назлап «әнием», этигә «әтием» диюче юк бу өйдә. Балалар аларга «Әй, старина», «предки» дип кенә дәшәләр. Туган көннәр, бәйрәмнәрдә түр өстәлгә гаилә табыны көйләнми. Шкафларда тезелгән фарфор, бәллүр чынаяк, вазалар еллар буе кузгалмый. Фәритнең җаны өермә булып дулый бу тормышка. Ләкин хатынының, балаларының тынычлыгын бозудан курка. Сүз дәшми. Төннәрен уянып китеп, үзе үскән тар гына бүлмәне, кечкенә генә шатлыкны да зур итеп, гөр килеп, куанып гомер иткән әтисен, әнисен сагына.

Я, нәрсә отты соң Фәрит бу тормыштан?! Рәзинәсен бәхетле иттеме? — Юк! Акча колына әйләнде. Дөнья малына табынып эшен ташлады. Үзе һаман канәгать түгел. Ә соң балалар? Алар бәхетле булачакмы? Монысы да икеле. Алар кулларындагы әйберне «мә» дип бүлешә белмиләр. Кирәкләрен дә «бир әле» дип түгел, «давай» белән генә даулыйлар. Мохтаҗлыкны күрми үстеләр шул.

Үзенә егет чакта олысы-кечесе зурлап «Фәрит Мәхмүтович» дип дәшә иде. Ә хәзер исеме «пәри» аның. «Шабашник»лар белән беренче тапкыр акча «көрәргә» чыккан сәфәреннән ук «ябышты» аңа бу исем.

Тормышның башыннан ук ир-егет була алмавы өчен өзгәләнде Фәрит. Мондый чакларда бердәнбер юанычы аракы булды аның. Хәер, моңа ул үзе гаепле идеме соң? Олы кешегә гаеп атарга хакы булмаса да, әбисенең комсыз капканын каргады ул.

Төнге уйлары башына сыймас булгач, әкрен генә торып киенде дә урамга чыкты Фәрит. Салкын һава сулауга, күңеленә бераз җиңел булып китте. Сутелеп чуалган йом-

гагының очын эзләгәндәй, атлый-йөгерә кайчандыр үзе укыткан мәктәп ягына ашыкты.

20 ел буена мәктәптән, балалардан, яраткан хезмәтеннән акчаны өстен күреп яшәгәннән соң, класс каршына ни йөзе белән кереп бассын инде ул. Алай гына да түгел, мәктәп, институт биргән белемнәре дә хәзер башында төтен булып кына бөтерелә. Ә бит алар кайчандыр ныклы иде, нигезле иде. Нинди зур өметләр, якты хыяллар белән үзләштерелгәннәр иде. Тик артына борылып карап кына күренми торган ерак үткәннәрдә калды алар. Аралар меңнәр, затлы мал, аракы сөреме белән гомерлеккә аерылды.

Язилә Абдулкадыйрова

СӨЕНЕЧКӘ ДИСӘМ...

Дилә, бүлмәгә килеп кергәч, моңарчы тыеп торган күз яшьләренә ирек бирде. Үзе, аяк киемен дә салып тормыйча, караватына ауды. Әллә ничә тапкыр әнисе кереп чыкты, аңа нидер дәште. Тик Дилә берни дә күрмәде дә, ишетмәде дә. Әйтерсең, үзеннән һәм күңелсез уйларыннан башка аның өчен бернәрсә дә юк иде. Гомерендә иң шатлыклы һәм дулкынландыргыч көннең болай тәмамлануына әле дә ышануы кыен иде.

...Әйе, көннең иртәсе гаҗәп матур башланды. Кайчак була бит күңелнең шундый күтәренке чагы. Бер генә нәрсә дә синең кәефеңә зарар китерә алмас кебек тоела. Үзеннән-үзе очып кына йөрелә, җырлыйсы, туктаусыз көләсе килә. Дилә белән дә шулай иде. Күңел күгендә ник бер болыт әсәре булсын. Бу иләс-миләслекнең, әлбәттә, сәбәпчесе — «ул». Кичә Даниял аңа тәкъдим ясады. Дилә, аның тел төбен күптән сизеп йөргәнгә күрә, сөйләшүне сузып маташмады. Ул риза иде. Күпме кичерешләрдән, йокысыз үткәргән төннәрдән соң, ниһаять, алар бергә. Мондый вакытта күзгә йокы керәме соң. Шуңа да Дилә таңнан ук торды. Башта кухняда әнисенә булышты, аннары үз-үзен тәртипкә китерергә кереште. Сәгать уникедә Даниял килеп җитәчәк. Аңа кадәр әзер булып торырга кирәк. Ул парикмахерскаяга барып чәчен ясатып кайтты. Зал якта мул итеп әзерләнгән өстәлгә күз төшереп алды. Аннары шифоньер янына килде. Ишеген ачып кадерле бүләген кулына алды. Искиткеч купшы итеп тегелгән

нәфис бу ак күлмәкне аңа Даниял өч көн элек кенә бүләк итте әле. Ул аны Украинада командировкада чакта алган иде. Дилә, күлмәкне киеп, бөркәнчеген ябынды. Көзгедән үзенең чагылышын күреп бераз сокланып торды. Йөрәге дулкынланып тибә иде.

Кайсы гына кыз үз гомерендә шушындый ак күлмәкне кию турында хыялланмый да, бу көннең житүен түземсезлек белән көтми? Диләнең бу хыялы тормышка ашты. Бер-ике сәгатьтән ул шул киемнәре белән иптәш кызларының соклануы, көнләшүле карашлары астында Даниял белән янәшә өстәл түрендә утырачак! Үзең яраткан кешең белән кавышудан да зуррак бәхет бармы соң ул?!

Тик менә алдагы тормышлары ничек булыр? Даниял аны гомере буе шулай яратырмы? Юк, Даниял начар кеше түгел. Ни генә булмасын, ул Диләнең таянычы булачак. Дилә аны белә. Кичә генә танышмадылар ич.

Көзге каршында бер ялгызы үзенең буй-сынын карап торган килеш, Дилә бермәл уйланып торды. Даниялны беренче очратуын хәтерләде.

...Аның белән бергә училище тәмамлаган кызлар кайсы-кая тормышка чыгарга өлгергәннәр иде иде. Диләнең генә күңеле буш. Иптәш кызлары егетләр белән яисә алар турында үзара чыркылдашып сөйләшкәндә ул бер читтә тора, әйтерсең егетләр аның өчен бөтенләй юк иде. Ләкин, күрәсең, һәркем өчен олы мәхәббәтнең үз вакыты бар. Кайчан да булса ул килә, тик аны сабырлык белән көтеп ала белергә, аңарчы хисләреңне вакламаска кирәк. Диләгә дә ул килде...

Бервакыт озын буйлы, офицер киемендәге бер кеше Дилә эшли торган бүлектән нәрсәдер сатып алды. Ул чакта Дилә аңа артык игътибар итмәде. Ләкин әлеге офицер кибеткә еш керә башлады. Алган әйбере дә нәрсә генә! Бер кап сигарет яки шырпы, кайчак бер кисәк шоколад була. Шуның өчен ул, чират никадәр генә зур булса да, сабыр гына көтеп тора. Кирәкле әйберен алгач, тыйнак кына елмаеп Диләгә рәхмәт әйтә. Башка сатып алучыларга һич тә охшамаган бу кешегә Дилә игътибар итә башлады. Ә берара ул кеше шактый вакыт күренми торды һәм хатын-кызлар көне Сигезенче март алдыннан гына пәйда булды.

Бәйрәм алдыннан була торганча, кибеттә кеше күп иде. Әлеге офицер чиратның иң ахырына басты. Дилә шулкадәр житез эшләгәнлектән, озын чират тиз арада юкка чыкты. Менә иң соңгы кеше. Дилә аңа баш кагып, ягымлы гына дәште:

— Сезгә нәрсә?

— Бу юлы берни дә кирәкми,— диде әлеге офицер, үзе Диләгә өч чәчәк сузды.— Бәйрәмегез белән, Дилә!

Шул көннән соң иптәш кызлары Диләне мөлаем йөзле, озын буйлы офицер белән очрата башладылар.

Даниял һәрчак үзен әдәпле тота, хисләрендә искиткеч тыйнаклык саклый белә иде. Шулай да, аның һәр карашыннан, һәр хәрәкәтеннән бөркелеп торган олы хисне Диләйөрәге белән тоймыйча кала алмады. Даниял аның бөтен күңелен биләп алды. Диләнең аны уйламаган, аның белән горурланмаган бер генә минуты да юк иде.

Беркөнне, «Казан» ресторанында утырганда, Даниял Диләне һич көтелмәгән хәбәр белән шаккатырды. Диләүз колакларына ышанмыйча, әллә Даниял шаяртамы дигәндәй, гаҗәпләнеп тыңлап утырды. Тик Даниялның шаяртырга исәбе дә юк иде. Әйе, аның Даниялы бер мәртәбә өйләнгән булган икән. Уйласаң, исең китәр! Хатыны аны аңламаган. Шундый кешене дә аңламыйлар микәнни? Даниял командировкада чакта, кызын әниләренә илтеп, башка берәү белән китеп барган... Нинди йөрәксез хатын икән ул!..

Бу көнне каршылыклы уйларына бернинди җавап таба алмыйча таңны аттырды Диләә. Әнисе белән киңәшү дә файда бирмәде. Киресенчә, тагын да борчыды гына. Әнисе балалы ир белән язмышын бәйләмәскә киңәш бирде. Ул әйтмешли, «үз тиңе» табылыр-табылуын. Тик бүтән кешене Даниялны яраткан кебек яратып булырмы?.. Юк, аннан башка тормышны күз алдына да китереп булмый! Нәрсә генә булмасын, Диләаны ташламаячак. Үзен дә, кызын да. Һәр икесен дә гомере буе яратачак!

Шул карарга килгәч, ул яңадан тынычланып китте. Көн саен Даниялның кызы янына бара, аңа уенчыклар сатып ала. Кызчык аңа тәмам ияләшеп җитте. Ә бит нинди генә сүзләр ишеттермәделәр Диләгә шул чакларда.

— Юньле булса, хатыны китмәс иде, үзе рәтле түгелдер...

— Ирекле баштан балалы кешегә!.. Ничек яшәмәк кирәк?..

Әмма Диләнең карарын һичнәрсә үзгәртерлек түгел иде инде.

...Звонок шалтырады. Диләә, уйларыннан бүленеп, атылып-бәрелеп ишеккә йөгерде. Даниялдыр. Ләкин ул түгел иде әле. Кунаклар килә башлады. Ә нигә соң Даниял озаклады? Бер генә минутка да кичегә торган кеше түгел ич ул. Берәр хәл булмагае...

Сәгать теле, һичкем белән исәпләшмичә, әйләнә дә әйләнә. Менә ул инде уникедән дә шактый авышты. Диләнең күңеле аның саен шомлана бара. Даниял, мөгаен, берәр бәхетсезлеккә юлыккан. Яшен тизлеге белән башына килгән шушы уй кинәт аны тетрәндереп җибәрде. Ул тиз генә киенде дә, кунаклардан гафу үтенеп, урамга чыгып йөгерде.

...Даниял яныннан кайтып, караватына аугач, Диләинде онытылып бара торган бер очрашуны күз алдына китерде. Даниялның хатыны Мәдинә белән иде ул очрашу. Мәдинә аның янында озак сөйләшеп утырды. «Кызым Алсуны сагынып килдем, бер күреп китим дидем» дип сөйләгән иде Мәдинә. Диләбу хатынның гаҗәп сөйкемле һәм чибәр йөзенә, кызлардан болайрак нәфис буй-сынына, купшы киемнәренә сокланып утырды. «Менә нинди матурлык! Даниял сайлый белгән икән!..»

Мәдинә сөйләде дә сөйләде. Аның күп сүзләре инде истән дә чыккан. Ә хәтердә калганнары колак төбендә яңгырап тора сыман.

— Интектем мин ул Даниял белән. Гомеремнең иң матур чагын иргә чыгып та ялгыз үткәрдем... Командировкадан кайтып кермәде... Ярый әле китеп котылдым. Юкса, гомерем шулай әрәмгә узасы икән.

— Яратсаң, алай уйламыйсың,— дигән иде Дилә.

Мәдинә авыз чите белән генә матур итеп елмайды.

— Шулкадәр дә беркатлы булырсың икән. Бармы соң ул ярату?.. Дөрес, китапларда бар. Ә тормыш бүтән. Менә минем хәзерге ирем кеше ичмасам! Гел янымда...

Саубуллашканда Мәдинә аңа бәхет теләде, Даниялның әйбәт кыз табуына шатлануын белдерде. Үзе, кызымны сагындым дигән булса да, кемнедер күрәсем бар дип ашыгып чыгып китте.

Мәдинә Даниялның өйләнәчәген ишеткәч, Стәрлетамак белән Казан арасын аз таптамаган. Елыйсы җирдә елаган, язасы җиргә язган. Һәркайда Даниялны даулап йөргән. Үзен ире ташлап киткән мескен бер хатын итеп күрсәткән. Ничек итсә иткән, теләгенә ирешкән.

...Бу вакыйгада кемне акларга, кемне гаепләргә? Кеше күңеле карурман дип юкка гына әйтмиләрдер шул. Аны әйләнеп чыгу өчен көннәр-айлар гына түгел, кайчак еллар, хәтта дистә еллар да җитми әле...

Рина Зарипова

АДАШКАН КҮҢЕЛ

Авылда урта мәктәптә укыганда тыйнак иде, җитди иде Әлфия. Җәмәгать эшләрендә актив катнашты. Укуда арттта калучы классташларына физика, химия буенча ярдәм итте. Әти-әнисе укытучы булгач, өйдә дә эш җитәрлек иде аңа. Әнисе төнге 12 ләргә чаклы дәфтәр тикшереп утырганда, ул аның янәшәсендә дәрес хәзерләде.

Вузга да алтын медаль белән килде ул.

Бердәнбер кызларының канатланып төп оядан очуын Әлфиянең әти-әнисе авыр кичерде. Җитмәсә, студент кызлары, алар күңеленә шом салып, колхозга бәрәңге алырга барган җиреннән салкын тидереп кайтты. Терелгәч, аны Казанга икәүләп алып килделәр. Тулай торакка урнаштырдылар. Авырудан соң бераз ябыга төшкән Әлфиягә уч тутырып акчасын биреп, ашау-эчүдән акчасын кысмаска киңәш иттеләр.

Вуз тормышының беренче айларында Әлфия, урта мәктәптәгечә, бөтен күңелен укуга бирде. Кышкы сессиядә бөтен зачёт-имтиханнарын да «яхшы» билгеләренә тапшырып авылына кайтты.

Озак күрми торгангамы, әнисенә Әлфия бик тә ябыккан, бик тә арыган кебек тоелды. Үзләре җибәреп торган акчаларын җыеп баруын, аны өйләренә кире алып кайтуын да белгәч, ана сабырлыгын бөтенләй җуйды. Кызын ачуланырга ук тотынды:

— Ачлы-туклы килеш башыңны бәрә-бәрә укып сәламәтлегеңне бетерсәң, синең дипломың кемгә кирәк булыр соң...

Каникулдан киткәндә, Әлфиягә акчаны төргәге белән тоттырдылар. Үзләре студент чакта хуш исле аш-су исенә кызыгып кына китә торган татар ашханәсенә йөрергә куштылар.

Бу юлы Әлфия алар сүзен тыңлады. Лекция димәде, семинар димәде — көнгә ике тапкыр ашханәгә юнәлде. Акрынлап аның икенче катындагы ресторанга күтәрелә башлады. Әнә шунда электр гитарасы кылларын оста тибрәндергән «тәти» егет аның күңелен кузгатты да инде. Егет кичке сәгатьләрдә еш күренә башлаган оялчан кунагын ишектән үк каш сикертеп сәламләп каршы алырга күнекте. Моны сизгән кыз баштарак озын керфекләрен күтәреп карарга кыймый иде. Ә беркөнне ул кергәндә буш урыннар оркестр мәйданчыгы каршында гына калган. Нишләсен, барып утырды Әлфия колак тондыргыч музы-

ка шавы астына. Сызылып киткән кара мыеклы гитарачы исә шуны гына көткән икән. Үзләре уйнаган дәртле көйгә «селкенә-селкенә» залга төште. Гитарасыннан сузылган электр чыбыгын җай гына җилкәсенә ташлап, Әлфия янына атлады.

Үз хисләрен сиздерүдән коты очкан кызның битләренә ут йөгерде...

Икенче көнне Әлфия теге «тәти» егет белән «Маяк» ресторанына китте. Алар амсамбле анда да чыгыш ясый икән.

Әлбәттә, ресторанда йөри башлагач, кызның укуга күңеле көннән-көн сүрелде.

Алдагы семестрда инде Әлфия әллә ни укып җәфаланмады. Шулай да табигый зирәклеге, урта мәктәптә чагында тамырланган фикер тирәнлеге аңа имтихан-зачетларын «түгәрәкләп» чыгарга ярдәм итте. Айлар буена кулына дәреслек алмаган, лекцияләрдә (йөргән кадәресендә) бөтенләй башка уйларга-хыялларга бирелеп утырган студент өчен ул зур «җиңү» булды, әлбәттә. Шуңа күрә дә группадашлары аның укуга карашына игътибар итмәделәр. Бу яктан аларны гаепләргә дә иртәрәк иде әле. Чөнки үзләренең дә сагыну-сагышлар катыш студент тормышына күнегеп, бер-берсенә ияләшеп кенә килгән чаклары иде бит.

Әлфиянең бөтен кайгысы соңгы мода белән тегелгән кием эзләүгә күчте. Ул инде акчаны әти-әнисе белеп җибәргәнне көтми, үзе соратып ала башлады.

Әмма педагог әти белән әни моңа игътибар итмәделәр. Кызлары янына килгәч тә аның ничек укуы белән дә кызыксынмадылар алар. Кашын-күзен буяган, чегән күлмәгедәй бөрмәле итәгенә урала-абына атлаучы кызларына ияреп «иң шәп» ресторганнарда ашадылар да кайтып киттеләр. Юл буе хәзерге яшьләрнең уку-яшәү рәвешен үз чорлары белән чагыштырып хәтерләрен яңарттылар. Әмма алар күз алларына баскан хәтер белән хәтәрнең аермасын күрмәделәр, аңламадылар.

Әлфиянең еш кына исереп кайтуына бүлмәдәш кызлары шаһит иде. Алар аңа берничә мәртәбә акыллы киңәшләрен биреп карадылар. Тик типтереп яшәргә күнеккән студент кызга алар сүзе стенага бәргән борчак кебек кенә тәэсир итте. Кимсетүләргә әверелеп, кызларның үзләренә кире чәчрәде ул.

Җәйге хезмәт чирегә җиткәч тә, иптәшләре белән эшкә китми, авылына кайтты Әлфия. Юк-бар авыруын күпертеп ыңгырашты. Бердәнбер кызларын сагынудан гаҗиз

булган ата-ана аны үз яннарында ял иттерү чарасын күрделәр.

Әйе, моны педагоглар эшләде. Гомерләренең 20 елын балаларга белем, тәрбия бирүгә багышлаган, күпме «авыр» үсмерләрне аякка бастырырга ярдәм иткән укытучылар әнә шулай үз кызларын язмыш сукмагында адаштырдылар. Әлфиянең каникулы чәч, тырнак буяудан, кояшта кызынудан гыйбарәт иде. Аның хыялый дөньясы җилбәзәк тормышка омтылды.

Вузларда яңа уку елы башланды. Аудиторияләр курсташларның күңелле гөрелтесенә күмелде. Сүз җәйге хезмәт, яңа дуслар турында куерды. Ә Әлфиянең алар белән уртак сүзе юк. Ул тәрәзәгә баккан. Шәһәр панорамасын күзәтә. Куе яшеллек арасыннан күккә үрелгән мәһабәт йортларны эзли. Күңеле белән аларга урнашкан рестораннарга кереп югала... Ул бу елны Казанга тагын уч тулы акча белән килде.

Мин Әлфияне университет каршындагы мәйданда очраттым. Кыяфәте нәкъ авылдаш кызлары сөйләгәнчә: джинс чалбардан, итәге-җиңе бер җөйгә тоташкан ялтыравыклы блузкадан. Эскәмия читендә «заграничный» сигарет тартып утыра. Шулай да бу очрашудан миндә, Әлфиянең сабый чакта тамырланган тыйнаклыгы югалып бетмәгән икән әле, дигән фикер калды. Ул үзен күпме генә бәйсез тотарга тырышса да, кыенсынуы, тартынуы сизелеп тора. Сорауларга җавап биргәндә тавышы калтыранып чыга. Сүз иярә сүз чыгып, айга уртача күпме акча тотуы турында соргач, «нигә болай җентекләп төпченәсез соң әле» дигәндәй, күзләрен тутырып, миңа сораулы караш ташлады. Җавабын керфекләрен аска төшереп кайтарды: «Аны кем санаган инде»...

Билгеле, үзе эшләп алмагач, ник санасын ул аны. Ә бит аның курсташлары бүген җәй көне эшләп алган хезмәт хакларына күңелләренә ошаган кием эзлиләр. Әле аның да артык кыйммәтлесенә үрелмичә, эти-әниләренә, якын туганнарына истәлекле бүләк-күчтәнәчләргә өлеш калдыралар. Әлфия моны: «Минем эти-әнием ул көнгә калмаган әле һәм калырга да язмасын»,— дип кенә аңлата.

Әлфия белән сөйләшүдә аның укуын дәвам иттерергә теләмәве аңлашылды. «Мин бу вузга яраткан һөнәремне эзләп килмәдем. Әниләр югары уку йортына керергә кушканга гына кердем. Монда шул башыңны бәрә-бәрә укып (болар аның әнисенең сүзләре), яшьлегеңнең рәхәтен күрми каласың, кияүгә чыкмыйча картаясың. Ә минем чәчәк

кебек чагымны таш капчыкта үткәрәсем килми һәм минем беркемнең дә тикшереп йөрергә хакы юктыр дип беләм»,— дип дорфа гына җавап бирде дә торып китеп барды. Чыннан да, чәчәк түтәлләре арасында шатлык таратып гөрләшкән студентлар янында Әлфиянең үз урыны, үз тиңнәре, якын дуслары юк иде шул.

Ул шушы китүдән бирегә әйләнеп килмәгән. Хәтта документларын да алмаган. Бер ай чамасы югалып торганнан соң, тулай торактан киемнәрен һәм үзенә юлланган хатларны килеп алган. Бүлмәдәшләренә «кияүгә чыктым, эшкә урнаштым» дигән. Бәлки, болар хактыр да, әмма озакка булырмы икән инде Әлфиянең бу мавыгулары? Әлегә ышануы кыен, ә күңел бу кызның кабат адашмавын, бәхетле булуын тели.

Язилә Абдулкадыйрова

КҮК КАПУСЫ ЯБЫЛСА...

Иртәнге сәгать өчләрдә үк ут алына торган кечкенә генә бу өйнең тәрәзәләре дөм караңгы. Күрше-тирәсе, авылдашлары моның серен яхшы беләләр: димәк, кечә хуҗа хатын артыграк «сыйланып» алган, ә бүген ул авырып урыныннан кузгала алмыйча ята. Андый чакларда аның малларын бүтәннәр карап тора.

Бәләкәй генә гәүдәле, үз яшеннән шактый олы күренүче Тәнзилә Гыймазиева ферма исе сеңгән, терлек арасында йөреп пычранган эш киемнәрен кигәч, тагын да картаеп, ямьсезләнеп кала сыман. Яргаланып кытыршыланган кулларының кайчандыр җыйнак кына хатын-кыз куллары булуына ышанасы да килми. Акча таба торган, иртәдән кичкә кадәр кирәк, сәнәк сабын тотудан сөялләнеп, сизү сәләтен югалткан тупас куллар болар. Алар хәтта нәфис рюмкаларны да тота белмиләр. Ә кырлы стакан тотарга әллә ни осталык кирәкми. Шуңа күрә: «Ник хатын-кыз гүзәллеген сакламадың, ана, дәү әни исеменә тап төшереп аракыга үреләсең, ник үз-үзеңне кадерсезлисең, үз теләгең белән упкынга барасың?» — дип битәрләргә дә тел әйләнми аны.

«Коммунист, депутат, хезмәт ветераны — ә үзен ат белән килеп алалар, китереп куялар. Басып торырлык та хәле булмаган кешедән нинди хезмәт көтәсең?» Тукай

исемендәге колхоз бозау караучысы Т. Гыймазиева турында язылган хатта шундый юллар бар.

...Ник килүемне белгәч, тыныч кына сүзен дә әйтә алмады, илереп, җан ачысы белән еларга тотынды Тәнзилә. «Кемгә нинди начарлыгым тиде икән? Ник минем авырткан җиремә кагылып йөрәгемне телгәлиләр? Болай да бер бәхеткәйләрем булмады...»

Берәүләр рәхәткә чыдый алмаганга, байлык-муллыкны кая куярга белмәгәнгә эчсә, икенчеләр гомер буе михнәт кичереп, тормышта үз бәхетен тапмаганга аракыдан үзенә юаныч таба. Ә Тәнзилә...

Сабый чагыннан ук терлек-туар арасында кайнашып үссә дә, фермада эшләп гарипләнгән, йөри алмаслык булып аяксыз калган әнисенең язмышын кабатларга хыялланмагандыр ул, мөгаен. Шулай да аның эзеннән киткән. Ялгыз авыру анасына азмы-күпме булышу нияте белән фермага килгән. Бала чагында ук әтисез, ярты канат астында кимсенеп-кыерсытылып үскән Тәнзиләне яшьлегендә үк бәхетсезлек көтеп торган икән. Нибары ике атна яшәп калган иреннән аерылгач, нарасыен үз анасы кебек ялгызлыкта тәрбияләп үстерергә туры килә аңа. Әнә шул кадерлеләре хакына яңадан гаилә кора алмавы яшь хатынны упкын читенә илткән сукмакларның берседер, күрәсең.

— Туганнан бирле авыр тормышта интегеп яшәгәнгә күрә эчәргә өйрәнгәнмендер инде,— ди Тәнзилә.— 27 яшь иде миңа ул чакта... Соңгы елларда арурак эчелде шул...

Тәнзиләнең шушы сүзләрендә үткәндәге тормышның бөтен аһ-зары, үкенечләре, кайгы-хәсрәтләре яшеренгән. Хәер, монда болай да муеннан михнәткә чумган, тормыш ачысы иңгән ялгыз хатынның берүзен генә гаепләп калдыру һич дөрес түгел, минемчә. Кешенең язмышы тулаем бәхетсезлекләрдән генә тормый бит. Хезмәт кешесе буларак аның кадере бармы? Еллар дәвамында (ул баштагы уналты елында сарыклар, соңгы унбер елда бозаулар караган) һәрвакыт әнисе шикелле алдынгылар сафыннан төшмичә, кыйммәтле бүләкләр, Мактау грамоталары белән бүләкләнүен яисә акчалата премияләр алуын андыйларга карата күрсәтелгән олы бәя диярләр, әлбәттә. Һичшиксез, монда дөреслек бар. Ай саен икешәр-өчәр йөз сум хезмәт хакы яки планнан тыш үсеш алган өчен өстәмә түләү алуын да күпсенәләрдер диясем килми. Бил бөккән, тир түккән кешенең хәләл эшләп алганыннан күпсенү аркасында югалтты бит инде җәмгыять үзенең чын хуҗаларын. Әле һаман да арына алганыбыз юк бу канга сеңгән чир-

дән. Күп вакыт хезмәт кешесенең, производство алдынгысының җиңүләре, уңышлары нәрсә бәрабәренә ирешелгәнне онытабыз. Аннары тәүфыйксыз балаларга, азгын хатыннарга, «ычкынган» ирләргә, кыскасы, җимерелгән гаиләләргә карап аптырыйбыз.

Тәнзилә Гыймазиева яшәгән унбиш хуҗалыктан торган Җикән-Күл авылын гына алыйк. Ул колхоз үзәгеннән ерак түгел, нибары бер чакрым читтәрәк булса булыр. Җикән-Күлнең хезмәткә яраклы кешеләре (биредә алар утызлап исәпләнә) һәр көнен күрше Дөреш авылына эшкә ашыгалар. Күз ачкысыз карлы буранда көрт ярып, юл салып баралар, язгы-көзге пычракларда итек балтырына кererлек баткаклыктан чупыр-чупыр үтәләр. Менә шул араны көненә ничә мәртәбә урарга туры килә аларга?! Кыш көннәрендә чана, яз-көз көннәрендә арба җиккән атларга гына юл бар. Тәнзилә дә бер караңгыдан икенчесенә кадәр көннәр буе аякларыннан резин итеген, өстеннән каешка әйләнгән фуфайкасын-халатын салмыйча эшли. Фермадагы авыр хезмәте аның терлекчелек вазифасына гына керә. Ул малларны ашатырга-эчертергә, асларын чистартырга һәм югары үсеш алырга тиеш. Аның өчен хезмәт хакын түлиләр, бүләген тапшыралар, җылы сүз әйтәләр... Ә бит кеше эшләр өчен генә яшәми, яшәр өчен эшли. Ул эшнең хәтта ялы-отпускысы да юк. Оек балтырына җыеп баргач, ишеп акча алуның нигә кирәге бар? Чөнки авылда алыйм дисәң, юньле әйберсе юк, булган яхшы киеменең киеп барыр җире юк.

Терлекче Тәнзилә Гыймазиеваның өенә, баш бәрелмәсен дип иелеп керергә кирәк. Бардыр, менә дигән ташпулат салдырып куярлык акчасы да бардыр. Ләкин ялгыз хатынның көченнән килә торган эшмени йорт җиткерү. Аның өчен ягарга утынын, утырып чәй эчәр өчен, затлы ук булмаса да урындык-өстәлен, караватын-шкафын юнәтергә кирәк. Аларны кайтару өчен көн-төн фермасыннан бушый алмаучы терлекче шәһәр юлын таптый аламы? Җитмәсә, ишегалды тулы күзгә карап торучы мал-туары... Егерме-утызар баш сарыкны, сыер-бозау, кош-кортны да шул япа-ялгыз хатын карап үстерә, ай саен 200—300 әр литр сөтен, җитештергән итен колхозга сатып бирә. Ә аны авылдашлары исеменнән кемдер берәү эчкечелектә гаепләп дөньяга фаш итмәкче була. Бу урында тукталып, шунысын да әйтергә кирәк: авыл кешеләре Тәнзилә Гыймазиеваның вакыт-вакыт аракы сөременә бирелеп, «ычкынып» алуына чын күңелдән борчылалар, аның тормышта күргәннәрен сөйләгәндә, кайберәүләрнең хәтта күзләре яшь-

ләнә. Тик аларның ярдәме үгет-нәсихәттән, җылы сүздән ары китми. Монда гаеп «эчкән вакытларда ат белән килеп алучы һәм китереп куючы», алдынгы хезмәте өчен мактап трибуналардан сөйләүче, «дөнья болай да рәнҗеткән инде, ник аны бимзаларга» дип битарафлык күрсәтүче, кешене эчкечелеккә илтүче юлларның иң нечкә, иң тирәндәге тамырларын эзләп интекмәүче хуҗаларда түгел микән?

— Дүртенче ел эшләү дәверемдә эчкечелек өчен гаиләләре белән авылдан куган очраклар булды хәтта. Бу бәхетсез хатынны куып кая җибәрәсең инде?..— ди авыл Советы башкарма комитеты председателе.

Әйе, кимчелеге булган һәрбер бәндәне каядыр сөреп җибәреп кенә тормыш гариплекләреннән котылып булса икән ул?! Бик ансат юлны сайлыйбыз түгелме?! Ни өчен ул чагында власть вәкиленең көчсезләргә генә көче җитә. Югыйсә авылда «яшел елан» белән дуслашкан урта буын җитәкчеләрне дә беләләр бит. Аларның кайдадыр тәрәккыйлаучылары булган өчен генә күрмәмешкә салышабыз түгелме?

Егерме ике яшендә кулына партия билеты алып, коммунистлар белән бер сафта тормышны алга җибәрү өчен көрәшергә сүз биргән Тәнзилә Гыймазиева бүген «җәмгыять чире»ннән ничек котылырга тиеш?

...Авыл уртасындагы ярым көрт баскан кечкенә өйнең тәрәзәләрендә һәркөнне иң ахырдан ут сүнә. Тәнзиләгә бүген өч-дүрт сәгать кенә йоклыйсы. Кешеләр уянганда ул инде буран күмгән юлда тирән эз калдырып Дөрешкә таба, бозаулары янына юнәлгән була. Эшкә бара алмаслык көннәрдән кала, һәркөнне шулай...

Элфия Саматова

ЙӨРӘК ТАШ ТҮГЕЛ

Капкадан кергәнен күрүгә үк сөймәс булды Хәтирә киленен. «И ходаем, минем әзмәвердәй малаем янында суга төшкән чебеш кенә ич бу нәмәстә»,— дип, бөтенләй кәефе кырылды. Улы: «Өйләндем, шушы ялда ук сезгә кайтып киләбез»,— дип язгач, и хыялланды, и хыялланды Хәтирә. Имеш, улы белән килене хәтәр шәп киенеп урамнан узалар. Киленнең чибәрлегенә бөтен кеше шаккатып кала. «Юкка гына утызга җиткәнче йөрмәгән икән

шул Гаптери малае, мондый чибәр хатын табасыңны белсәң, кырыкка хәтле дә көтәргә риза булырсың»,— дип, ирләр дә авыз ерып хатыннарына сөйләнәләр, имеш...

«И-и, әзерләнгән булам тагы шушы җук нәмәстә өчен»,— дип, Хәтирә кулындагы чәшке тастымалын ачу белән мич каршындагы сәке чатына атты да, яхшысынмады, улы белән килене каршына чыкты. Яшьләргә бәхетле тормыш, җылы теләкләр теләп маташмады: «Җәһәннәмнән эзләп тапкан алтының шушымыни инде, улым?» — дип, улы белән күрешергә кулын сузды...

Менә шулай каршылаганнар иде Нәзиләне бу йортта. Хәзер ул аларны онытып та килә инде. Чөнки бу йортка аны ире бик сирәк алып кайтты. Әбисе белән бабасы оныкларын сагынганда гына бергәләп кайттылар, чөнки бала бәләкәй, әнисеннән башка алып кайтып булмый иде.

Ә Рамазан үзе еш була иде өйләрендә. Килгәндә гел исерек була, өенә керә-керешкә үк Нәзиләгә кычкыра башлый: «Нәрсә авызыңны салдың? Кем соң син мине шулай күбенеп каршыларга? Кайтып кергән җиремә идән җәймәсе булып ятасы кеше син...» Китә тезеп, Нәзилә башта, китереп суга күрмәсен дип, куркудан калтырый башлый, әкренләп куркуы кача, аңсыз ташка әйләнә, башы берни уйламас, колагы ишетмәс була. Моны күреп, Рамазан гайрәтләнгәннән-гайрәтләнә: «Кемгә килеп тап булдым мин, катык сөртеп ташласаң, эт җаламас, шуның белән торам бит. Бетмисең дә ичмасам»,— дип, өстенә кизәнә, тик Нәзилә аның сукканын сизми, күзләре киерелеп ачылган, йөзе агарган хәлдә тик карап тора. Каршы да дәшә алмый, урыныннан да кузгала алмый. Әйтерсең табаннары идәнгә ябышкан, ут кебек янганнарын гына тоя Нәзилә аларның. Башында бер генә уй: «Бала гына ишетеп уяна күрмәсен, куркыр». Шулай дулый-дулый да, Нәзиләне тукмаклаудан арыган кулын уа-уа, пычрак киеме белән ап-ак урын-җиргә барып ава Рамазан. Һәм биш-ун минут үтми, гырлап йокыга да китә. Шуннан соң гына ире көчле куллары белән китереп суккан сәен почмакка сеңә барган Нәзиләнең ике күзеннән яшь атылып чыга. Ул Нәзиләнең таштай катып киткән бәгырен йомшатырга ашыккан сыман һаман тама да тама.

Хатын урыныннан кузгала. Стенага тотына-тотына улының бүлмәсенә керә, әкрен генә янына ята. Тик меңдәргә башын куюы була, улы ике куллап аның муеныннан кысып кочаклап ала, әнисенең битенә битен куеп җайлап ята. Шушыны күтәрә алмый Нәзилә. Улының өйдәге төнге мәхшәрләрне сизүеннәнме, әллә үзенең кемгәдер

кадерле, кирәкле кеше икәнен тоюданмы, үз-үзен тыя алмый сулкылдап еларга тотына...

Балалар йортында тәрбияләнеп үскән кыз каенанасын үз әниседәй якын итәргә хыялланган иде. Баштарак аның җанын эретергә тырышып үзенә алмаганны, үзе кимәгәнне аңа алып кайтты. Ул йортта үзен чәй эчәргә утыр дип чакыручы да булмагач, җаны суынды, дәшмәс булды.

Ә каенана улы кайткан саен киленгә каршы яңа «алымнарны» өйрәтә тора. «Бала бераз исәйгәнче түз, ди ул, Рамазанны тәмам котыртып җиткергәч.— Аннан аны үзебез карарбыз. Ул нәмәстәңә үз каныбызны әрәм итеп булмый».

Инде менә бу ялга улы гаиләсе белән кайтасын белгәч, Хәтирә килене өчен бөтенләй көтелмәгән «сюрприз» хәзерләде. Кайтып ашап-эчкәч, Нәзилә өстәлне җыйды. Рамазанның да бу юлы кәефе әйбәт иде. Ни дисәң дә, әнисенең Нәзилә белән әйбәт сөйләшкәнен күргәч, ничектер сөенеп, кәефе күтәрелеп китте. Хатынына, улына үзе уйнап, сыер көтеп үскән урман-болыннарны күрсәтеп кайтмакчы булды. Ә инде анда баргач, Рамазанны әйтерсең алыштырып куйдылар. Үзе балачагындагы берсеннән-берсе кызыклы хәлләрне сөйли, үзе әле улын, әле хатынын кочагына алып сөя, күтәреп әйләндерә, куышып уйный, улыннә чәчәкләр җыйдыртып әнисенә китертә...

Рамазан бу көнне Нәзиләнең күзләрендә чын куаныч, шатлык күрде. Көн кичкә авышкач кына кайтырга чыктылар алар. Шаяра-көлешә кайтып килгәннәрен тәрәзәдән күргәч, Хәтирәнең йөзенә тагын сөрем сарды. Оныгының: «Әби-әби, менә сиңа чәйгә салылга каллыган яфлагы алып кайттык»,— дигән сүзләренә дә эремәде. Өйдәге күңелле гөрелтене басарлык тавыш белән: «Өстәл җәймәсе астында 25 лек торадырые, син алмадыңмы, улым?» — дип, Рамазаннан сорады. Тегесе аңа әллә ни әһәмият бирми генә «юк» дигәч, каенананың зәһәрлеге тагын да көчәйде. «Кайда гына булыр икән?» — дип, әйберләрне дөбер-шатыр актарып акчасын эзләргә тотынды. Ишек янында эленеп торган кием-салым кесәләренә дә күчте. Һәм... акчаны Нәзиләнең кайткач ук кадакка элеп куйган плащы кесәсеннән тапты».

— Әстәгыфируллакайгынам,— дип, йөзенә алтын балык тоткандагыдай шатлык чыгарып, бөтен өйне яңгыратты Хатирә.— Улым, хатының бәләкәй генә булса да, кәсебе бик зур икән. Кай арада тыгып куйган?..

Рамазан күгәреп-зәңгәрләнеп усал карашы белән Нәзиләгә текәлде. Ә тегесе улы белән мәшгуль иде. Башта

әйдә нәрсә турында сүз барганын аңламый торды, каенанасы «оятсыз, карак» дип битенә төкергәч кенә бик нык үкенгән кеше сыман кызарды да, башын аска иде. Хәтта улына карарга да кыенсынды. Ул да түгел, ир аның алдындагы баланы йолкып алды да: «Вон!» — дип кычкырды.

Әле моңрачы күпме генә кимсетсәләр дә, җәберләсәләр дә, Нәзиләне болай ачыктан-ачык куучы юк иде. Көтелмәгән әмер булгангамы, коточкыч яланың үз рухын пычратуыннан куркыпмы, әллә баласы күз алдында ире үзенә китереп сугудан качарга теләпме, чыгып йөгерде. Тәмам арып хәлдән тайганчы йөгерде. Күзенә беркем, бер нәрсә күренмәде, аягы җирне тоймады, башына уй килмәде. Хәлсезләнеп аягы атламас булгач, барып җиргә ауды... Шул хәлдә шактый ятты Нәзилә. Тәненә иңгән җир салкыны әкрен генә аны үз хәленә китерә башлады.

Ике-өч сәгать элек кенә Нәзиләнең үткәнендәге болытлы көннәрне таратып канатланган, якты хыяллардан исереп, очынып уйнаган алан иде бу. «Гомеремдә шулай онытылып көлгәнем юк иде менә нәрсәгә булган икән. Гайшә апа әйтә иде шул: «Шашып көлмәгез, — артыннан еларга туры килер», дип. Тәки шулай булды»,— дип уйлап куйды Нәзилә. Фикере шуннан да тирән куера алмады. Бары тик үзенең ул 25 сум акчаны күргәне булмавы һәм ни өчендер ул акчаның үз кесәсеннән табылуына гына гаҗәпләнде. Улы китереп салганмы әллә дисәң, ул да тапкан әйберен иң беренче әнисенә суза иде...

Уянганда инде төн иде. Кап-караңгы. Агач башлары арасыннан йолдызлар җемелдәгәне генә күренә. Нәзилә курыкмый да, уйламый да. Төнге салкыннан калтырап өшү генә борчый аны. Мотор гөрелтесе ишетелгән якка атлады ул. Урман читендә генә бер КамАЗ туктап тора. Нәзилә аның янына килде. Кабина эчендә ике кеше ашап утыра иде. Алардан кая баруларын сорады. Тегеләре: «Сиңа кая кирәк соң?» — дигәч, ни дияргә дә белми аптырап калды. Кабинадагылар башта көлешеп алдылар. Аннан соң, фаралар яктысында бөрешеп баскан кечкенә генә ябык хатынның әле һаман да үзләреннән күзен алмый карап торуын күреп, аптырап калдылар. Берсе, кабинаның ишеген ачып, соравын кабатлады. Хатын тагын дәшмәде, үзе теше-тешкә бәрелеп калтырый икән. Аны кабинага чакырдылар. Ашарга куштылар — ашады, җылынырсың дип, аракы салып бирделәр, тончыга-тончыга булса да эчте. Болар Нәзиләнең хәленә тиз төшенделәр. Үзара больницага илтергә кирәклеге турында сөйләшеп алдылар.

Ә больница шактый ерак иде. Анда барып җиткәндә Нәзилә ут кебек яна иде инде. Болай да бәйләнешсез җөмләләре, аңлашылыр-аңлашылмас сүзләр белән алышынды.

— ...Хәле хәзер әйбәт инде. Температурасы да нормальләште,— диде аны дәвалаган врач.— Тик аның нервларын яхшылап дәвалыйсы бар. Анысына бездә белгечләр юк. Ә республика больницасына үзенең китәсе килми.

— Анда психбольницага салсалар?..

Нәзиләнең күзенә яшь тулды. Кемнән курка, нәрсәдән ояла — аңлашылмый. Үзе: «Нишлим икән?» — дип киңәш сорый. «Хәзергә ирең турында да, улың турында да уйламый, үз саулыгың турында кайгырт»,— дигәч, карашын аска төбәп, сүзсез кала. Аннан, оялып кына: «Ә малаем... Рамазан да бит әнисе аракы эчертеп котыртмаса әйбәт. Өйдә эчми, башка хатыннар белән чуалганы юк» — ди.

«Минә айга якын ятасың, берәр мәртәбә килдеме соң синең янына Рамазаның?» — дигәч, тагын уйга тала. Алай гынамы соң әле, Рамазан белән әнисе шушы саф, керсез күңелгә икенче пычрак ягалар. Имеш, Нәзиләнең, алар куып чыгаргач, ниндидер шофер белән төне буе урманда кәеф-сафа корып йөргәнен күргәннәр. Бу турыда да ишетсә, болай да өзгәләнгән үзәге нишләр икән дип борчылам. Ә бит ишетәчәк. Күпме генә киңәш итсәм дә, ул больницадан чыгуга ире белән улы янына кайтачак (хәер, аның әлегә ачып керерлек башка ишеге дә юк).

Нәрсә көтә бу хатынны — әлегә билгесез. Нәзилә үзе яшь кенә булса да, тормышка чыкканнан бирле күргәннәрен беркемгә сөйләмәгән. Иренең, әнисенең теләсә нинди кимсетүләренә түзеп яшәгән. Ә тегеләре аның сабырлыгыннан, яклаучысы булмаудан явызларча файдаланалар. Гадәттә мондый типлар куркак, түбән җанлы булалар. Шулай да Рамазанның ир булуын, моңарчы анасы сүзеннән башка бер адым да атламыйча яшәвеннән туктап, гаиләсен саклап калуын өмет итә күңел.

Язилә Абдулкадыйрова.

МАТУРЛЫК НИНДИ БУЛА?

..Ул елны яз иртәрәк килде. Көнозын кояш көлә. Инде дөнья яшелләнде, очар кошлар да кайтып, бала чыгарды. Урам һавасы сулап туйгысыз булып сафланды. Күңелләр күтәрелеп, йөгерә-йөгерә эшләп көн узганы да сизелми. Ул арада урамны иңләп төн шәүләсе йөгерә... Тиздән һәр-

кем татлы йокыга талачак. Тик менә бала тудыру йорты гына бу күренешкә буйсынмый. Аның үз законы, үз тәртипләре. Көн һәм төн дигән төшенчәләр биредә бөтенләй юк.

...Альбинаны да бирегә әнә шулай төнлә китерделәр. Аны кабул итеп алган дежур врач, аптырашта калды хәтта. Баласына гомер бирүче бу ана физик кимчелекле, аның терсәгеннән уң кулы юк иде. Хатын еш-еш сулыш ала, әмма авызыннан ник бер сыкрану авазы ишетелсен. Баласы таң алдыннан туды. Таза-сау ир бала тапты ул.

Альбинаны без яткан палатага урнаштырдылар. Бущ җиңен җилпеп алган саен, күңелгә хәвефле уйлар килә: ничек багар ул баласын? Үз авыртуларыбызны онытып, һәркайсыбыз аның күңелен күтәрер өчен тырыша. Берберебезгә ияләшә төшкәч, Альбинаның күңеле ачылып китте: бәхетле елмая үзе, ул үз эченә бикләнүче, боек кеше дә түгел икән.

Баласын ашатырга китергәч, Альбина аеруча җанланып китә. Юкка гына ана матурлыгына иң көчле әсәрләр язылмыйдыр. Бу минутларда ул иң бәхетле кеше иде. Бит алмалары алсуланып, күзләренә кадәр елмая.

Больницада көннәр санаулы. Никадәр игътибар бирсәләр дә, тизрәк үз йортыңны сагына башлыйсың. Без дә кайтыр көннәрне көтә башладык. Альбина да шулай. Аның янына туганнары килеп йөрде. Үзе Казанда яшәми ул, Түбән Камадан кунакка килгән булган. Ә туасы җан көттерми. Иренә шалтыратканнар: тиздән килеп җитәчәк.

Альбинаның ниндидер фаҗигагә юлыгуы барыбызга да билгеле иде. Әмма нинди фаҗигагә тарыган ул? Хатын-кыз психологиясенә барысын да беләсе килү хас. Әмма күңеленә саксыз кагылудан куркабыз. Альбина инде бөтен эшне сул кулы белән эшләргә күнеккән. Шулай да бер көнне су алып килгәндә кулыннан савытын төшереп җибәрде. Бернәрсәсе дә юк монының. Һәркайсыбыз белән була торган хәл. Игътибар да итмәдек. Әмма Альбина сулкылдап ук елап җибәрде, түгелеп-чайпалырга торган күңел дәрьясы ташый иде аның.

Юк, Альбина әкият кызлары кебек матур булмаган. Әмма сөйкемле, озын керфекле, шат күңелле бу кызны Илдар исемле егет яраткан. Бу дуслык, беренче мәхәббәткенә булып калмыйча, олы мәхәббәткә әверелгән. Туй көнен билгеләгәннәр. Тик станциядән кайтканда машиналары капланып, шунда Альбина бик нык җәрәхәтләнгән. Аның янына беренче булып Илдар килеп җиткән, больни-

цага урман чәчәкләре ташыган ул. Әмма кызның хәле җиңеләюгә таба бармаган. Уң кул терсәктән түбән чәрләкләнгән булган. Врачлар уртак фикергә киләләр: бары кулын кисеп кенә гомерен саклап калып булачак. Альбина бер аңына килә, тагын саташа башлый. Һәм операция тәмам...

Кызның йөзендә яшәү гаме юк. Кулыңны югалту, юк, моның белән килешеп булмый, бәргәләнә-бергәләнә елый ул. Җитмәсә, әнә шул аяныч көннәрендә Илдар да аның янына килмәс була. Каядыр читкә үк чыгып киткән хәтта. Яратумы, ялгышумы? Һаман да аның исеме белән саташа кыз. Тик иң авыр чагында ташлап китүен башына сыйдыра алмый. Ачы булса да, чын дөресе шул — Альбина ике фаҗига белән берьюлы очраша. Ул үз эченә бикләнә. Көннәр буе ялгызы, бер ноктага карап уйланып утыра. «Акылына зәгыйфьлек килмәсә ярар иде» — дип әнисе шөбһәгә төшә. Вакыт узар, тән ярасы да, җан ярасы да төзәлер. Кызын ул шулай юата.

Чыннан да, алар Түбән Камага күчеп киләләр. Альбина эшчеләр тулай торагына тәрбияче булып урнаша. «Махсус белемең юк», дип тормыйлар, аның күңелен күтәреп, аз гына уңышын да хуплап, зурлап торалар. Эшенә бөтен күңелен бирә. Яралардан азрак арына. Шунда ул олы мәхәббәтенә юлыга. Аны күзләп йөргән төзүче егет Дамир беркөнне «Киногa барыйк»,— дип сүз ката. Дуслык шулай башлана. Гаилә коруларына алты ел икән. Кызлары үсеп килә, инде менә уллары дөньяга килде.

Кыска гына вакыт эчендә дә Альбина безнең бик якын дустыбызга әйләнде. Шунысы гаҗәп: беребез дә ана кызганулы сүз әйтмәдек. Күңелебездә аның өчен никадәр ягымлы сүзләр булса да, юатмадык. Чөнки ул кызгануга мохтаҗ түгел, көчле кеше, тормышның иң авыр сикәлтәләрен узып, сабыйларына гомер биргән, иң изге миссияне үтәгән ана. Дөрес, аңа бөтенесе дә җиңел бирелмидер. Таза-сау кешегә дә тормышта эш-мәшәкать җитеп ашкан. Әмма ул бирешергә җыенмый.

...Кичен бүлмәгә ак халатлы санитарка апа керде. Кулында — затлы чәчәкләр бәйләме. «Кайсыгыз Саттарова?» Альбина баш селекте. «Ирегез бирде. Шундый олы күңелле, әйбәт кеше икән»,— диде.

Альбинаны бездән алдарак чыгардылар. Ул һәркайсыбыз белән бик җылы итеп саубуллашты, гел хәбәрләшеп торырга сүз куештык. Аны озаткач, шундый күңелсезлек биләп алды безне?! Аннары аның белән хушлашу өчен тәрәзәгә капландык. Ире сабыйны кулына алган, Альби-

наның иңнәреннән тоткан, ярый әле, аның эчке матурлыгын аңлаган, тормышта терәк булырлык ир-егет икән. Һәркайсыбыз шуңа сөенә иде бу минутта.

Альбина безнең тәрәзәгә карап башын какты, тагын бер саубуллашуы иде аның. Бу минутта ул — бәхетнең нәкъ үзәгендә басып тора иде. Аның көткән гаиләсе — җылы учагына кайтып барышы.

Алсу Бикбаева

ТӘҮБӘ

Гөлнарның больницадан чыкканына ай булды. Әмма хәле алга бармый. Саф һавага сусап палатада ятуга караганда, өйдә яхшырак булыр, тизрәк сихәтләнермен дип чыккан иде югыйсә. Хәлен белергә килүче дә юк. Көнозын, бүлмәсен төреп алган затлы келәмнәргә, шкафында җемелдәшкән бәллүр савытларга карап ята, узган яшьлеген, яшьнәп үткән көннәрен уйлап уфтана. Җитмәсә, үчекләгәндәй төшенә дә яшь чаклары керә. Менә бүген тагын балачак дусты Фәүзияне күрде...

Нинди дуслар, сердәшләр иде бит алар. Укырга кергәнче, берсеннән-берсе төнгә дә аерылмыйча, әле берсендә, әле икенчесендә кунып калалар иде. Аннан соң ун ел буе бер парта артында утырдылар. Берсенең матурлыгы, чаялыгы, икенчесенең ягымлылыгы, сабырлыгы аларны үзара тулыландыра сыман иде.

Казандагы финанс-экономика институтына да укырга бергә керделәр дуслар. Әмма, беренче каникулга кайткач ук, Фәүзия кияүгә чыкты. Гөлнар ахирәте белән аерылышуны авыр кичерде. Авылга кайтуга, Фәүзияләргә йөгерде. Авыраеп, битләре тапланып киткән дустын күргәч, кызгана да, соклана да иде.

Фәүзия, баласын тапкач, өзлегеп китте. Гөлнарның каникул вакыты иде. Шундый чакта дустыңа ничек ярдәм кулы сузмыйсың?

Сәламәтлеккә туя алмаган хатыныннан Заһирның күңеле тиз бизде. Аны Фәүзиянең ахирәте кызыктыра иде. Башта уйнап, аннан чынлап шаярулары җитдиләнеп китте. Моны сизгән Фәүзиянең Гөлнарга күңеле рәнҗеде. Баштарак: «Ялгышамдыр, үтәр әле»,— дип үзен тынычландырырга тырышты. Ләкин, көннәр үткән саен, өйдә үзенең артык кешегә әйләнә баруын ныграк тойды Фәү-

зия. Тулып ташыган күңелен бушатырга, киңәшергә дип, Гөлнарның әнисе Шәфика апа янына килде.

Шәфика апа кызын яшьли ялгыз калып үстерде. Ире күрше авылда икенче оя корды. Әмма Шәфика гомере буе аңа тугрылыгын югалтмады. Ә бит анын, күңелендә ут уйнатып, иренең ике күзен дүрт итәргә уйлаган чаклары аз булмады. Әмма үзенә күз аткан ир-атның кайсын гына уйласа да, иң беренче аның нарасыйларын кочаклап тол калырга тиешле хатынын күз алдына китерде. Алар күз яшеннән курыкты. Менә бүген бердәнбер кызы Гөлнар турында хәвефле хәбәр ишетү ана күңелен көйдереп алды, бермәлгә зиһенен томалап торды. Игезәк туганнар сыман үскән дустының ашына кара таракан булып төшкән бит, дип өзгәләнде ул. Шулай да, Фәүзиянең ялгышуына өмет тотып, аны юатып озатты. Шул ук көнне Гөлнарына җайлап кына аңлатып хат язды.

...Фәүзиянең ирен тартып алып озак тотмады Гөлнар. Аннан аерылыр-аерылмас ук хәрби кешегә кияүгә чыкты. Аның белән авылдашларын шаккатырып килергә дип кайткач, Фәүзияне очратты.

— Бик үрсәләнгән, карганган идең, әнә, иреңне бушаттым, үзеңә булсын! — диде дә китеп барды.

Әйе, Шәфика апаның матурлыгы, чаялыгы тулысы белән кызына да күчкән. Әмма моңысы инде анасы рәнҗешеннән дә, кеше каргышыннан да курыкмый. Типтерепметиптереп яши бирә.

— И бала, бала, бу кыланышларың бер заман аягыңа тышау булып уралыр бит. Ичмасам, бер бала да тапмыйсың, аңлар идең аналар хәсрәтен, балалар ятимлеген...— дип үгетләп тә, ачуланып та карады Шәфика апа кызын. Тик файдасызга. Ахыр чиктә түзмәде, Гөлнар хәл белергә кайтып (бу юлы ул өченче ире белән яши иде инде): «Синең кебек, кеше сүзеннән куркып, мин дә ялгыз картайыйммыни?..» — дип сүз башлагач, Шәфика апа аны кырт кисте:

— Гомерем күп калмады, исән чакта күңелемә төелгән төенне чишеп калыйм: син әйткәнчә, кеше сүзеннән куркып картаймыйм мин, ялгышма. Әтиең безне ташлап киткәч, аны сагынып үрсәләнүләрең күз алдымнан әле дә китми... Ә син, ятимлек сагышын тоеп үскән минем кызым, үз дустыңның баласын ятим иттең. Фәүзия хәзер әнә ирен дә гафу итә алмый, башкага да чыкмый. Ә бу ирнең дүрт баласы сиңа рәхмәт укыйдыр дисеңме?..

Үзеннән 25 яшькә олы иде Гөлнарның бу ире. Ул, хатыны белән мал бүлешеп тормыйча, «Москвич»ын һәм

саклык кенәгәсен генә алды да, яшь хатынын утыртып, аның туган ягына — Казанга юл тотты. Кесә калын иде шул. Яңа кавышкан бу парга гаилә, балалар авызыннан өзеп җыелган акчалар квартира җайларга да, аны заманча җиһазларга да җитте. Әмма, гадәттәгечә, Гөлнарны бу тормыш та тиз туйдырды.

Дәрәҗәле генә җитәкченең кабул итү бүлмәсеннән урын алды ул. Яңа эшли башлаган чибәр ханымга, әлбәттә, монда игътибар зур иде. Аңа тагын ире «комачаулый» башлады. Куып-куып та китмәгәч, нахак яла ягып, аны эшеннән чыгартты...

Башка кияүгә чыгып тормады Гөлнар. Хәер, аңа хәйләкәр елмаючы, ялгыз очраганда биленә кул салучы, җае чыкканда, затлы дефицит бүләкләр кыстырып килеп, өендә чәй эчеп китүчеләр күп булса да, өйләнергә теләп тәкъдим ясаучылар бүтән булмады. Әнисе исән чакта бәйрәм саен бәйләм-бәйләп бүләк төяп, сөяркәләре «Волга»сына утырып кына авылына кайта иде Гөлнар. Әнисе үлеп киткәч, мондый бәйрәмнәрдә ялгызлык үзен сиздерсә дә, канәгать иде әле ул мондый тормыштан. Шәһәр үзәгеннән яңа квартира алды. Аны менә дигән итеп ремонтлатты, җиһазлауны да оештыручылар табылды. Чыннан да, Гөлнар өчен шуннан да рәхәт тормыш юк иде. Ир кайгысы, бала-чага мәшәкате юк. Бөтен дөньясы җитеш. Эше җаваплы түгел. Алай гынамы соң? Үз-үзен көйләп, кайгыхәсрәтсез яшәп, матурлана гына барды.

Каян чыккандыр, бу юлы чираттагы ялын Гөлнар туганнарында гына уздырырга уйлады. Бик күп күчтәнәчләр, әнисе каберен әйләндергән рәшәткәләрне буярга буяу алып, «Волга» машинасы белән тагын туган авылына илттерде. Әнисенең энесендә чәй эчеп урамга чыкканчы, Гөлнар алып кайткан күчтәнәчләр бөтен авылны хәйран калдырган иде инде. Аның турында төрле сүзләр йөрсә дә, хәтәр дә затлы киенгән бу сөйкемле ханым белән очрашып күрешкәч, олысында да, кечесендә дә аңа карата соклану хисе уянды. Гөлнар икенче көнне үк абыйсының малае белән зиратка китте. Әмма бәла аяк астыннан чыга бит ул. Эшне бетереп, өйгә ашыкканда, мотоцикл көпчәге ташка бәрелеп, алар икесе дә әллә кая очып барып төштеләр... Шунда Гөлнарның умыртка сөяге сына.

Янына килеп хәлен белмәсәләр дә, элеккеге «дуслары» аны дәвалау өчен барысын да эшлиләр. Озак вакытлар больницада ятса да Гөлнарның хәле алга таба түгел әле...

Куршеләре ипи-сөт кайтара. Туганнары да килә килүен, ләкин һәркайсының үз тормышы, үз мәшәкатьләре, берәз торалар да китеп баралар. Гөлнар тагын шушы затлы келәм белән төрелгән дүрт стена эчендә кала. Каяндыр күңеленә Тукайның: «Бер иптәш тә юк, ичмаса, тик икәү без — уй да мин»,— дигән сүзләре килә. Баштарак, авыруының җитдилеген аңлаганчы, терелеп элеккеге тормышына кайтырга өмете зур иде Гөлнарның. Янына килмәгән, хәлен белмәгән өчен «дусларына» үпкә сүзләре дә әзерләнде.

Бүген инде ул үз-үзен карый алырлык булып терелә алуын гына тели. Моның өчен ул өендәге шушы бөтен затлы әйберләрен, киемнәрен биреп бетерер иде. Әнисе белән гомер иткән өенә кайтып, Фәүзия белән элеккечә дус булып, серләшеп яшәр иде Гөлнар. Тик бу хәзер бары тик хыял гына. Һәм мәңге тормышка ашмас хыял.

...Күптән түгел Гөлнарның, авырганын ишетеп, хәлен белергә бардым. Һәм шунда мин аның, мәхәббәт алдында көчсез, балалары хакына барысын да гафу итәргә сәләтле икенче берәүнең бәхетен урлап, кая басканын, нәрсә сөйләгәнен белми яшәгән шатлыклы көннәрен бүгенге халәте белән чагыштырдым. Әйе, ул инде, бөтенләй өметсезлеккә бирелеп, яшәвенең мәгънәсен югалтып бара. Аның назлап юатучысы да, борчылып кайгыртучысы да юк. Дөресрәге, ул бүген берәүнең дә кадерлесе түгел. Һәм Гөлнар моны бөтен барлыгы белән тоя, аңлый, үткәннәренә үкенеп бетә алмый.

— Начармы-яхшымы, янында ирең булсын икән ул. Их, тормышны яңадан башлап булса икән. Әни сүзләреннән чыкмас идем. Күңелемне иң сызландырганы шул: ахирәт дустым Фәүзия тормышын ботарладым...

Ул да түгел, Гөлнарның фикерләре икенчегә күчә. Япьяшь кызларның намусын таплаучы, киләчәген урлаучы ир-ат халкын сүгә башлый. Үз юлыннан тайпылуында Заһирны гына гаепли. Елап-елап, язмышлар тигезсезлегеннән зарлана.

Аңламады Гөлнар матурлыкны, бәхетне, мәхәббәтне. Матурлыкны күзгедән генә күрде. Бәхетне хәсрәтсез, мәшәкатьсез тормыш итеп күз алдына китерде. Ә мәхәббәтне көн дә яңарткан күлмәкләре белән тиңләде.

Бары тик авыру яктан еккач кына Фәүзиянең язмышын, әнисенең өзгәләнүен һәм тагын үзенә төбәлгән бик күп рәнҗүле карашларны күз алдына китерде. Алар күз яшеннән җыелган упкында сыман хис итте ул үзен. Бу упкыннан аны беркем дә тартып ала алмаган кебек үк,

Гөлнар рәнҗеткән кешеләрен, әнисе әйткәндәй, бәхилләтә дә, алардан гафу үтенә дә алмый. Барысы да әйләнеп кайта алмаслык еракта калган. Гөлнар янәшәсендә фәкать намус хөкеме белән вөҗдан газабы гына бөтерелә. Әнисенең өзелеп әйткән сүзләре, Фәүзиянең хәсрәтләре аның бүгенге көнен искәрткән җитди кисәтү булган икән ләбаса. Әгәр шул вакытта Гөлнар ялгыш адымнан туктап калалган булса, бүген аның янында җылы сүзе, якты карашы белән җанына рух өрүче ире, уллары-кызлары булмас идеме әллә?! Һәм, гомумән, булыр идеме бу фаҗига?

Язилә Абдулкадыйрова

«ГАФУ ИТӘ АЛМЫЙМ»

Сабый чакның бөтен хатирәләре әни исеме белән бәйләнгән була. Әни. Бала өчен аңардан да якын, кадерле, игелекле зат бармыни бу дөньяда! Ул — бетмәс-төкәнмәс наз чишмәсе, бөтен бер дөнья. Аның кочагында гына үзеңне бәхетле тоясың, аның кочагында сиңа бернинди куркыныч янамый. Олы тормышка, олы бәхеткә фатиха әнә шуннан башлана.

Сабый чагында сине шул наздан, шул дөньядан мәхрүм итсәләр, күңелеңдә ни кала? Бары тик бушлык, бернәрсә белән тулыландырып булмый торган бушлык һәм йөрәк ярасы... Бала чакта гына түгел, үсеп җитеп, үзе әни булгач та гафу ителми торган кичерешләре турында Гөләндәмнең сөйләгәннәрен хикәяләп үтәсем килә.

«Бәхетле балачак» дигән сүзләрне ишеткәндә, сеңелем Лилия белән бәхетсез балачагыбыз исемә төшеп, йөрәгем әрни. Без дә бәхетле була алган булыр идек тә бит... кызганычка каршы, әти-әнине сайлап алмыйлар...

Балачагымның күңелгә уелып калган хатирәләре:

Миңа 7 яшьләр чамасы, сеңелем Лилиягә 2 яшь тулмаган. Әти исерек, әнкәйне кыйный. Әнкәй елый, бишектә үзәк өзгеч тавыш белән сеңелем елый. Мин: «Әтием, тимә, тукта, әтием!» — дип, әнкәйне яклашам. Әти, башка әйбер тапмагач, бер кулы белән өстәлдән аш чүмече алып, миңа суга. Бер суга ике, өч... Ә мин китмим. Иртәгесен әти суккан урыннар күгәреп-күгәреп чыга...

Ә яз кояшы караган бер җылы матур көндә без әтидән качтык. Басуга тирес түгәргә килгән машинага утырдык та киттек тә бардык.

Машинадан төшкәч, эти куа килми микән дип куркып, артыбызга борылып карый-карый, йөгерә-атлый җәяү бардык. Әбиемнәр авылына (хәзер «безнең авыл» дибез инде, олы юлдан 5 чакрым) кара кичтә барып кердек.

Шуннан соң үткән ике ел гомер ике сәгатьлек төш кебек кенә тоела. Гел шулай бит ул: бәхетле көннәр тиз уза, ә менә хәсрәтлесе...

Без вакытында туйганчы ашый, тынычланып йоклый башладык. Әнкәй фермада эшләде, әбиебез инде пенсиядә. Тик шатлык озакка бармады, әнкәй турында төрле имешмимешләр йөри башлады. Өйдә тагын киеренкелек урнашты. Әби елый-елый әнкәйгә әкрен генә нидер әйтә, әнкәй аңа тупас итеп җавап кайтара да, ишекне шап итеп ябып, өйдән чыгып ук китә.

Ә көннәрдән беркөнне ул эштән чит бер абыйның атына утырып кайтып керде. Чанада ике толып та бар. Абзый өйгә керде, аның белән бергә аракы, тәмәке катыш ачы ис керде. Ул зур гәүдәсе белән ишекне каплап кереп баскач, өебез тагын да кечерәеп, әбиебез мескенләнеп калган кебек булды. Лилия белән без почмактагы сәкегә елыштык.

Абзый күрше авылдан икән. Күптән түгел хатынын җирләгән, 1 һәм 3 яшьлек ике бала белән тол калган ир булып чыкты. Әнкәйне алмага килгән, килешүен инде алдан ук килешкән булып чыктылар. (Соңыннан белдек: үзе белән бергә эшләүче хатынга әнкәй: «Шушы яшемнән ялгыз яшәмәм бит инде. Балалы иргә бармый, кемгә барыйм, миңа хәзер өйләнмәгән егет килмәс бит»,— дип сөйләгән.)

Әбием тагын елый, әнкәйне үгетли... Китте әнкәй, шул абый чанасына утырды да күздән югалды. Мин, өстемә иске бишмәтемне япкан килеш: «Әнкәем, китмә, әнкәем, ка-а-л»,— дип кычкырып елый-елый, алар киткән якка ташландым. Артымнан сеңелем Лилия иярде...

Өебез авыл башында гына, үр төшәсе дә болын. Шул үрдән аска томырылдык кына. Тавышларыбыз төн караңгылыгын яра... Караңгыда юлны күрмичә, болында җәелеп яткан суга барып кергәнбез. Кар сулары чыга башлаган вакыт иде. Билдән карлы-бозлы суда басып торабыз. Кайсы якка да барыр хәл юк, баскан саен аяк тирәнрәк бата. Ярый әле Лилия арттарак, үр төшкән кебек җитәкләшеп йөгергән булсак, батып та калыр иде.

Шулай бозлы суда әби артыбыздан килеп җиткәнче басып тордык. Өчәүләшеп үкси-үкси, әкрен генә өйгә кайт-

тык. Бишмәт итәкләре бозланып каткан, аякларыбызны көчкә сөйрибез.

Лилия шуннан соң бик каты авырды. Сеңелемнең болай да зәгыйфьрәк организмына җитә калган: аның бөерләре авыртып калды, аяклары сызлый торган булды.

Болай да зәгыйфьрәк дигәнемне аңлатам: әнкәй Лилияне бик авыр тапкан, икесе дә бик авыр хәлдә больницада озак яттылар.

Тагын бер ел чамасы вакыт узгач, әнкәй кунакка кайтты. Тагын көннәр язга авышкач булды бу. Мин инде 4 нче класста укыйм. Лилиягә 5 яшь. Мәктәптән кайтып керсәм, болдырда өр-яңа галошлар ята. Өйдә самавыр чыжлый, өстәл янында плюш жакет кигән әнкәй утыра. Әбием дәшми-тынмый гына учак тирәсендә кайнаша. Ә өстәл артында Лилия утыра. Кулында конфет-прәннек. Күзләре елтырый, йөзе балкыган.

— Исәнме, кызым,— ди әнкәй. Әллә нишләп киттем. Әнкәйне барып кочакларга оялдым, зур ич инде мин, зурлар кебек күрешергә яхшысынмадым, тамагыма төер утырды, тизрәк ишегалдына чыгып киттем. Үземнең эчем поша. Яныма Лилия чыгып басканны сизми дә калганмын.

— Апам,— ди бу.— Әйдә, әнкәйнең галошларын яшерәбез.

— Нигә? — дим.

— Соң, галошын таба алмый да китми, өйдә кала.

— Әбинекен алып кияр дә китеп барыр.

— Тиле,— ди сеңелем көлеп,— әбинеке тишек ич...

Гел шулай гаҗиз калдыра мине сеңелем. Баштарак: «Әнкәй нигә кайтмый?» — дип аптыратты. «Бүтән кайтмый ул»,— дим. «Иртәгә дә кайтмыймы?» — ди. «Юк,— дим.— Кияүгә китте ул». Лилия аңламый: «Әйдә, без дә барыйк. Әнкәйне алып кайтырбыз».

...Әнкәй без йокыдан уянганчы иртүк киткән иде. Бик күңелсез, шыксыз көн иде ул. Кая киткән кичәге кояш? Көн болытлы, ачы җил исә, әллә яңгыр, әллә кар сибәли.

Башка вакытларда да без әнкәйне озатып кала торган булдык. Ул бик сирәк, әллә нигә бер генә кайта, анда да бит әзгә генә: кичтән кайта, иртән-иртүк китә. Яңа ире бик каты холыклы кеше булып чыккан. «Мин сине балаларымны карарга дип алып кайттым, үзеңнекеләр кадерле булгач, үзеңнекеләрне карарга иде» — дип, безнең янга җибәрмәгән дә.

Әни кайткач әллә ничек: үзе рәхәт, сөендерә дә, әллә нигә оялта да — аннан әкренләп читләшүебез булгандыр инде. Иртән ул әкрен генә, саубуллашмый гына чыгып

китмәкче була. Ә без уянабыз, тиз генә сикереп торып, әнкәйгә сарылабыз. «Китмә, әнкәем, без синең бөтен сүзеңне тыңларбыз, бөтен эшне эшләрбез, китмә-ә-ә!» — дип, үзәкләребез өзелеп елыйбыз, әнкәйнең аякларыннан кочаклыйбыз. Ә ул китә. Әкрен генә итәген кулларыбыздан ычкындыра да, артына борылып карамыйча, ашыга-ашыга китә...

Бер кайтуында әби әйтте әнкәйгә:

— Кайт! — диде.— Әле кайтыр юлың бикләнмәгән, балаларыңа кирәк әле син. Ә болай балаларның йөрәкләрен бозып йөрмә. Тулар-тулмас бер тәүлек өчен генә булса, гел кайтма мин үлгәнче,— диде.

Шуннан соң әнкәй бик озак кайтмый торды. Әбинең авыруы көчәйде, ул астма белән җәфалана иде, яз-көзләрне бигрәк авыр кичерә иде. Әнкәй хәсрәте дә бик бетерде үзен. «Ничекләр болай булды бу бала?» — дип, үзалдына да сөйләнеп йөри, күрше апалар да төрттереп-төрттереп куялар. Авылда бөтен нәрсә күз алдында, берни яшереп булмый. Безне дә кызгана иделәр, кимсеткәннәре дә булды. Әнкәй турында җан өшеткеч сүзләр ишетеп куырылып-куырылып китә идек.

Әбием бик нык авырган көннәрне төннәр буе керфек тә какмый чыгам, күрше апаларга: «Төнлә генә үлеп китмәсәм ярар иде, балалар куркырлар»,— дип сөйләгәне исемә төшә, тын да алмый әбинең сулаганын тыңлап ятам. Аннан мендәргә капланып әкрен генә үксим. Мендәргә капланып еларга иртә, бик иртә өйрәндем мин...

Нигә безнең әтиебез дә, әниебез дә шундый булды икән дип баш ватам. Классташларымны уйлыйм: кайсының әтисе дә, әнисе дә әйбәт, тыныч яшиләр, кайсының әтисе холыксыз, ә әниләре балалар дип үлеп тора. Миннән дә бәхетсез кеше дөньяда юктыр кебек тоела. Болай әти-әниле ятим булып яшәгәнче, аларның үлүләре яхшырак дип уйлыйм. Үлделәр дип әйтер идең, ичмасам, бу кадәр хурланмас, кимсенмәс идең.

Хыялланып ятам: имеш, әти дә, әни дә үлгәннәр, суга батучыларны коткарганда... Әй, юк, янгыннан кешеләрне алып чыкканда... Бөтен кеше аларны хөрмәтләп искә ала... Ә төшемдә мин янгын күрәм. Әнкәем ыргып торган утка кереп бара! Агач бүрәнәләр чартлап яна, менә-менә ишелеп төшәргә торалар. Мин елап кычкырам: «Әнкә-ә-ем!»

Шабыр тиргә батып уянып китәм. Әбием кытыршы учлары белән авызымны каплый: «Әкрен, бәбкәм, Лилияне уята күрмә». Ә битемә аның күз яшьләре тама...

Авыр үстек, ятим бала ятим бала инде. Өс-башыбыз да, ашау-эчү яклары да этиле-əниле яшьтəшлəребездəн начаррак булгандыр. Хəер, ач-ялангач булмадык. «Хөкүмəтебезгə рəхмəт» дигəн сүзлəр минем өчен буш аваз гына түгел. Чын күңелдəн əйтəм мин аларны. Беренче класстан бирле мəктəп алып биргəн киемнəр киеп укыдык. Баштарак елга бер килə торган ул вакыйганы бəйрəм көткəн кебек көтеп ала идек. Ə аннан ояла башладык. Сигезенчедə укыганда миңа бик матур зəңгəр җəйге пальто алып бирделəр.

— Кирəкми! — дидем, бүлəк бирергə чакыргач.— Рəхмəт! Мин 8 не бетергəч үзем эшли башлыйм, үзем алырмын. Ə пальтоны берəрсенə бирегез.

Завуч апа берни əйтми көрсенеп башымнан сыйпый, ə үзенең куллары калтырый, башка укытучылар да эндəшми.

Мин шуңа гаҗəплəнəм: ни йөрəге белəн яшəп ятты икəн ул əнкəй анда?! Ничеклəр кайтмый түзде икəн ул?! Газиз балаларыңны ташлап, ничек шулай дөньяңны онытып яшəп була икəн ул?!

Уйлыйм-уйлыйм да исем китə: сау-сəламəт, эшлəсə — эше, ашаса — ашы, торырга үз йорты, кайгыртырга тəрбиялəп үстергəн, хəзер инде үзе ярдəмгə мохтаҗ авыру əнисе, «əнкəй» дип өзелеп торган ике сабые бар килеш, чит бер иргə кол булып яшəргə риза булсын əле! Ир юньле булса бит: «Синекелəр дə яртылаш ятим, минекелəр дə. Шуларны бергəлəп бəхетле итеп үстерик əле!» — диярргə тиеш. Алай дип əйтми икəн, кирəге юк. Нəрсəгə дип, нəрсə бəрабəренə аңа үзеңнең, балаларыңның тормышын корбан итəргə?!

Кайвакыт күңелгə: «Ə əбисез дə калган булсак, нəрсə булыр иде безнең белəн?» — дигəн уй килə. Йөрəгем өшеп китə.

...Сигезне бетергəч тə эшкə кердем. Тырышып эшлəдем, өс-башыбыз да бөтəеп китте, табышыбыз да мулрак булды, кешелəрнең күзлəренə карарга оялмый башладык.

Əнкəй тагын əллə нигə бер генə кайткалый башлады. Без инде елап аңа сарылмыйбыз, без аның белəн сөйлəшмибез, бөтен əңгəмə «əйе» белəн «юк»тан узмый.

Мин фермада ике еллап эшлəгəчтер, əйе, классташларым 10 нчыны бетерəлəр иде, əнкəй аерылып кайтырга булды.

— Бик җəберлилəр,— диде.— Балалар (ике малай) аталарына телəсə ни ялганлап, мине кыйнаттыралар, түзəр хəлем калмады, кайтам,— диде.

Үзе Лилиягə сырпалана. «Моннан ары гел бергə бу-

лырбыз, кызым. Мин сиңа матур бантиклар алып бирермен». Лилия дәшми. Аңа 4 яшь түгел шул инде, ул 4 нче класста укый...

— Юк инде, әнкәй,— дидем.— Кайтма. Бантигың да кирәк түгел...

Бик кимсенеп, күңелемнән әнкәйгә бик рәнҗеп йөргән көннәрем иде. Яратып йөргән егетем бар иде. Шуның энисе сүз белән бөтен авылны тутырды: «Әтисенә карап улын коч, әнисенә карап кызын коч дип сөйлиләр! Шул... кызын алдыртаммы соң! Анасыннан туган баласыдыр әле...» һ. б., һ. б. Дөрес, егетем килде. «Әни сүзенә карама, Гөләндәм. Мин сине яратам, чык миңа кияүгә, берәүдән дә кыерсыттырмам»,— диде. Минем тормышымны шакшы сүзләрдән башлыйсым килмәде, болай да гарык идем инде. Кеше кебек тыныч, матур итеп яшисем килә иде, ә бу гаиләгә барып керсәм, тагын әнкәй белән кимсетерләр дип курыктым.

Тагын бер сәбәбе бар иде әнкәйгә алай кырт кисеп каршы төшүемнең. Аерылып кайтса да, басылып кына яши алмас, тагын сүзгә калып, оятка калып бетәрбез дип уйладым. Бәлки, ялгышканмындыр...

— Ә-ә-ә, тамагыгыз туйдымыни? — диде әнкәй минем сүзләргә каршы. Аннан әбигә ябырылды.

— Син бозасың балаларны! Син! Минем турыда теләсә ни сөйләп, миңа каршы котыртып бетергәнсең...

Лилия 8 не бетергән елны әбиебез үлде. Аны соңгы юлга озатырга дип кайткан әнкәй белән сөйләшмәдек тә, эндәшмәдек тә.

Лилиянең авыруы җитди иде. Ерак туганнарның адресын табып, Казанга киттек. Лилияне больницага салдык, мин заводка эшкә урнаштым. Эшем авыр, аның каравы акчасы әйбәт төшә иде. Туганнарыбыз без килгәнгә сөенмәделәр, билгеле. Мин тулай торакка урнаштым, тик безгә сеңелем белән бергә торырлык урын кирәк иде. Шул вакытта, бәхетебезгә каршы, вахтер әби караучысыз калган бер апа адресын бирде. Ул, үзен карарга риза булсалар, пропискага кертер идем дип әйткән булган.

Шулай итеп, язмыш безне Глафира Сергеевна белән таныштырды. (Мин аны гомерем буе тирән ихтирам белән, мең рәхмәт хисе белән искә алачакмын. Ул моннан ике ел элек дөнья куйды. Әбиебезне юксынган кебек юксынабыз без аны сеңлем белән.) Фронтовик ире сугыш яраларыннан үлеп киткән, балалары булмаган, туганнары юк. Гомере буе балалар укыткан Глафира Сергеевна үзе дә авыру, җитмәсә, елдан-ел күзләре начарая бара.

Лилиянең хәлен белү белән, таягына таянып, үзенең элекке укучыларына, аларның әти-әниләренә чыгып китте. Кайсы врач, кайсы кайдадыр профком председателе... Шулай итеп, никадәр кирәкле дарулар тапты ул сеңлемә. Санаторийларга путевкалар табып бирде. Сеңелемнең хәле яхшырды, әмма врачлар кырт кисеп: «Бала табарга ярамый»,— диделәр.

Ә бервакытны күршегә, туганнарына дип, сөйкемле генә украин егете кайтып төште. Вениамин, Веня. Лилияне ошатты, еш кайта башлады. Бер кайтуында барын да сөйләдем үзенә. Бәйнә-бәйнә, берни дә яшермичә, ни өчен авыруын да, ничек авыруын да. Тын да алмый тыңлап утырган егет, Лилиянең авыруы турында ишеткәч, урыныннан ук сикереп торды: «Соң бит аңа безнең һава, җылы як һавасы, җылы як кояшы кирәк!»

Шулай итеп, Лилиям Лебеденко булды да куйды. Ул вакыйгага да 6 ел узды инде. Лилиянең хәзер ике баласы бар, игезәкләр. Денис белән Динара. Аларга хәзер 1 яшь тулып килә.

Тормыш шулай әкренләп җайланды. Әнкәй генә йөрәкне әрнетә. Ире моннан ике ел элек трактор белән капланып үлде. Балалары әнкәйне куып чыгарганнар. Ул тузып-таушалып килә торган йортыбызга кайтып урнашты. Әбинең каберен карап-хәстәрләп торам, ел саен бер кайтам авылга. Соңгы ике кайтуымда әнкәй өйдә иде.

— Бергә яшик, кызым,— ди.— Без бит ана белән бала. Дөньяда, нинди булса да, анадан якын кеше юк. Анага рәнҗергә ярамый. Мин бит балалар карарга киттем,— ди.

Бермәлгә тынсыз калам. «Ә без...» — диюдән узмыйм. Әнкәйнең аңа да җавабы әзер:

— Алар бит сездән бәләкәйрәк иде,— ди.— Хатын-кызсыз аякка басарлык түгел иде алар,— ди.— Син,— ди,— үзең бала табып карамагач, ана хәлен аңламыйсың.

...Тагын бәгыремә тиде. Гомер буе өй тотып балалар үстерергә хыялландым. Сау-сәламәт, бәхетле, әти-әниле, шат, матур балалар үстерергә. Тормышымның иң авыр минутларында шул уй белән юандым. Юк, бу хыялым да тормышка ашмады. Базарда матур итеп бәйләнгән нәни генә башмаклар күрсәм дә күңелем тула...

Бөтен тормышымны күз алдымнан үткәрәм дә: «Юк, әнкәйне мәңге гафу итә алмыйм»,— дим. Ә аннан күз алдына бөкрәйгән әнкәем килеп баса. Җимерек өебез янында кулына чәйнек тотып басып тора. Күршеләргә суга кереп баруы...

Йөрәгем калтыранып куя... Әле энкәй карт түгел, узган ел гына пенсиягә чыкты. Ә бит гомер көзе киләчәк. Киләчәк.

Үз балаларыннан чит ир кочагын артыграк күргән аналарга әйтәсем килә: «Айныгыз. Бәлки, соң түгелдер әле, кайтыгыз балаларыгыз янына! Гомер көзе кемгә дә килә бит...»

Гөләндәмнең ачынулы авазын сабыйларын үксез калдырырга җөрьәт итүчеләр ишетерләр, һич югында берсе, икесе... булса да аның киңәшенә колак салырлар дип ышанасы килә.

Рина Заринна

МӘХӘББӘТНЕҢ ХАКЫ БАРМЫ?

Рафис белән Рамилгә ятимлек көтмәгәндә, уйламаганда килде. Әтисе дә, әнисе дә исән килеш бит әле, ичмаса. Анысына да түзәр иде малайлар, хурлык җаннарын талый аларның. Барлык малайларны өйләрендә әниләре уятып, җылы ризык ашатып, чип-чиста киендереп мәктәпкә озата. Ә Рафис белән Рамилне... Дөрес, аларның да тамаклары ач, өсләре ялангач түгел. Әбисе хәленнән килгәнчә карарга, тәрбияләргә тырыша. Әмма Халисә әбинең үзенең дә хәзер түрдә генә утырыр чагы. 80 яшен тутырган. Шуның өстенә әле тагын ул сәламәтлеге тәмам югалып бара торган 83 яшьлек карты — Шәйхетдин бабайны карарга тиеш. Инде менә ике оныгы да аның җилкәсенә калды. Җитмәсә, малайларның холык-фигыле үзгәргән чак. Кайчагында иркәләнеп аласылары килә, кайчагында тискәреләнеп, әбиләрен тыңламыйча, кирәкмәгән эш тә эшләп куялар.

Авылның нәкъ урта бер җирендә Шәрәфетдиновлар йорты. Тирәсе җәен яшеллеккә, кышын ак карга күмелә. Өйалды белән бүленгән өйнең бер ягында Халисә әби белән Шәмсетдин бабай, икенчесендә Шәрәфислам белән Фәүзия, аларның уллары торган. Моннан ике ел элек балаларын калдырып, әни кеше — Фәүзия өйдән чыгып киткән. Берсеннән берсе матур, сау-сәламәт ике ул үстереп аякка бастырам дигәндә генә йортын-җирен ташлап китәргә нәрсә, кем мәҗбүр иткән соң аны? Өйдән чыгып киткәндә улларының, иренең ничек яшәүләрен кат-кат күз алдына китергәндер, үзе белән бергә уртак өйнең нурын,

җылысын да алып китәчәген аңлагандыр. Бу адымы турында туган-тумачалары, якыннары, дуслары белән каткат киңәшкәндер. Күңелдә: һәрхәлдә бик рәхәттән чыгып китмәгәндер Фәүзия, дигән уй туа. Үзем Халисә әби белән сөйләшәм, ә үзем (ул килене белән әйбәт торулары, беркайчан да усал итеп телгә кергәннәре дә булмавы турында сөйләгәндә дә) әнә шундый мең сорауга җавап көтәм.

Аннан соң малайлар ягына кердем. Ял алып этиләре дә кайткан чак иде.

— Соңгы 6—7 елда күңеле өйдә булмады. Авылда: «йөри», дигән сүз таралды. Өйдә үзе шулхәтле әйбәт булгач, ышанмадым. Сүз туктамады. Күңелгә шик килә башлады. Алай да Фәүзиягә сиздермәскә тырыштым. Ләкин, яшермим, онытылыр өчен бераз «салгалый» башладым, тик эчкечелеккә бирелүдән курыктым. Шикләнүемне басар өчен бик нык эшкә тотындым...— ди Фәүзиянең элекке ире Шәрәфислам. Шәрәфисламның күңеленнән, теленнән ул минутта хатыны кайтып керсә, барысын да кичереп, аны берсүзсез кабул итәргә, нәкъ элеккечә яшәп китәргә омтылыш сизелә иде. Кече уллары Рафис кына: «Кайтып карасын, кертермен менә! — дип куйды.— Кирәкми ул безгә: әйбере дә, үзе дә. Әнә, кеше аркылы кайсыбызгадыр костюм җибәргән. Нигә үзе китермәгән? Илтеп ыргытырмын әле»,— дип тә өстәде Рафис, өстәлдә яткан бик матур күрән костюмга күрсәтеп. Олы уллары Рамилнең дә йөзе, карашы җитди. Ләкин ул сүзгә сирәк кушыла.

Фәүзиянең килен булып төшкән шушы нигезен ташлап китүенең сәбәбен аңламадым мин бу йортта. Аны биредә беркем дә яманламады, хурламады. Киресенчә, картлар да, ире дә йомшак күңелле, сөйләшергә ачык, ягымлы булуын ике сүзнең берсендә кабатлап тордылар. Әмма йөзләрендә сагыш та, әйтеп-аңлатып булмый торган ниндидер бер рәнҗүле газап та чагылды. Нәрсәнедер әйтеп бетермиләр сыман иде алар миңа.

Шуңа күрә Фәүзиянең үзен күреп сөйләшәсем килде. Кайда торганнарын сорадым, Шәрәфисламнардан ике йорт аша гына, диделәр, әмма анда барырга киңәш итмәделәр... үзен авыл Советына чакырттык.

— Мужигымның эчүенә, көнләшеп талавына түзәрлегем калмады,— дип башлады Фәүзия сүзен. Сорауларыма йомшак тавышы, ягымлы итеп җавап бирүе белән күңелдә үзенә карата кызгану хисе уятты. Аның сүзенә ышанмый мөмкин түгел иде.

— Аерып кына бер кешедән түгел, бөтен кешедән

көнләде. Гел кибеттә эшләдем. Товарга барып, соң кайткан көннәрем дә була иде, һаман тавыш, һаман гауга туйдыргач, бер аерылып киткән идем инде. Олы улым, «кайтыйк», дип елагач, кире килдем.

Минем ничек газапланып яшәгәнне балалар да, әнә, күршеләребез Хәдичә апа Батыршина белән Фәридә Гәрәева да бик яхшы беләләр. Шәрәфислам кыйный башлагач, аларга кыш көннәрендә яланаяк барып кергән чакларым күп булды.

Бу иремне яратам. Тыныч тормышка сусаганмындыр инде, бүгенге көнемнән бик канәгать.

— Ә балалар?

— Мин бит башта Казанга киткән идем, шул балаларны көн саен күрермен, ярдәм итеп торырмын, дип кайттым инде монда.

Әйе, Фәүзия йомшак сөйли, хәтта кискен сорауларга да ачуланып, кабынып китми. Әмма аның белән озаграк сөйләшкән саен, минем бу хатынга ышанычым кими барды. Шуңа күрә ул сөйләгәннәрне авыл халкы фикере белән чагыштырып карарга булдым. Күршеләрнең икесе дә Фәүзиянең ире исереп кайтып кыйнап чыгаргач, яланаяк үзләренә килеп кергәнен хәтерләми. Ә пенсионер укытучы Хәдичә апа Батыршина бу гаилә турында сорагач: «Шәрәфислам кебек акыллы, тәртипле, эшчән ир сирәк ул»,— дип, бөтен фикерен бер җөмләгә сыйдырып җавап бирде. Гомумән, кем белән генә сүз башласаң да Шәрәфисламны мактыйлар. Ул колхозның алдынгы тракторчысы булган, әмма хатынының ташлап китүе аның рухын сындырган. Ә инде Фәүзиянең ике өй аркылы гына икенче бер кеше белән язылышканын ишеткәч, Шәрәфислам авылдан ук чыгып киткән.

...Моннан 6—7 ел элек үк инде, Фәүзия председатель белән чуала икән, дигән сүз чыга. Ул сүнеп тормый, елдан-ел куера бара. Бу гайбәткә беренче булып председатель хатыны сыгылып төшә. Инде дүрт баласы да үсеп аякка баскач, тормышларының җайлануына өмете өзелгәч, үз өлешен акчалата гына ала да өйдән чыгып китә ул. Авыл халкы моңа ул чаклы ук күтәрелеп бәрелми. Тормышта аерылулар, кавышулар була, картаймыш көнендә гомер иткән иреннән аерылып әллә ни озак яши алмас, әйләнеп кайтыр әле, дип, сабыр гына аларның кавышуын көтә. Бер ел үтә, ике ел... Әмма хатын әйләнеп кайтмый. Хәер, күңелендә сүнгән өметне уятып, иренең аның янына килгәне, тормышларын яңадан көйләп җибәрергә тәкъдим иткәне дә булмагандыр. Әгәр ир тарафыннан шушындый

адым ясалса, хатын-кыз күпме генә горур булса да яки ничаклы гына рәнҗетелеп яшәсә дә, барысын да онытырга, гафу итәргә әзер зат бит ул.

Ә Фәүзия Казанда бер ел да түзми, яңадан Чирмешәнгә кайтып кибетче булып эшли башлый. Аның янына ире дә, уллары да килгәләп йөри. Гадәтенчә, Фәүзия алар белән ягымлы була. Малайларны күчтәнәченнән өзми. Шәрәфислам эштә чакта өйләренә дә килә, улларының өстенбашын юып, каенанасы белән каенатасына чәйләр куеп эчерә, һаман аларга «эткәй», «әнкәй» дип дәшә. Шәрәфетдиновлар өенә ниндидер бер җылылык, өмет иңә. Шундый килүләрнең һәркайсында Фәүзиянең бөтенләй торып калачагын көтәләр. Әмма...

— Фәүзия председатель белән тора ук икән инде, язылышканнар да икән,— дигән хәбәр бөтен авылны шаккатыра. Бик күпләр ышанмыйлар. «Ничек инде Фәүзия этисе кебек кешегә кияүгә чыксын, ди... Гайбәттер бу!» — диләр. Ә инде моның гайбәттән узып гыйбрәткә әверелүен белгәч, авыл кешесендә нәфрәт чиктән аша. «Моңа чик куярга кирәк», дип төрле инстанцияләргә мөрәҗәгать итәләр. Фәүзияне эштән үк алдыруга ирешәләр. Председательгә дә район оешмалары тарафыннан тиешле җәза бирелә. Тик болар гына ирнең, балаларның хәлен җиңеләйтми шул. Дөрес, Шәрәфисламга әле кырык яшь кенә. Һәм ул, мөгаен, үз тиңен, күңеленә ошаган кешесен табып яңа тормыш та корып җибәрер. Ә балалар? Алар табармы соң әни назын, аның изге киңәшен, җылы карашын? Этиләре яңа оя корса, улларыннан аны яңа мәшәкатьләр, икенче балалар аерачак бит. Кемгә күңел серләрен сөйләрләр балалар, кем белән иң яшерен хисләрен уртаклашырлар, кем белән киңәшерләр? Бала күңелен иң яхшы аңлаучы изге зат — ана бит ул. Ә бүген Рамил белән Рафис өчен шушы кадерле кеше «юк». Бу ике үсмер өчен әни кеше бүген бары тик җан җәфасы гына. Ул аларга хурлык китерүче генә. Мәктәпкә, клубка барганда, алар хәзер Фәүзия яши торган йортны әллә каян әйләнеп үтәләр.

Рамил белән Рафисның язмышы, киләчәге өчен бүген укытучылар, авыл халкы борчыла: хурланудан үз эчләренә бикләнеп малайларның күңеле катмасмы, кешеләргә, тормышка ышанычлары сүнмәсме, дип куркалар.

Ә Фәүзиянең балалар өчен яшим дигәненә ышануы кыен. Әгәр бу сүз хак икән, иреннән аерылгач, начармы-яхшымы, ул үзенә яшәр почмак эзләр иде (авылда буш өйләр, ялгыз карчыклар бар), балаларын янына алыр иде. Ә бит Рамил дә, Рафис та әниләрен бик яратканнар.

«Әнием», дип кенә дәшә торган булганнар. Тик Фәүзия улларыннан бигрәк үз рәхәте, үз мәхәббәте турында кайгырткан. Председатель хатыны булырга, әзергә яшәргә кызыккан Фәүзия.

Вахитов исемендәге колхозның кайсы гына почмагына күз салсаң да, яңа корылмалар күрәсең. Чирмешән авылы үзе бер шәһәрчек сыман үсеп киткән. Балкып торган культура йорты, янында ук колхоз идарәсе, авыл Советы, кунакханә, медпунктны эченә сыйдырган мәһабәт бина, бераз гына читтәрәк урта мәктәп. Әйләнә-тирәләре матур итеп буялган рәшәткәләр, парк, амбар тирәләрендә дә пөхтәлек, тәртип. Йортлар матур, төзек. Шушындый муллык белән балкып торган колхоз, авыллар Чирмешән ягы халкының кайчандыр хыялында гына булган. Аларны менә шушы якты хыялларына канатландырып эшкә туплаучы кеше председатель булган. 20 ел инде ул шушы колхозны җитәкли, халык аның артыннан бара иде. Гомер көзе якынлашканда, халык хөрмәте кебек ышанычлы терәк булганда, «арбаны» «кышка» хәтле дә тарта ала иде әле ул. Әмма бөтенесе челпәрәмә килде. Колхоз тракторчысының гаиләсен таркатып, аның хатынын тартып алуга бөтен авыл аңа каршы күтәрелде. Үгет-нәсихәте, катгый сүзе белән инде бөтенләй таркалган гаиләләрне дә саклап калырлык көч, кодрәт күрә иде бит халык председательдә. Тик моны гына түгел! Әмма 20 ел буе саулыгы, көче, белеме бәрабәренә яулаган абруен Фәүзия «мәхәббәтенә» алыштырды да куйды председатель.

Моңарчы боз крепостедай зәңгәрсу нурлар таратып утырган йортны, Фәүзия аяк баскач, әйтерсең, сөрем сарды. Рамил, Рафис, Шәрәфисламнар гына түгел, бик күпләр читләтеп үтә аны хәзер. Фәүзиягә дә председатель хатыны булып озак яшәргә насыйп булмады. Бүген инде колхозны башка кеше җитәкли. Ә авылдан, гомер кичергән иреннән читтә председательнең үз хатыны, үткәннәренә рәнҗеп, ялгызы картлыгын каршылый...

Язилә Абдулкадыйрова

АНА КҮҢЕЛЕ БАЛАДАМЫ?

Бер ай инде аны таба алмыйлар.

Фамилиясе — Колчина. Исеме — Маргарита. Бәлки алай да түгелдер. Әнә ич, әйткән адресы буенча эзләп

барганнар. Ә анда Колчина дигән хатынны бөтенләй күргәннәре дә юк икән...

Больницага килгәндә бернинди документы да булмаган. Тугыз ае тулган, ә ул хатын-кызлар консультациясенә дә мөрәҗәгать итмәгән, врачларга да күренмәгән. Бары тик тулгаклый башлагач кына Казан шәһәренең 4 нче балалар тудыру больницасына килеп кергән.

— Әле монысы ярый. Баласын больницада калдырып качты. Ә кайберләре? Кеше ишек төбенә, чүп чиләкләренә ташлап китәләр бит...

Больницаның баш врачы Наилә Зиятовна Бикмөхәммәтова бер тынга сүзсез кала. Аннан тамагына тыгылган төерне йотып: «Беләсезме, болар барысы да аракы афәте бит,— ди.— Хатын-кызны хиссез иткән дә, төссез иткән дә шул аракы».

Фикерләребезне раслагандай, бүлмәгә елаудан күзләре кызарып беткән бер әби килеп керә.

— Нәрсә булды? Ник елыйсыз? — ди баш врач, игътибарын әбигә юнәлтеп.

— Оныгым... гарип бала тапкан. Төзәтә алырсыз микән, доктор?

— Беләм мин ул баланы. Дөресрәге, барыбыз да беләбез. Хирурглар чакырдык. Менә-менә килеп җитәргә тиешләр. Сез тынычланыгыз, әби. Мөмкин булганның барысын да эшләрбез.

Әби исә, елый-елый үз алдына сөйләнә.

— Каян гына килде соң шундый кайгы? Наташам да, киявем дә бик әйбәтләр. Әнә аналары ләгыйньгә бирәсе иде андый хәсрәтне. Хәер, барыбер борчылмас иде ул...

— Аларның аналары сезнең кызыгызмы соң, әби, киленегезме?

— Андый исерекнең анасы булудан ходай үзе сакласын. Дөрес, ирем ягыннан бераз туганлыгы бар барын... Үземнең балам булмады, шул, оланнар,— ди әби.— Бераү булды да, саклый алмадым. Ул заманда кая инде, врачы бармы?.. Сугыш вакыты. Ирем фронтта һәлак булды, балам монда дөнья куйды. Торыр җирем юк. Өйдәш булып дигәндәй, шушы балаларның бабаларында яшәдем. Алар вафат булганнан соң кызлары, ягъни боларның әниләре белән торып калдым. Минемчә, эшсезлек кенә шулай бозды аны. Әйтергә эти-әнисе юк. Ә мине санламады. Эчә, тарта, ир-атлар алып кайта башлады. Бер-бер артлы өч бала тапты да, өчесен дә миңа калдырып, чыгып качты. Баласын больницадан алып кайтуында ук өмет юк иде. Берсен генә дә дә күкрәгенә кысып, кочагына салып

кайтмады. Песи баласымыни. Биләвеннән чеметеп тотар иде дә, сумка күтәргәндәй, кул очына тотып кайтыр иде. Кайтып җиткәнче ничек буылып үлмәгәннәрдер?..

Әби, тирән итеп көрсенде дә, тыңлыйлармы икән дигәндәй, безгә күтәрелеп карады, сүзен дәвам итте:

— Менә шул. Кайтарып ташлый да — эше бетә. Ә мин кызганам. Эштән кайткач, көне буе ялгыз ятып ачыккан, буялып беткән балаларны карыйм. Балалар үстерәсем килеп тә мөмкинлегем булмагангадыр инде, яраттым шул багалмаларны. Аналары ташлап китте дип, балалар йортына да бирмәдем, кыерсытмадым да. Әкренләп тәпи бастылар, укый башладылар. Иң шатланганым — нәфесле булмадылар. Бары бергә, югы уртак дигәндәй, ни бар шуңа канәгать булып яшәделәр. Хәзер үземә үзем рәхмәт әйтәм. Төрлесен төрле якка таратмыйча яхшы иттем, димен. Алар булмаса, кем дип яшәр идем бу дөньяда? «Әни» дип өзелеп торалар. Шул сүз менә миңа бар нәрсәдән дә кыйммәтрәк. Менә бу кайгы гына...

— Тынычланыгыз, әби. Кулыбыздан килгәннең барысын да эшләрбез,— диде Наилә Зиятовна, кабатлап.

Каршыбызда утырган олы җанлы кеше әкрен генә кузгалып, рәхмәт әйтеп, хушлашып ишеккә юнәлә. Кыска гына вакыт эчендә бу әбинең мәрхәмәтле җанына, аның эчке дөньясының матурлыгына һәм батырлыгына сокланып, озатып калабыз. Бүлмәдә тынлык урнаша. ...Бер җирдән килере булмаган өч тамак, өч кеше. Ач та итмә, туңдырма да, кеше арасында ким-хур булмаслык итеп укыт та... Хәзер картайган көнендә, тынычлап кына ял итәргә иде дә бит аңа? Юк. Ул һаман алар дип борчыла. Алар еласа елый, алар көлсә шатлана... Күп, һай күп булсын иде дөньяда менә шундый пакь күңелле кешеләр!

— Менә бу, алкогольнең турыдан туры үз баласына түгел, ә баласының баласына булган тәэсиренә мисал,— ди врач, әңгәмәне дәвам иттереп.

— Ичмасам тудырмасыннар иде алар.— Йомыш белән бүлмәгә килеп кергән җыештыручы, сүзнең ни турыда барганын, тиз генә абайлап, әңгәмәгә кушыла.— Баласының бүгенгесе дә, нәселенең киләчәге дә борчымый андыйларны. Менә хәзер типтереп калырга кирәк аларга...

Алай дисәң, аеклардан туган, хәтта кайбер очракта тигез-тату гаиләдә дөньяга килгән баланы да төрле язмыш көтә бит. Мәсәлән, егерме дүрт яшьлек хатын. Икенче баласын тудырган. Малай. Өйдә кызлары бар икән. Больницадан чыгар вакыты җиткәч, баланы алмаска теләвен әйтә бу. «Ни өчен?» — дип сорыйлар. «Ирем кушмый»,—

ди. Ирен чакыртып сөйләшәләр. Ул исә: «Хатыным авырлы вакытта грипп белән чирләде, дарулар күп эчте. Авыру бала белән гомерем буе азапланыр хәлем юк»,— дип җавап биргән. Врачлар, билгеле, сәбәбе зуррактыр, дип уйлаган була. Грипп белән авырган өчен балаларыннан баш тартырлар дип, башларына да килми. Әмма байтак вакыт җанга тия эти кеше. Балага тулы күзәтү үткәреп, анализларын кат-кат тикшергәннән соң гына улын больницадан алырга риза була.

— Кайчагында, киресенчә, балаларын больницада калдырырга үгетлибез. Әйе, әйе, гаҗәпләнмәгез. Шундый очраклар да бар,— ди Наилә Зиятовна.— Әле менә күптән түгел генә бәрәү өченче баласын тапты. Ә үзендә җитди авыру бар. Диагнозы — олигофрения. Ирендә шезофрения авыруы. Кыскасы, икесе дә психик яктан сәламәт түгелләр. Мондый авыруларның үз-үзләрен белештермичә балаларына кул салу очраклары да юк түгел. Нишләргә? Икесен дә чакыртып, җайлап кына сөйләштек. Өч бала белән авыр буласын әйткәч, ризалаштылар. Улларына үзләре теләгән исемне бирделәр дә хушлашып кайтып киттеләр.

Мисаллар күп. Чөнки без көн саен никадәр язмыш белән очрашабыз. Әйтик, «Баламны калдырам» дигән сүзне ишетү авыр булса да, ана кешенең кайчагында бу сүзне чарасызлыктан әйтүен аңлыйсың,— ди баш врач.

— Менә тагын шундый бер хәл. Яшь кенә кыз. Авылдан килгән, авырга узган. Җитмәсә, балалары да игезәкләр. Авырлы вакытта ук тулай торактан куа башлаганнар үзен. Балаң белән монда кайтып керәсе булма, дип кисәткәннәр. Йөрәгендә аналык хисе уянса да, кайтып керер җире булмагач, икеләнеп кала. Балаларын калдырып китү турында курка-курка гына сүз кузгата.

Врачларга кичекмәстән яшь ананың торак мәсьәләсен хәл итәргә кирәк була. Дөрес, тулай торакка үз урынына кайтырга рөхсәт алалар. Әмма ул кечкенә генә бүлмә дә яшь ананың үзенә генә түгел.

Яшереп булмый, соңгы вакытта атасыз бала табып, яхшы шартлар даулап йөрүчеләр ишәйде. Аларның холыксызлыгы җитәкчеләр өчен шактый кыенлыклар тудырып тора. Әмма андый мәгънәсез, тәрбиясез кешеләргә карап, картлык көнендә ялгыз калырга теләмәгән, олыгая барган ялгыз хатын-кызның бала табуын гаепләргә кирәк микән? Яшь бара. Ул һаман үз тиңен очратмый. Әмма аның бала сөясе, аны туган илгә лаек итеп тәрбияләп үстерәсе, үзенә иптәш булдырасы килә. Акыл белән эш

итсен... тапсын, үстерсен. Тимик без аларга. Кырын карап, болай да китек күңелләрен җәрәхәтләмик.

...Икәү.

Беренчесе — болай да караңгы бүлмәсен караңгылап, керләнеп беткән пәрдәсе белән юылмаган тәрәзәсен каплый. Яктылыктан, кешеләр карашыннан ераклашырга тырыша. Балалар шау-шуын ишетмәс өчен колагын кысып, калынрак яулык бәйли. Шартлап ярыларга җиткән башының авыртуына чыдый алмыйча, тагы шешәгә үреләә. Кылган гамәлләренә җавап бирә алмас, бу дөньяда ник яшәвен аңлый алмас дәрәҗәгә җиткәнче эчә. Башы авырткан өчен генә түгел. Айныган арада җаны да авырткан өчен эчә ул. Атна-ун көн генә элек тудырып, больницада ташлап калдырган баласы исенә төшә. Онытыласы, караңгылыкка, хәмер төтененә чумып, кылган гөнаһларыннан качасы килә...

Икенчесе таң белән бергә уяна да табигатьне, бөтен тереклекне иркәләүче кояш яктысына үзе йөгереп чыга. Дөньяның матур, илләрнең тыныч булуына шатланып хезмәт иртәсен башларга җыена. Нәниен күкрәгенә кысып сөя дә, балалар бакчасына кертеп калдыра. Аннан үзе белән алма-кишер ише әйберләр алып эшенә йөгерә. Югарыда сөйләнгән зат тудырып, ташлап калдырган сабыйны тәрбияләргә ашыга...

Икәү. Ике хатын-кыз. Егерме-утыз ел элек алар да сабый булып дөньяга килгән. Әниләреннән мирас булып, икесенә дә бер үк вазифа — ана булу вазифасы калган. Һәм ул үтәлгән дә. Әмма бу бөек исемне йөртергә һәр икесе дә лаекмы соң? Ни өчен дөньяга карашлары, кылган гамәлләре төрле аларның? Яшәү рәвешләре, үзләре тудырган балаларына мөнәсәбәтләре төрле?

Сабый...

Томрап торган күзләр!

Акыллы, әмма яшьле ул күзләр.

Башка балаларны әниләре күкрәгенә кысып сөйгәндә, егылса, күтәреп торгызганда, аны беркем дә иркәләми, бәрелгән җирен беркем дә сыйпамый. Аның белән рәхәтләнеп уйнаучы да, чын күңелдән кушылып көлүче дә юк. Тупырдап йөрүе, һәрнәрсәгә үзенчә исем биреп сөйләшергә өйрәнүе дә шулай ук беркемне шатландырмый. Йә, әйтегез, кемнән ким бу гөнаһсыз җан иясе? Нигә чак кына урынсыз кагылсаң да мөлдерәп яшь түгелергә тора аның күзләреннән? Кешегә гомере буе ныклы терәк кирәк ләбаса. Хәтта үзе ата-ана булгач та. Терәге булганда

тына кеше җирдә ныграк басып тора. Ә бу сабый? Дөньяга яңа гына күзен ачкан нарасый бала? Сөеп, сөелер вакытта сыеныр кешесе бармы аның?...

Балалар больницасы. Ятимнәр бүлмәсе. Язмышлар төрле булган кебек, исем-фамилияләре дә төрле аларның. Волков фамилиясенең табылган урыны — урман. Бүреләрнең кешедән мәрхәмәтлерәк булуы, балага тимәве хөрмәтенә шулай атаганнар. Майская — чәчәкле май аенда, Морозов — ачы суыкта табылган. Малаев — нечкә күңелле тәрбияченең: «Малай бит, шундый матур малай. Нишли бу хатын-кыз, мондый баланы ничек ташламак кирәк, йә инде?..» дип, табылдыкка карап елап җибәрүе — Малаев фамилиясе килеп чыгуга сәбәп булган.

Мондый балалар башта балалар больницасында тәрбияләнә. Сәламәт булганнары билгеле, турыдан-туры балалар йортларына озатыла. Әмма тумыштан ук чирле булып туганнары күбрәк. Чөнки алар беркемнең дә көтеп алганы түгел. Аның дөньяга килүе өчен беркем, бернинди хәстәр дә кылмаган. Киресенчә, тудырмас өчен төрле «чара»лар күргән.

«Баламнан баш тартам». Бу сүзләрне язу өчен шәфкатьсез, кешелексез, соң дәрәҗәдә намуссыз булырга кирәк. Берәүләр җан ачысы белән баласының гомерен саклап калу өчен тырышканда, икенче берәүләр мең газаплар кичереп, дәваланып йөргәндә, дөньяга кеше булып туган нарасыйдан баш тарт, имеш. Балаңнан ваз кичеп гариза яз...

«Мин, Феофанова, 1987 елның егерме җиденче августында туган улымны больницадан алып чыкмыйм. Асрамага алып тәрбияләргә теләгән кешегә рөхсәт. Үземнең тәрбияләргә мөмкинлегем юк.

Баладан баш тартам. Акча керер урыным юк».

«Без, Костиннар, кызыбызның (сеңелебезнең) бу баласын үз тәрбиябезгә ала алмыйбыз. Беренчесен инде тәрбиялибез. Ул үзе беркайда да эшләми, эчә. Атналар буе юкка чыгып тора. Балаларын гына түгел, аның үзен дә без туйдырабыз. Андый мөмкинлегебез юк. Шуңа күрә дә әле туган баланы ала алмыйбыз. Ул сезнең карамакта. Кая куйсагыз да сезнең ихтыярда. Тәрбиягә бирсәгез — каршы килмибез. Соңыннан юллап йөрмибез.

Әнисе, абыйсы».

«Баш тартам. Яшьлек ялгышымның исемен Алексей дип куегыз.

Дежнева».

Мондый дорфа, ярым-йорты белем белән язылган документларның эчтәлеге соңгы елларда кыскарганнан кыскара бара. Эчтәлеге ни өчен кыскарамы? Чөнки калдырып китүләрнең сәбәбен аңлатырлык сүз юк. Эчәргә һәм азгын көн итәргә комачау итәләр дип язмаслар бит инде...

Шушы ук больницада сабыйларын сулышлары белән өреп терелтергә әзер торучы әниләр дә бар. Алар ут эчендә. Тапкан газизләренә каннарын гына түгел, җаннарын да бирергә әзерләр. Кайберләре яшәргә бернинди өмете булмаган баласын да елый-елый, иреннәрен тешләп түзәтүзә карый. Шул йодрык кадәр нарасыйдан башка күзләренә берни күренми. Сабыеның бүген генә булса да, тагын бер генә көн булса да, яшәве кыйммәт аңа. Чыкмаган җанда өмет бар, диләр. Бәлки, могҗиза булып, тернәкләнеп, терелеп китәр. Бәлки киләчәктә шуннан да матур бала булмас... Әнә шундый уй, өмет, теләк белән яши алар.

Ник соң кешенең күңеле тупасланганнан тупаслана, тарая бара, бәгыреката? Ни өчен җанының бер кисәге булып яралган сабыена ярдәм иң кирәк чакта ташлап китә ул аны?

— Бала, туган көннән башлап, әнисенең йөзе белән очрашырга, дөнья белән таныша башларга тиеш,— ди врачлар.— Ә алар ялгыз. Үзе кебек ике-өч сабый белән дүрт стена арасында төн һәм көн, ай һәм еллар үткәрә. Ярый әле балалар больницаларында еш кына нечкә күңелле, бала җанлы кешеләр эшли. Юк вакытларын бар итеп, сабыйларны кулларына күтәрә, һавага алып чыгалар. Сөйләшәләр, бишек җырлары көйлиләр.

Ләкин смена саен икешәрләп кенә эшләгән шәфкать туташлары өчен дәвалау, ашату, асларын алыштыру, юындыру һәм башка шуның кебек эшләр өстенә һәр балага күпләп игътибар бирү мөмкин түгел. Шуңа күрә кечкенә чактан ук аларны бала кирәксенгән гаиләләргә асрамага бирергә, эти-әниле итәргә тырышалар. Ә эти-әни «таба» алмаганнары, яки «баш тартам» дигән документы булмаганнары балалар йортларына озатыла.

Капкадан керешкә сине нәниләрне итәгенә җыеп утыручы изге Феяны хәтерләткән скульптура каршылый. Ул — инде ун ел дәвамында республика балалар йортларына ярдәм итеп килгән Әсгать ага Галимҗанов бүләге. Тирә-

юньдә яшеллек, тәртип. Шундый ук пөхтәлек «Урман аланы» дигән балалар йортының ишеген ачып, түргә узгач та күзгә ташлана. Килүчеләр өчен куелган кәнәфиләр, өстәлдәге чәчәкләр, гөлләр — һәммәсе җылы тәэсир калдыра. Зал ягыннан музыка тавышы ишетелә. Анда зур келәм өстендә музыка дәресенә җыелган балалар тыпырдаша. Зурраклары киенеп, ачык һавадагы мәйданчыкка уйнарга чыгып бара.

— Башкаларын да игътибарсыз калдырмагыз инде. Әнә ничек нәүмиз булып карыйлар бит,— ди тәрбияче, яныннан узганда берничә баланың башыннан сыйпаган кунакка. Берсе белән шаярып-уйнап алсаң, барысы белән дә шуны ук кабатларга кирәк. Наз җитми аларга. Ягымлы сүз, иркәләү җитми. Һәммә әйберләре җитеш аларның. Уенчык дисеңме, урын-җир, кием-салым, ашау-эчү, җиһаз — барысы да бар. Бүлмәләрне дә өйдәгечә гөлле-чәчәкле итеп торырга тырышалар. Ләкин «өйдәгечә» дигән сүз, кайбер балалар өчен бик үк туры килеп бетми. Нинди өйдә яшәгән дә, ни рәвешле монда килеп эләккән бит? Менә Катя. Бирегә урнашканына дүрт ай тула. Ике яшен тутырып килүенә карамастан, йөзенә әле яңа гына елмаю йөгергән, көлә башлаган. Башта кем, нинди хәрәкәт ясаса, шуннан сискәнә, куркынган күзләре белән әсәрләнеп тирә-юньне күзәтә торган була. Өйдә, әнисе янында елый да, көлә дә алмас дәрәҗәгә җиткән була ул. Исерек әнисеннән аралап алып урнаштыралар аны бирегә.

— Хәзер бездә сәрхүш аналарыннан суд белән алынган балалар күп,— ди балалар йортының баш врачы Нина Григорьевна Сафиуллина.— Алар, гадәттә, физик яктан зәгыйфь, үз-үзенә бикләнгән, тәрбия-аң үсеше буенча да үз яшьтәшләреннән артта калган балалар.

Тагын бер танышыбыз — өченче группадан Соня исемле кызчык. Тәрбияче апалары ишек катына атлауга, елап артыннан йөгерә: «Әни, китмә». Күп җәфа күргән бала әйбәт әни «табылгач» кына аны югалтудан курка, күрәсең. Шуңа күрә дә бер генә хәрәкәтен дә күздән ычкындырмыйча күзәтә. Бер генә минутка да тәрбияче-әнисеннән аерылмыйча янында йөрисе, сырпаланасы, сөеләсе килә аның. Ә тәрбиячене «әни» диючеләр күп. Группада егерме бала булса, егермесе өчен дә әни ролен үти ул!..

Безнең илебездә, бала нинди генә югалтуга дучар булса да, ул урамда калмый. Һәрчак өсте бөтен, тамагы тук, урыны җылы аның. Материаль яктан кайбер эти-әниле балаларга тимәгән шартларда яшиләр. Аларны һәрвакыт медицина хезмәткәрләре күзәтеп тора. Балаларның сау-

сәламәт булып үсүе өчен бу мөһим шарт, билгеле. Төгәл режим булдырылган. Әмма дәүләт никадәр генә зур кайгыртучанлык күрсәтмәсен, хезмәткәрләр никадәр генә олы җанлы, йомшак күңелле булмасын, ул инде барыбер ана мәхәббәте, ана назын алыштыра алмый.

Сабыен балалар йортында тота Гәрәева. Ә өендә... Күзеңнең явын алырлык җиһазлар, түшәмнән диванга, диваннан идәнгә тоташ итеп сузылган зиннәтле келәмнәр. Сервант тулы бәллүр савыт-саба. Алтын-көмеш. Килеп керешкә, дөньяда моның кадәр дә матур әйберләр була икән, дип таң каласың. Ә сөйләшә башлап, әлеге ханымның эчке дөньясы белән танышкач, бөтен җиһаз, экияттәге кара көчнең сихере сыман, кап-кара чүп өеменә әверелгәндәй була да кала. Шушы кадәр мал-мөлкәт янына үз җаныңнан яралган сабыең сыймагач, асыл әйбер арасында көн үткәрүеңнең кемгә кирәге бар икән соң? Шушы якты дөньяда бөтен йөрәгең, күңелең белән елмаймагач, алтын тешләреңне күрсәтү өчен генә көлгән булып кылануың — кемгә хаҗәт?!.

Балалар йортында тәрбияләнүче улын, хезмәтенә комачаулый, дип карый Гәрәева. Аның фикеренчә, бала үстерү бөтенләй башка формада алып барылырга тиеш. Ягъни ана баланы табуга балалар йортына тапшырырга теләсә, әйе, бары теләсә генә яңадан алу хокукы калдырылырга тиеш. Юкса, «мескен» хатын-кыз үзе өчен генә яши алмый кала икән...

— Димәк, үзегез өчен яшәп канәгатьләнгәч, балагыз үсә тешкәч, улыгызны алачаксыз?

— Әлбәттә,— ди ана кеше катгый итеп.— Әлегә минем яшьтә яшь бала карап яту — акылсызлык.

— Ул чагында ни өчен сабыйны дөньяга тудырырга уйладыгыз?

— План башка иде...

Җаннан җан аерылган, бала туган. Туган һәм шул тудырган кешесе үк ташлаган. Кендек белән бергә җаннан җанга сузылган күзгә күренмәс җепләр дә киселгән...

Белгечләрнең әйтүенә караганда, бала карында вакытта ук әнисенең ни уйлаганын белеп ята, имеш. Мәсәлән: бер ана авырын дүрт айлык вакытта төшерергә йөри. Ире риза булмаганга күрә генә таба. Тугач исә, бала әнисенең күкрәген имми. Ә этисенә кояшка тартылгандай, атлыгып, талпынып тора икән.

— Дөрестән дә бала күңелен берничәк тә алдап булмый,— ди врачлар.— Өлкәннәрне ышандырырга, хәтта алдарга мөмкин. Ә баланы юк. Кыскасы, начар ният,

кырыслык һәм усаллык белән бала мәхәббәтен һич кенә дә яулармын димә.

Сөйләгәннәргә куәт итеп мисал китерик: ике яшьлек Марат янына соңгы вакытта әнисе ешрак килеп йөри башлады. Ана килеп тәрәзә янына сөялүгә, баланы тәрәзә каршындагы урындыкка илтеп утырталар. Ә Маратта ник бер үзгәреш булсын? Әнисен танып аңа тартылмый да, кулын да сузмый, көлми дә. Бары тик кушылган өчен күпмедер вакыт утыра да төшеп иптәшләре янына китә. Гүя бала эчүдән, кыйналудан йөзләре күгәреп беткән әлеге хатынның күпмедер вакыт шулай килгәләп йөргәннән соң, тагы юкка чыгасын белә. Гүя аңа рәнжи, үпкәли.

«Начар бала үстергән өчен җәза бирергә кирәк»,— дигән Максим Горький. Начар бала үстергән өчен дә, үстерә һәм тәрбияли алмасын белеп тапкан, тапкан да ташлаган өчен дә хөкемгә тартырга кирәк, дияр идем. Әхлакый яктан бозылган сәрхүш хатыннар карамагында, әлбәттә, бала калдырып булмый. Әгәр балалар йортында тәрбияләнүчеләрнең биографиясенә күз салсаң, андыйлар күпчелекне тәшкил итә. Билгеле, арада вакытлыча каратучылар да бар. Алар — студентлар, инвалидлар, әниләре үлеп, этиләре вакытлыча биреп торганнар. Алар монда ятимнәр дип түгел, «әти-әнилеләр» дип, йөртеләләр. Һәм ул балалар, сөйләшенгән вакыттан соң, кире үз өйләренә кайталар. Өйләргә китүчеләр чын ятимнәр арасында да юк түгел. Әмма аз. Йөзләгән бала арасыннан унбиш-егермесен генә балалыкка бирү дә алучы юклыктан түгел. Киресенчә, асрамага бала алырга теләүчеләр күп. Әмма баланы яраткан, аны тәрбияләп кеше итәргә атлыгып торган гаиләләргә бирерлек, һәр яктан камил, сау-сәламәт балалар елдан-ел азая бара. Ә авыру балалар саны арта. Алкоголизм, эчүчелек менә шулай шәхси бәхетсезлектән гомуми бәлагә әверелә.

...Эльза уянып киткәндә, бөтен тереклек якты нурга төренгән иде. Яңа гына яфрак ярган каеннар да, яңгырдан соң күтәрелеп киткән яшел чирәм дә, кичә генә утырткан чәчәк үсентеләре дә... Ә нигә шундый сихри нур эчендә алар? Нигә дөнья бүген шундый якты? Кичәгегә дә, аннан алдагы башка көннәргә дә охшамаган. Ул сикереп торып тәрәзәгә килде. Чынлап та бүген табигать башкача яши башлаган, хәтта кояш үзе дә үзгәргән кебек тоелды аңа. Стеналарны куш йодрыклап төеп, чаң кагасы, тәрәзә төбенә басып, бөтен җиһанга ишетелерлек итеп кычкырасы килде аның. Шыгырдатмаска тырышып ишекне ачты да

коридорга чыкты. Шундый ук җиңел һәм җитез хәрәкәтләр белән күрше бүлмәгә керде. Туганының ятагы янына чүгәләде. Унике ел буе көн дә күреп, бергә уйнап, бергә елап, бергә көлеп, кайчагында төрткәләшеп тә алган туганын беренче тапкыр шулай якын итеп, сокланып карады.

Сеңлесе йокы аралаш нигәдер елмая, ниндидер, татлы төш күреп көлеп ята иде... Эльза, кулларын кош канаты кебек җәеп, туганының чәчләрен, керфекләрен сыйпады.

Эльза шатлык яше тулган күзләрен кемнәндер яшерергә тырышып, урамга чыкты. Йокласын. Яңа көн башлануын уянгач сөйләрмен, дип уйлады. Үзе: «чынлап та, ник болай матур икән соң бу көн, дигән сорауга җавап эзләде. Әллә таң атканда Кама буенда гел шулай була микән? Юк, аның моңа кадәр дә йоклый алмаган төннәре күп булды. Моңа кадәр дә Кама буендагы пионер лагеренда җәйге иртәләрне күп каршылады. Әмма мондый таңны күрмәде...

Эльза кулына кысып тоткан, инде йөз тапкыр укып, һәр хәрефнең нинди авышлыкта булуына кадәр күз алдында калдырган хатны ачты. Ачты да йөзенә каплап, үксеп җибәрде. Шатлыктан тулышкан хисләренең җанына чиксез рәхәтлек бирүеннән, энисе табылудан, «кызларым» дип язылган хат алудан иде бу күз яшьләре. Исәнлеген унбиш ел буе белдертмәгәнгә кыенсыну, балалары алдында үзен гөнаһлы итеп тоюы сизелмәсә дә хатында «кызларым» дигән сүзләр язылган иде. Эльзаны шул җылы сүзләрнең назы, көче канатландырган, күкнең җиденче катына күтәргән иде.

Шушы көннән башлап эниләренең хатлары еш килә башлады. Кызлар үзләре дә көн саен икешәр, өчәр мәртәбә утырып җавап яздылар. Көннәр буе эниләренә әйтер сүзләрен хыялларында кабатладылар. Кадерле кешеләренең төрмәдә булуы, хатларны шунда адресларга кирәклеге һич кимсетмәде аларны. Эни бит ул! Табылды энә. Кайтуга, кызларын үз янына алачак. Бу дөньяда шуннан гайре рәхәтлек булырга мөмкинме соң?

Бу күтәренке хис балаларга ел буена җитте. Ел буе кая басканнарын белмичә очынып йөрделәр. Күзгә күренеп укулары яхшырды. Пөхтәрәк киенә, эшләрен дәртләнеп эшли башладылар. Беренче хатны алган көннән башлап, айларны, атналарны, көннәрне чигереп, бер елны киметә тордылар. Бер ел үтте. Ел да бер атна, ел да бер ай, ел да биш (!) ай... Елдан арткан һәр көн — үзе бер ел, үзе бер газаплы гомер булып тоелды аларга. Җитмәсә, шул газапны тагы да авырайтып, эни кешенең хатлары

сирәгәйде. Тора-бара «кызым» дип эндәшүче бөтенләй билгесезлеккә чумды. Югалды...

Күңел!

Ничә кыллы һәм нинди тукымадан тора икән ул? Кайчагында нигә шулкадәр тартыла да, ә кайчагында нигә шул кадәр бушана, хәлсезләнә? Кайчагында нигә «китек», кайчагында нигә «мөлдерәмә тулы» диләр аны? Шартлап сынарга мөмкин булган әйбер, чайпалып түгелергә дә мөмкин микәнни? Күрәсең шулай. Дәртләнеп җырлый да, ятып елый да белүче йомшак шәфкатьле күңел каты бәгырьлегә дә әйләнә, күрәсең. Эльзаның күңелен дә әнә шулай сындырдылар, хисләрен таптадылар. Кем, дисезме — әнисе.

Хатны тагын, тагын күтәп карады кызлар. Көн саен почтальон янына йөгереп барып, боегып кайткан сеңлесен: «Авырыйдыр безнең әни, син елама»,— дип тынычландырырга тырышты Эльза. Әмма үзе, күңеленең кай почмагы беләндер, бу югалуның сәбәбе авыру түгел икәнен аңлый иде. Эчтән өзгәләнде, эчтән елады кыз бала. Ни өчен аларның язмышы белән шулай шаярдылар соң? Туганнан бирле бер генә мәртәбә дә күрмәгән әниләренә нинди начарлык эшләде соң алар? Хәтта аның йөзгә нинди булуын да белмиләр, каршыларына очраса да танымаячаклар ич... Эльза томан эченә кереп адашты. Ул уйчанланды, үзенә йомылды, усалланды. Юк кына нәрсәгә ачуы чыга яки турсаеп җавап бирә торганга әйләнде. Кем дә булса, берәрсе, әйткән сүзне тиз генә аңламаса, кабат һич кенә дә сөйләп торасы килми башлады. Вакыт-вакыт караңгы җиргә кереп китеп, ауный-ауный елыйсы килде. Кешеләрдән явызлык, дөньядан әшәкелек эзли башлады. Иртәләр кояш баегандагы кебек караңгы, көннәр сүлпән, кояш та кемдер мәҗбүр иткәнгә генә чыга сыман иде. Төшендә генә күргән кебек булып артта калган якты таңнар мәңге кабатланмас, кабатланса да хәзер аның күңелен алай кузгатмас, тәэсирләндермәс инде...

Балаларның хат тәэсирендә ничек үзгәргәннәрен күреп торган педагоглар, ана кешенең бу эшен соң дәрәҗәдә шәфкатьсезлек дип бәяләделәр. Күп нәрсәне аңына да, йөрәгенә дә сыйдыра алмасын белеп, аларны дөньяга тудырган кешенең ямьсез үткәнен һәм бүген кылган намуссызлыгын сөйләмәскә тырыштылар. Әмма кайчан да булса, төрмәдә утыручы бу хатынның кызларының хатын дәлил итеп, балалар йортын судка бирүен, берсен унбиш, икенчесен унике ел караган, ашаткан, киендергән урынга алимент итеп түләгән өч мең сум акчасын кире алуын һәм

ахырдан юкка чыгуын белерләр. Белерләр һәм йөрәкләрендәге төзәлмәс яра гомер буе сулкылдар...

Арганчы елады Надя ул көнне. Әтиләренең мәетен озаткач, өй юа башлаганнар иде. Түшәмгә үрелгән җиреннән диванга тезелеп утырган энеләрен (алар өчәү) һәм сеңлесенә карады да бөгелеп төште. Аларның мөлдерәмә яшь тулы карашларын күтәрә алмыйча, берсеннән берсе кечкенә дүрт туганын нишләтергә дигән сорауга җавап таба алмыйча елады. Укытырга, киендерергә, туендырырга кирәк. Ничек итеп? Үзенә дә нибары егерме тулып, балалыктан яңа чыгып килә ләбаса. Күп нәрсәләрнең җаен, көен, рәтен белми. Күп нәрсәләрне аңларга көче җитмәс кебек. Әмма бер мәсьәләдә көче җитте Надяның. Күпләр уңай хәл итә алмаслык авыр мәсьәләдә. «Үзем исән чакта туганнарымны балалар йортларына бирмәячәкмен». Ул көнне шулай уйлады Надя.

— Көчең җитмәс, үскәнем, карый алмассың,— дип куркытсалар да катгый фикереннән кире кайтмады. Бу сүзләрне ятимлекнең ни икәнен татымаган, иленнән-көненнән аерылып, туган авылыннан китеп, әллә кайдагы балалар йорларында яшәп карамаган кешеләр әйтте: «Юләрләнмә, бир балалар йортларына туганнарыңны»,— дип кабатладылар. Әмма Надяның уен үзгәртә алмадылар. Казанга барып инде өч елга якын эшләгән, тулай торакка урнашкан җиреннән, «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсеннән документларын алды да, кайтып әтисе урынына Актаныш район үзәгендәге сельхозтехникага эшкә урнашты. Ирләр көче таләп ителгән тавышлы, юеш цехта тимер челтәрләр үрү, билгеле, авыр иде аңа. Надя түзде. Хезмәт хакы әйбәт булгач, туганнары хакына түзде. Алар да апаларының үзләре өчен шулай эшләгәнен аңлыйлар. Шуңа күрә кушканны карусыз үтиләр, тыңлыйлар, буйсыналар иде.

Хәер, менә хәзер дә апалары әтиләре урынына да, әниләре урынына да аларга. Берсен дә какмый, берсен дә кыерсытмый.

Әнисе үлгәндә ундүрт яшь тулып узган гына була Надяга. Көтелмәгән, кинәт булган бу хәлдән соң әтиләре Әхмәтхан ага югалып кала. Биш бала бит. Үзләре берсеннән берсе кечкенәләр. Өйләнергә исәп итми. Хатынкызга күңеле каткан. Хатыннар да эчә. Әгәр үги ана булып килгән кеше күз алдында балаларны кага башласа, йөрәге күтәрә алмас кебек тоела аңа. Ике баласын үз янында калдырып, өчесен балалар йортларына урнаштыра

ул. Әле без сөйләгән иң олы кызы Надя, энесе Рафаэль белән Лаеш балалар йортына эләгә.

Җәйге ял вакытларында әтисе аларны ел саен өйләренә алып кайта торган була. Кышларын да, яз һәм көз айларында да мең бәлаләр белән һаман яннарына барып тора. Барыбер күңелсез була Надяга. Туганнарын, ягымлы әтисен, өйләрен сагына. Аннан соң иң күңелгә тигәне — зуррак малайларның бәләкәйләрне, шул исәптән Рафаэльне дә, кыерсытулары була. Андый чакта үзен-үзе белештермичә аларга ташлана ул. Гаделсезлекне җиңәргә, явызлыкны бетерергә тырыша. Ничектер үзенә бер төрле ярсу, ачулы, яралы булып тоела Надяга биредәге малайлар һәм кызлар. Әллә инде матур һәм иркен дөньяда үз дигәнчә йөри алмыйча, бикләнеп сак астында яшәүләренә ачуы килә аларның. Әллә «әти», «әни» дип әйтерлек, кирәк чакта тыеп, кирәк чакта сөеп торучы кешеләре булмаганга, көнләшү хисе күңелләрен шулай җәрәхәтләли? Бу сорауга җавап бирүе кыен. Әмма башка күп балалардан аермалы буларак, тормыш шартларының икенче төрле корылуы — бала психологиясенә үз эзен сала, күрәсең. Тәпи басканнан бирле егерме-утыз кешелек бүлмә, ишле кешегә исәпләп пешерелгән аш, тамга суккан урын-җир, кием-салым, хәтта уйнарга чыкканда да строй белән йөрү... Өстәвенә өч яки җиде яшеңне тутырдыңмы — башка җиргә күчерәләр. Инде генә якын итеп, «әни» дип йөри башлаган тәрбиячең алышына...

Надяга балалар йортында озак яшәргә туры килми килүен. Сигез классны тәмамлаганнан соң, техникумга укырга кереп, тулай торакка дүрт кешелек бүлмәгә күчә. Рафаэльне Арча балалар йортына җибәрәләр. Инде бәләкәй туганнары да үсә төшеп, туган йортка — Актанышка яңадан җыелып бетәбез дигәндә генә көтелмәгән хәл килеп чыга. Әтиләре дөнья куя...

Җәйге каникулга җыйналган: әтиләре янында иркәләнеп, кадер күреп яткан балаларны аяз көндә яшен суккандай була. Бер таушалган йөрәк кайгыны гына түгел, әнә шулай балалары җыелу шатлыгын да күтәрә алмый, күрәсең... Дөм ятим калган балаларның, әйткәнебезчә, зурысына егерме, кечесенә алты тулмаган була. Балалар йортларындагы тормышны үз күзләре белән күреп, туган нигезсез яшәгән балаларның язмышына үзенчә бәя биреп өлгергән Надя, сеңел һәм энеләрен туган ягыннан, ата йортыннан аермаска карар кыла һәм үзендә дүрт баланы карар көч тә, ихтыяр да таба. Ашату-киендерүгә генә түгел, укуларына да зур җаваплылык белән карый. Һәрчак

мәктәпкә барып, туганнарының укуы, үз-үзләрен тотулары турында кызыксынып тора. Оля инде кулинария училищесын тәмамлап эшли башлаган. Ә менә аның турында класс җитәкчесе әле дә яхшы сүзләр белән исенә төшереп тора: «Актив, һәрнәрсәне җиренә җиткереп эшли, чиста, төгәл, диктантларны гел «биш»кә генә яза иде,— ди.— Бик яратып спорт белән шөгыльләнә, ярыш вакытларында күп мәртәбәләр җиңеп, призлы урыннарга чыкты».

Надяның өченче туганы Ренат Кәримов турында да җылы сүзләр генә әйттеләр. Фәйрүзә Гыйниятовна Сәитова рус теле һәм әдәбиятыннан укыткан аны. Ренатның тырыш, сәләтле булуы белән күпләрдән аерылып торуын, һәр эштә үзен җаваплы сизүен, астыртынлыкны яратмавын, гадел һәм мәрхәмәтле булуын сөйли.

Мәрхәмәтлелек! Кешедәге барлык күркәм сыйфатларның нигезе түгелме ул? Һәм аның башы — гаиләне бер йодрыкка төйнәгән апаларына барып тоташмыймы?

Эльмира Шәрифуллина

ШӘФКАТЬСЕЗЛЕК

Маһирә апа кызыннан зарланып утыра: «Бала диген инде, бигрәк шәфкатьсез булды. Мин аңа әллә бар, әллә юк... Чит кешене артыграк күрә. Әйтеп тә ни файда? Бер сүзем дә үтми. Мин аның газиз әнисе. Күпме газаплар күреп тапкан әнисе...»

Аны тынычландырырлык сүзләр таба алмыйм. Хәер, бар микән соң аның йөрәгенә дәва булырлык сүз? Кызы Рәмзияне ничек гаеплисең? Якын түгел аңа әнисе. Теле белән «әни» диеп әйтсә дә, йөрәгендә Маһирә апа өчен җылы почмак юк. «Нишләтим соң, ул миңа бөтенләй чит булгач? Берничек тә якын итә алмыйм»,— бөтен сүзе шул.

Табигать биргән бәйләнешләр өзелгәч, ничек кенә акლансаң да, йөрәкләргә сукмак салынмый икән.

...Маһирә апа кызын алты айдан әбисенә калдырып читкә чыгып китә. Дөрес, ул кайткалап йөри, күчтәнәчен-бүләген җибәрә. Ләкин бала күңелен алар белән генә яулый да, үзенә якынайта да алмый. Теле ачылганда «әттә», «әннә» дип бабасы белән әбисенә дәшә Рәмзия. Сабыйның тәүге адымнарын күреп куанучылар да, каты авырып ятканда аның янында йокысыз төннәр үткәрүчеләр дә әнисе түгел, картайган әбисе белән бабасы була. Ә Ма-

һирә апа?.. Ул Рәмзия өчен гомер буена китә-килә йөргән кунак булып кала.

Тапкан ана түгел, баккан ана, дип белми әйтмәгәннәр шул. Тормыш законнарына таянып, кабат-кабат исбатланган ачы хакыйкать әнә шундый. Үземә бик таныш булган әлеге вакыйганы искә төшерүем юктан гына түгел.

«Баламны калдырам, бер ялгызым үстерә алмыйм» яки «...Фәлән-фәлән кеше баласын ташлап киткән...» Авыру балалар турында әйткән дә юк инде. Хәтта әти-әнисе тигез булган очракта да сабыйны язмыш иркендә калдырып китүчеләр бар. «Ул авыру, безгә гомерлек имгәк кирәкми»...— соңгы вакытта мондый җан өшеткеч сүзләрне еш ишетә башладык. Әйтерсең лә бу сүзләр адәм баласы турында түгел, ә бәлки кирәкмәс товар турында бара!

Бервакыт миңа бер гаиләдә булырга туры килде. Ата белән ана бер-берсен бүлдерә-бүлдерә үзләренең олы хәсрәтләрен сөйләделәр. Кызлары авырып киткән. Дәвалаууга бирешми торган психик авыруга дучар булган. «Кая куйыйк, безгә ничек яшәргә?» дип офтандылар алар. Бу йорттан киткәч тә шушы хәлне тиз генә оныта алмадым. Баланың авыруыннан бигрәк, ата-ананың аңа карата мөнәсәбәтен, әлеге дә баягы «аны нигә беркая да алмыйлар икән» дигән сүзләре йөрәкне телгәләде.

Чын кыйммәтләрне, иң газиз, иң кадерле, иң изге хисләрне кайда югалттык соң? Кешеләрне дә якынлык, туганлык дәрәҗәсенә түгел, ә файда китерү-китермәвенә карап кына бәяли башладык ахры: эшкә яраса — кирәк, ә үзебезгә әзрәк мәшәкать тудыра торган булса — кирәкми, теләсә кая китсен, тик күз көеге булып кына тормасын.

Бу нәрсә? Бәгырьсезлекме? Кайчаннан башланды бу хәл? Моңа ни сәбәп? Мәшәкатьсез, рәхәт тормышка артык күнегеп җиттекме әллә? Ә бәлкем әйләнә-тирәгә, дөньяга күңел күзе белән карый белмәгәннән шулай була торгандыр? Рухыбызны эшкә җигә белмәгәнлектән. Тегеләй дип, болай дип сылтау табарга тырышабыз, тик үзебезнең күңел ярлылыгын танырга теләмибез.

Бәхәсләшмим, авыру баланы карау җиңел түгел. Ул бик зур физик һәм рухи көч, түземлек таләп итә. Терелүгә өмет булмаганда бигрәк тә. Ләкин бит дөньяда бәхетсезлек бирәүдән дә сорап тормый, кисәтүсез-нисез бусаганы атлап килә дә керә. Менә кайда ул тормышның аяусыз сынавы! Кешелеклелеккә һәм тагын башка бик күп сыйфатларга сынау. Рухы белән көчле кешеләр аны офтан-

мыйча, сыкранмыйча уза беләләр. Андыйларны сынаулар чыныктыра гына.

Бу язмамда әйтер сүзем — «күке»-аналар турында. Бала бәхетле булган җирдә халык бәхетле диләр. Мәшәкатьтән качып, үз бәхетен эзләп йөрүчеләрне җәмәгать фикере бүген дә каты гаепли. «Яшьлегеңдә адымнарыңны үлчи белергә кирәк. Кайчандыр балаң артык булган икән, үзеңә дә киләчәктә шундый язмыш әзерләнә. Ни чәчсәң шуны урасың», «Күке-аналарны да җаваплылыкка тартырга вакыт. Аларның эш хакының яртысын хөкүмәт файдасына, балалар йортлары файдасына тотып калырга кирәк!» «Андыйлардан алимент алу гына аз. Закон буенча җавапка тартырга вакыт!» «Үзе исән килеш баласын ятим иткән хатыннарга закон каты булсын иде. Ятимлек кеше күңеленә төзәлмәс яра сала бит ул»...

Ананың балага хыянәте, үзе исән килеш баласын ятимлеккә дучар итүе җәмәгатьчелек тарафыннан әнә шулай кискен гаепләнә.

...Ятимлек дигәннән, балачак хәтере белән күңелдә калган бер мисалга тукталып китәм. Без бәләкәй чакта авылда балалар йорты бар иде. Шуннан унлап бала безнең белән бер класста укыды. Сугыш ятим иткән балалар. «Детдомнар» (аларны шулай дип йөртәләр иде) авыл балаларыннан нык аерылып тора: ничектер тыенкылар, олысымаклар, җитдиләр, уйчаннар, шау-шулы уеннарда катнашмыйлар. Мәктәпкә сафка тезелеп киләләр, киткәндә дә шулай. Өс-башлары, мөгаен, безнекеннән әйбәтрәк тә, тамаклары туграк та булгандыр. Әмма алар безнең иркенлеккә, өйгә кайтып йөрүгә көнләшеп карыйлар иде. Алар өчен ак күмәч түгел, мич төбенә куеп пешерелгән түгәрәк кара икмәк, ярып пешерелгән бәрәңге тансык. Менә шулай, аларның күз карашларында, бөтен кыяфәтендә ятимлек чагыла иде... Һәм тагын Маһирә апа кызы моңа тере шаһит. Бүген үз гаиләсе белән ничек бәхетле яшәсә дә, бала чагын искә төшергәндә күзләре яшьләнә, андый чакта балаларын күкрәгенә ныграк кыса төшә...

...Мин алдарак Маһирә апа язмышы турында сөйләгән идем. Ул бит, югыйсә, рәхәт тормыштан өеннән чыгып китмәгән иде. Аны үзе генә җиңеп чыга алмаслык кыенлыклар баласын калдырып китәргә мәҗбүр итте. Уйлап карасаң, баласын ташлап китүче хатыннарның күбесе бәхеттән качып китүчеләр түгел, ә бәлки бәхеткә — гап-гади хатын-кыз бәхетенә омтылудан шундый гайре табигый адым ясаган кешеләрдер. Шуның өстенә әле аларның гаять бәхетсез киләчәкләре — яшьлектәге ялгышлары өчен

үкенеп, зар елар көннәре алдадыр... Тормыш андыйларга әче сабакны соңга калып булса да төшендерәчәк әле (Мәһирә апага ул инде төшендергән): балага үз йөрәгеңне бирмичә, аның йөрәген яулый алмыйсың.

Әмма сәбәп нинди генә булмасын, хөкем бер. Монда ташламалар юк. Хәтта аларның йөрәк яраларыннан кан саркып торса да...

Ялгышларның да төрлесе була. Төзәтеп булмый торганнары аеруча кыйммәткә төшә. Ана белән бала арасындагы табигатьтән килгән бербөтенлекне җимерү — әнә шул төзәтеп булмый торган ялгышларның берсе.

Ташланган балалар. Бу безнең көннәрдә тәмам авырткан җиргә әйләнде. Ә баланы кемнәр ташлый? Башлыча ялгыз аналар. «Гаилә» атналыгы китергән мәгълүматларга караганда, безнең илдә 1980 елда атасыз балалар саны 427 мең булган, ә 1987 елда ул 548 меңгә җиткән, ягъни 28 процентка арткан. Бу — уйланырга мәҗбүр итә торган статистика.

Дөньяга яңа гына туган сабыйны кайда гына ташлап калдырмыйлар: бала тудыру йортында, поезд вагонында, хәтта чүп контейнерында... Аңардан «котылгач» үзләренең әхлаксыз тормышларын дәвам иттерәләр. Менә ниндиләре аеруча нәфрәт уята аның! Тели икән, тагын бала таба, тагын дәүләт җилкәсенә калдыра. Никахсыз бала табып, дәүләт җилкәсенә калдырган өчен закон буенча бернинди дә җәза каралмаган. Дөрес, баласын тәрбияләүдән ваз кичеп, эчеп-исереп йөрүчеләрен суд карары белән ана хокукыннан мәхрүм итәләр итүен. Аларны да әле иң соңгы чиктә генә. Ләкин бу категориягә кергән хатыннарның күпчелеге әлеге гайре табигый хәлне чүпкә дә санамый. Киресенчә, аларны бу чара «артык мәшәкатьтән» генә котылдыра һәм яңадан үзләре гадәтләнгән тормыш рәвешен алып барырга мөмкинлек бирә.

Ә ташланган балалар?..

Аларның язышы турында дәүләт кайгырта. Төрле оешмалар, балалар фондлары, ниһаять, аерым кешеләр... Кыскасы, тумас борын ятимлеккә дучар ителгән кешеләр турында бөтен ил кайгырта, тик аларны дөньяга китерүчеләр генә бу эштән читтә калып, гамьсез көн күрүне дәвам иттерә. Туктагыз әле, кайчанга кадәр без аларның башларыннан сыйпарбыз? «Син ничек булса да бала тап, ә аны тәрбияләү-үстерү — безнең эш». Шулай булып чыга лабаса! Нигә бу гаделсезлеккә бүгенгәчә юл куела? Ә бит бу очракта сүз җәмгыятьнең киләчәге, аның рухи һәм физик камиллеге турында бара!

Үз баласын тәрбияләүдән баш тарткан, ана хокукыннан мәхрүм ителгән бәндәләрдән ни көтәсең? Алардан ни он, ни йон дип кул селтәргәме? Ашыкмыйк әле алай диярргә. Белмәгәннең беләге авыртмый, диләр. Эшне белеп тә эшләргә теләмәгән кешеләргә карата әйтелә ул. Менә ул «белмәгәннәрне» белдерергә өйрәтәсе иде.

«Баламнан баш тартам. Чөнки аның атасы юк... үземнең көн күрү өчен бернинди килерем юк. Беркайда эшләмим...» Баласын калдырып киткәндә тутырылган бер юридик документтан китерелгән юллар бу. Менә ничек ансат кына. Ышандырырлык дәлил. Шушы кулъязманы калдырасың да, тудырган балаңда синең эшең юк. Әлеге документ сүзләренә бераз гына игътибар итсәң... Көн күрергә мөмкинлеге булмаган кеше иң элек тамак турында кайгыртырга тиеш кебек... Менә шулай, акыл белән түгел, кул хәрәкәте белән генә язылган язу юридик документ булып кала һәм баланың язмышын хәл итә. Ә тегеңә шул гына кирәк...

Бу өлкәдә төзәтмәләр кертер, хөкүмәт дәрәҗәсендә закон тәртибендә карарлар кабул итәр вакыт. Юкса, безнең вәгазь укулар, җәмәгать фикере, кыскасы, яхшы үрнәк белән йогынты ясарга тырышуыбыз корыны бушка әйләндерү генә булып кала.

Рина Зарипова

ЭЧТӘЛЕК

«Онытмаган булсагыз... *Рәйсә Юсупова* 3
Балалар хөкеме. *Әлфия Саматова* 9
Эти кеше хак даулый. *Язилә Абдулкадыйрова* 14
Гомер көзең нинди булыр? *Миңназыйм Сепперов* . . . 18
Әниләр, әниләр... *Рәйсә Юсупова* 22
Очрашу. *Рафаил Төхфәтуллин* 28
Күләгәле мизгелләр. *Ләйлә Зарипова* 33
Соңарган күз яшьләре. *Роза Рәхмәтуллина* 36
Армия тормышыннан берничә көн. *Рифкать Зарипов* . . . 39
Кемнәрне үстердек?.. *Исмәгыйль Шәрәфиев* 53
Кая соң сез, джентльменнар?! *Язилә Абдулкадыйрова* . . 58
Ак үлем — кара язмыш. *Фәүзия Бәйрәмова* 65
Җаннардан иман качты. *Нәбирә Гыйматдинова* 70
Каһәрле «игелек». *Язилә Абдулкадыйрова* 74
Бер мәхәббәт тарихы. *Нәбирә Гыйматдинова* 77
Язмышта ник ялгыш бар? *Язилә Абдулкадыйрова* . . . 82
Сөенечкә дисәм. *Рина Зарипова* 85
Адашкан күңел. *Язилә Абдулкадыйрова* 89
Күк капусы ябылса... *Әлфия Саматова* 92
Йөрәк таш түгел. *Язилә Абдулкадыйрова* 95
Матурлык нинди була? *Алсу Бикбаева* 99
Тәүбә. *Язилә Абдулкадыйрова* 102
«Гафу итә алмыйм». *Рина Зарипова* 106
Мәхәббәтнең хакы бармы? *Язилә Абдулкадыйрова* . . . 113
Ана күңеле баладамы? *Эльмира Шәрифуллина* 117
Шәфкатьсезлек. *Рина Зарипова* 131

Массово-политическое издание

ПОКАЯНИЕ

(на татарском языке)

ИБ № 5858

Редакторы *Я. М. Абдулкадыйрова.* Художнигы *И. К. Стоев.* Художество редакторы *Ш. К. Насыйров.* Техник редакторы *А. С. Газизҗанова.* Корректорлары *Ф. С. Гыйниятуллина, М. Ш. Хәйруллина.* Җыярга тапшырылды 2.08.90. Басарга кул куелды 5.12.90. Форматы 80×108¹/₃₂. Типогр. кәгазе № 2. «Литературная» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 7,14. Шартлы буяу-оттиск 7,35. Нәшер-хисап табагы 7,76. Тиражы 1000 экз. Заказ Л-365. Бәясе 30 тиен. Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан ССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420111. Казан. Бауман ур., 19.

80 тиен.